www.madanizhomga.ru

Мәдәни җомга

1995 елның июленнән башлап чыга

Татарстанда язылу индексы – П2355.

№ 3 (1368) 28 гыйнвар 2022 ел

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:

madani_zhomga
madanizhomga
madanizhomga
madanizhomga

2

Россиядә татарларга, исламга мондый тискәре караш, ачыктан-ачык кимсетүле чыгышлар хәтта патша заманында да булмагандыр.

12

Оренбурглы Альбина Әбсәләмова татар халкының борын-борыннан килгән шөгылен өлкәнең милли брендына әйләндерүгә ирешә.



24

Татарстанның халык артисты Нуриәхмәт Сафинның гомер бәйрәме уңаеннан Г.Кариев театрында уйналган спектакль рухыбызга туры килми.

Оренбургның актин-ак шәлләре Аккош канатына иштер лә!

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

● «Татмедиа» акционерлык җәмгыяте Балтач районы Норма авылы китапханәсендә «Татмедиа клубы» (@tatmedia_club) проекты кысаларында тәүге очрашу уздырды.

● Мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин Татарстан Дәүләт Киңәшчесе, республиканың беренче Президенты Минтимер Шәймиевкә Диния нәзарәтенең иң югары бүләге – I дәрәҗә Мәрҗани орденын тапшырды.

● Татарстан Мәдәният министрлыгы, Театр эшлеклеләре берлеге, Г.Камал театры драматургия өлкәсендә «Яңа татар пьесасы-2022» премиясенә конкурс игълан итте, бәйгегә пьесалар 1 октябрьгә кадәр кабул ителә.

● Г.Камал театры тамашачылар өчен 1 сәгатьлек бушлай экскурсияләр уздыра башлый.

● Change.org сайтында Казанда Җәмигъ мәчете төзүне яклап имза җыя башладылар.

● Казанда февраль башында узачак татар теле һәм әдәбияты буенча төбәкара олимпиадага Россиянең 21 төбәгеннән 150 дән артык укучы киләчәк.

● Г.Тукай әдәби музеенда үткән «Музейда музыка» циклындагы әдәби-музыкаль кичәдә Салих Сәйдәшев, Нәҗип Җиһанов, Рөстәм Яхин, Мансур Мозаффаров һ.б. әсәрләре башкарылды.

● Саратов өлкәсе мөселманнары Диния нәзарәте карамагындагы «Зейд бин Сабит» Коръән үзәге таныган меценат Эдуард хаҗи Ганиев истәлегенә Бөтенроссия Коръән уку конкурсы уздыра.

ӘЙТКӘН СҮЗ – АТКАН УК

Ринат БИЛАЛОВ, «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгының баш мөхәррире:

“Кайчандыр сүз ирегә беренчел иде, әлбәттә. Хәзер кешеләр күбрәк икътисади хәл өчен борчыла, ничек исән калырга дип уйлана. Соңгы ике елда үзе һәм якыннарының сәламәтлеге өчен кайгыра, курка. Бу тема беренче урында, ә җәмгыять, сәясәт аз кызыксындыра. Сүз ирегә исемлекнең азагына төште”.

СЫНАМЫШЛАР

Гыйнвар салкын булса, июль коры һәм эссе була ● Гыйнвар җылы килсә, март салкын була ● Февральдә кар күп яуса, апрель суга бай була ● Февраль башында җылы булса, кар эресә, уңыш уртача булыр, дип фаразлана ● Февраль яңгырлы булса, яз да, җәй дә яңгырлы килә; аяз булса – җәй коры килә ● Февральдә агачларны еш бәс сарса, бал күп була.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **7 сәгать 44 минутта** чыкты, һәм ул **16 сәгать 08 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **8 сәгать 24 минут.** Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **28 минутка озынаячак** һәм киләсе җомгада, ягъни **4 февральдә 8 сәгать 52 минут** тәшкил итәчәк.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

28 гыйнвар – актёр, режиссёр, тәрҗемәче, Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты Зәйни Солтановның (Зәйнелгабидин Гобәйдулла улы Сөләйманов) тууына 130 ел (1892–1952).

31 гыйнвар – философия фәннәре докторы, профессор Мансур Ибраһим улы Абдрахмановның тууына 110 ел (1912–1972).

1 февраль – язучы, шагыйрь Галимҗан Гыйльмановка 65 яшь.

2 февраль – шагыйрь, язучы-публицист, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Әхмәт Мөхәммәтһади улы Гаделнең (Гаязов) тууына 80 ел (1942 –2012);

– актёр, Татарстанның атказанган артисты Сәлим (Александр) Григорий улы Мифтаховка 75 яшь (1947);

– график Фәридә Госман кызы Галиевага 60 яшь (1962).

3 февраль – хор дирижёры, педагог, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Ирнис Әхмәдулла улы Рәхимуллинга 80 яшь (1942).

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Гыйнвар-февральнең магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Андый көнне исегезгә төшерәбез: 29 гыйнвар.**

* * *

Гадәттә, айның соңгы чирегеннән яңа айга кадәр **(25 гыйнвар-1 февраль)** организм кинәнүгә бара. Мондый көннәрдә юан эчәклекне чистартуга бәйле процедуралар үткәрү файдалы.

Шунысын да онытмагыз: **16 гыйнвардан 17 февральгә кадәр** ашказаны, ашказаны асты бизе, талак актив булучан. Шушы вакыт аралыгында аларны чистарту һәм дәвалау уңай нәтиҗәләргә китерә.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1443 ЕЛ

Бүген җөмәдел ахир аеның 25 нче көне

ҖАН АВАЗЫ

Рәфкать СӘГЫЙДУЛЛИН

Чит динлене читкә тибәләр



Дәүләт Думасы депутаты Александр Бородай күптән түгел генә мәчетләр төзүгә каршы чыгыш ясады. Аның әйтүенчә: мәчетләр гадәти мөселманнардан тыш төрле экстремистик группировкаларны да берләштерү үзәкләре булып хезмәт итә икән. Мондый карагруһчылар сафы ишәя генә бара. Шуларның берсе, Лондонга чыгып качкан Олег Кашин да аратирә татарларга каршы өреп куярга онытмый. Бу бәндә, Казанны рус шәһәре дип атап, аэропортына Г.Тукай исемен бирүгә дә каршы. Болай өрүче ялгызаклардан тыш, татарларны дөньядагы иң кыргый халык, хәтта кеше ашаучы, дип сурәтләүче мәктәп дәреслекләре дә дөнья күреп тора.

Әлеге гамәлләрне бүген дә Россиядә татарларга, татар теленә, ислам диненә каршы алып барылган сәясәтнең берничә, кечкенә мисалы дип карарга кирәктер. Әмма саллырак күсәкләр дә "пешеп" килә бугай. Әнә, Дәүләт Думасында христиан тәгълиматларын яклау өчен дип аталган, 30 дан артык депутатны берләштергән эшче төркем оештыра башланды. Бу эшкә патриарх Кирилл фатихасы алынган. Төркемне вице-спикер Петр Толстой җитәкләр дип көтелә. Бу төркемнең дә татарга, исламга карата нинди сәясәт алып барачагы әллә ни яшерен түгел.

Мәчетләр мәсьәләсенә килгәндә, алар инде рус шәһәрләрендә күптәннән тыелган бит. Мисал өчен, 1,26 млн мөселман яшәгән Лондонда бүген 462 мәчет булса, 2 млн (мигрантларны санамыйча) мөселманы булган Мәскәүдә – барлыгы 4 мәчет. Югарыда әйтелгәннәрдән чыгып, татарлар кем, кыргый халыкмы һәм без нинди телдә сөйләшергә тиеш, мәчетләр төзергә рөхсәтне кемнәндер сорарга тиешме соң, дигән сорау туа. Шуларга җавап йөзеннән, тарихчы галимнәрнең соңгы гасырлардагы татар-рус мөнәсәбәтләренә кагылышлы хезмәтләренә күз йөгертик.

XIII гасырда Алтын Урда дәүләте руслар яшәгән төбәкләрне басып алгач, алардан билгеле бер микъдарда салым түләтә, ләкин илнең эчке эшләренә, иҗтимагый-сәяси оешмаларына кагылмый. Русларның руханилары, монахлары, чиркәү һәм монастырь милекләре ясактан азат ителә. Рус руханиларының, дини оешмаларның хокук һәм дәрәҗәләре ханнарның фәрманнары белән раслана һәм закон белән ныгытыла. Рус иленә карата бу сәясәт, соңрак, Алтын Урданың мөселман ханнары заманында да үзгәрмәгән. (В.В.Григорьев. "Россия и Азия", СПб, 1876, 251б.). Ягъни христиан динендәгеләрне татарлаштыру яки мөселманлаштыру теләге Алтын Урда ханнарының уйларына да кереп карамаган.

Инде хәзер XVI-XVIII гасырларда һәм соңрак Мәскәү тарафыннан басып алынган Казан дәүләтенең дини оешмаларына һәм халкының дини ышануларына, иҗтимагый традицияләренә карата нинди сәясәт алып баруларын искә төшерик.

Мәскәү дәүләтендә мөселман руханиларының, гыйбадәтханә һәм мәдрәсәләрнең һичбер төрле аерым хокук һәм өстенлекләре булмау гына түгел, алар өчен бу дәүләттә яшәү хакы да бөтенләй танылмаган. Алтын Урда ханнары башка халыкларның дини ышануларына хөрмәт белән караган булса, моңа капма-каршы буларак, руслар Казанның ислам дине оешмаларын вәхшиләрчә юк иткән, дини җитәкчеләрен кылычтан үткәргән, мәчет-мәдрәсәләрне юк иткән. Татарның русларга карата сәясәте – мөмкинлек бирү һәм автоном ирек булса, русларның казанлыларга карата сәясәте – йоту һәм юк итү булган. Хәтта руслар тарафыннан басып алынган җирләр дә татарларныкы булып саналмаган, алар Мәскәү воеводаларына бүлеп бирелгән.

Воеводалар ике ел срок белән, аларга буйсынган "стрелец"ларның башлыклары һәм ясак җыючы чиновниклар кыска гына вакытка рус булмаган өлкәләргә җибәрелгән. Шуңа күрә бу чиновниклар, шәхси мәнфәгатьләрен кайгыртып, алдау, талау кебек, тиз арада башкалар исәбенә баюына китерә торган чараларның берсеннән дә баш тартмаган (Н. Фирсов. "Положение инородцев Северо-Восточной России в Московском государстве". 1866 г).

Н.Фирсов әйтүенчә: "Мәскәү чиновникларының акыл үсеше шул дәрәҗәдә түбән иде ки, алар байлык туплау өчен алдау һәм көчләүдән башка чара белми һәм хәтта үзләренең иҗтимагый әхлаксызлыкларының асылын аңламый иде". Күбесе укый яза да белмәгән бу бәндәләргә кешелек хисләре бик чит булып, башкаларны кимсетү, изүләргә бик оста иде. Баштагы чорларда җирле халыкны көчләп чукындыру рәсми төстә алып барылмаса да, бу эштә төрле алдау, өстенлекләр вәгъдә итү, хәтта җинаятьләрен йомып калу кебек чаралар да кулланылган. Ләкин миссионерлар зур уңышка ирешә алмый. Моны Н.Фирсов рус руханиларының әхлагы түбән булу белән аңлата: аларның урамда исерек килеш сугышуларын, мәхәллә кешеләреннән күп итеп акча каеруларын, ямьсез сүгенүләрен, бертуктаусыз ашарга һәм эчәргә талауларын... әйтеп китә.

1742 елда Синод "Казан һәм башка өлкәләрдә булган татар мәчетләрен" җимерергә һәм алга таба яңаларын төзергә рөхсәт бирмәскә", дип указ чыгара. Кыска гына вакыт эчендә Россиянең татарлар яшәгән губерналарда 545 мәчет сүтелә-җимерелә, шул исәптән Казан төбәгендәге 536 мәчетнең 418 е юкка чыгарыла.

Казан епископы Лука Конашевич инициативасы белән, чиркәү һәм монастырьлар төзегәндә, төзелеш материалы буларак, борынгы татар зиратларының кабер ташлары кулланыла. Шулай итеп, борынгы гореф-гадәтләрнең, Болгар һәм татар теленең, һәм мәдәниятенең байтак истәлекләре юкка чыгарыла. Бу турыда Ш.Мәрҗани дә язып калдыра, атаклы тарихчыбыз Ризаэтдин Фәхретдин өсти: "Руслар болгар каберлекләрендәге язулы ташларны гына да сәламәт калдырмады. Башка нәрсәләрне әйтеп торасы да юк... Кабер ташларын гына да үз хәлләрендә калдырырлык вөҗданга ия булмаган кавемнән ни калсын?"

Рус илбасарлары астында калган халыклар: татарлар, марилар һ.б. коточкыч изүләргә дучар ителә, аларның мәнфәгатьләрен яклаучы бер генә оешма да булмый. Кача алган халык Урал, Урта Азия, Кавказ якларына күчеп китә, Кама, Агыйдел буйларына сыена.

Шул изүләргә, көчләп чукындыруларга каршы халык күтәрелешләре 10-15 ел саен кабатланып тора. Бәйсезлек өчен көрәш гасырлар буена дәвам итә. XVIII гасыр азагында Екатерина II кайбер ташламаларга барырга мәҗбүр була. 1773 елның 17 июнендә Синод дин иреклеге турында указ чыгара. Ул мөселманнарның мәгариф һәм мәдәниятен үстерүгә дә ярдәм итә. XVIII гасыр ахырында Россия империясендә беренче мәдрәсәләр (мөселман мәктәпләре) яңадан ачыла башлый. 1787 елда Фәннәр академиясе типографиясендә Россиядә беренче тулы Коръән тексты басылып чыга.

Ләкин өстән бирелгән бу чамалы гына ирек тә озакка бармый, XIX гасырның беренче яртысында яңадан көчләп чукындыру башлана. Алар өстенә русларны татар авылларына, татарларны руслар янына күчереп утырту, миссионерларның төрле яшерен һәм башка эшчәнлекләре өстәлә.

Бу чорны Тәфкил Вафин үзенең "Мәкруһлар" исемле документаль әсәрендә яхшы тасвирлый (Мәкруһлар – көчләп чукындырылганнар, ләкин алар бу чукындыруны танымый, үзләрен элеккечә мөселман дип саный, мөселман кануннары буенча яши). Бу әсәр "Казан утлары" журналында (2008 ел, №11-12; 2009 ел, №1-4) басылып чыга. Шул әсәрдән өзекләргә күз салыйк:

"1834 ел. Халык саны алуга санаулы айлар гына калып бара. Шуңа күрә югарыдагылар эшне тизләтергә куша. Беренче чиратта кечерәк авылларның халкын чукындырып бетерергә, аннары зуррак авылларга күчәргә. Шулай итеп Зөя өязе халкын тулысынча православиегә көчләп күчерергә кирәклеге ачыклана.

Мөхәммәтсафа үзенең биш яшьлек оныгы Мөхәммәтсабит белән урамга чыгуга, сәер күренешкә тап була. Урман ягыннан халык төялгән 5-6 атлы арба килеп, аның өе каршысына туктый. Арбадан сакаллы ят кешеләр төшә. Алар утызлап. Араларында берничә поп та бар. Өч балаклы байракларын күтәреп, чиркәү җырларын җырлап, болар урамга юнәлә. Авылны егермеләп атлы жандарм чолгап ала, чыгып качарлык түгел. Авыл урамы төрле ямьсез авазларга күмелә. Татарлар ахырзаман килә дип куркышып, идән асларына, бәрәңге базларына төшеп кача. Ләкин аларны берәмләп сөйрәп чыгаралар, бер җиргә туплыйлар. Атлы жандармнар авылдан чыгып качарга ниятләгән берничә малайны тотып китерә. Шулай итеп авылда барлык татарларны җыеп, Ималле елгасы буена куалап төшерәләр.

(Дәвамы 5 нче биттә).

ДӘҮЛӘТЧЕЛЕКНЕ ЮДЫРТУ ӘМӘЛЕ

Рус халкында, «Война войной, а обед – по-расписанию» дигән әйтем бар. Шуның шикелле, соңгы вакытларда дөньяда сугыш истериясе хәттин ашса да, бериш агай-эне үз эшен – илне глобаль проектларга яраклаштырып үзгәртүне һич туктатмый. Узган җомгада Казанда узган «Татарстан Республикасы агломерацияләрендә социаль-икътисади үсешнең киләчәге һәм проблемалары» дигән стратегик сессияне дә шул җөмләдә карарга кирәктер. Анда Татарстан Президенты Р.Миңнеханов һәм РФ Хисап палатасы башлыгы А.Кудрин да катнашты. Әйе, тема республика өчен яңа түгел. Татарстанда 2030 елга кадәр чорга исәп тотып һәм федераль үзәк белгечләрен дә (шул исәптән А.Кудринны) җәлеп итеп төзелгән социаль-икътисади үсеш стратегиясе («Стратегия-2030») нигезендә, анда Казан, Кама арьягы, Әлмәт агломерацияләре төзелеп килә, 2015 елдан бирле үсеш шул юнәлештә бара. Татарстанның 77% халкы (3 миллион кеше) шунда яши һәм төбәк тулай продуктының 82,8 проценты (2 143,1 миллиард сумлык) бу өлешенә туры килә. Әлбәттә, проблемалар да җитәрлек (сессиягә кадәр Р.Миңнеханов һәм А.Кудрин бу хакта аерым да сөйләшкән). Ә сессиядә сүз Кама арьягы һәм Әлмәт төбәкләрендә яңа магистральләр төзү, агломерацияләрнең хокукый нигезен ныгыту һ.б. турында барган. Төп юнәлешләр исә шул ук кала: социаль инфраструктураны үстерү һәм уңайлы мохит булдыру.

Сессиягә йомгак ясап, А.Кудрин илдә Мәскәүгә көндәш булырдай (ә әлегә ул аны дөнья дәрәҗәсендәге бердәнбер үзәк дип саный) берничә эре агломерация (Екатеринбург, Краснодар, Ростов, Новосибирск, Томск тирәли) булдыру, шундый ук мегаагломерацияне Идел буенда да төзү тәкъдиме белән чыккан. Соңгысында ул Татарстанның аңың үзәге дип түгел, ә бер өлеше итеп кенә күрә. Бу хакта Кудрин: «Татарстанда халык саны 4 миллион тәшкил итә. Язмышны, шул исәптән Россиянекен дә, халыкара югарылыктагы эре агломерацияләр хәл итәчәк. Нәтиҗәлелеккә, энергиялелеккә һәм максатчанлыгына карамастан, Татарстан әлегә үзе генә тиешле дәрәҗәдәге саллы аерылыкка ия түгел. Без 8, 9, 12 миллионны [халыкны] берләштергән төбәк кенә андый [халыкара югарылыктагы] үзәк була ала», – дип сөйләгән. Әмма хезмәт ресурслары һәм базар киңлеге ягыннан ул андый үзәк Татарстан өчен файдалы булыр, дип саный. Идеяне Р.Миңнеханов та хуплаган. Аныңча, эре агломерациягә берләшү территорияләрне кушуны түгел, ә үсеш хакына берләшүне генә аңлата. Территорияләр суверен булып калачак, ә Башкортстан, Самара, Ульян өлкәсе, Удмуртия белән элемтәләр урнаштырудан алар һәммәсе дә отачак.

Идел буе төбәкләрен агломерация төзергә чакыргандa, А.Кудрин аларны тормыш дәрәҗәсен анда халыкара (ягъни Мәскәүдәге) югарылыкка күтәрү мөмкинлеге белән дә ымсындырган. Юкса, моның өчен төбәкләр табышының һич югы яртысын үзләренә калдыру да җитәдер кебек. Ә берләшүнең матди отышы шик уятмый (хәтта «синергия эффекты» дигәне дә ышандыра). Тик руснын «Не хлебом единым жив человек» дигән мәкален дә онытмыйк. Илдәге халыкларны иң элек үз дәүләтчелекләре, туган телләре, милли мәгарифе вә мәдәнияте язмышы борчый. Игътибарны мәсьәләнең хокукый вә сәяси яклары да җәлеп итә. Геосәяси планда исә, Россиядә агломерацияләр төзү аны «Зур Европа»га әзерләүнең төбәкләрдәге социаль-икътисади чагылышы булып тора. Асылда, төп халыклар бүген дәүләт милкеннән, җирдән һәм табигый ресурслардан да колак кага. Бу җәһәттән, Казан Кремленең сәер кыңдәмлеге инде бөтенләй дә аңлашылмый.

Ә Кудрин тәкъдиме артында хәтәр кавемнең Татарстанга карата чираттагы мәкере дә шәйләнә: Идел буе мегаагломерациясен төзүдә аның егәрен кулланып, территориясе вә бюджеты белән бергә, икътисадын да юдыртып, үзен исә гади бер төбәк итеп калдыру. Ә анда инде «клишаслар» моны законлаштырып куярга да күп сорамас. Нәтиҗәдә, Идел буе татар кулы вә көче белән «Зур Европа»га туры китереп үзгәртелә, әмма яңа субъектларда, Татарстанның түгел, хәтта Казанның да (патша чорында булмаган хәл!) исеме дә калмый. Мондый вәзгыятьтә Татарстанга инде бер генә юл кала: әчке агломерацияләрен ныгытып, «Татарстан Республикасы» дигән үзҗитешле агломерация формалаштыру. Ә аңа инде үз киләчәген өметле итәргә теләгән күрше төбәкләр дә ирекле рәвештә кушыла ала.

Фоат УРАЗАЙ.

Театрлар дөньясында

Бүген Г. Камал театрында Татарстанның халык артисты Ирек Баһмановның тууына 90 ел тулу уңаеннан, аны искә алып «Бабайлар чуагы» спектакле тәкъдим ителә.

Г.Кариев театры «Алтынч[ае]ч» спектакле премьерасын тәкъдим итә. Пьеса авторлары – Луиза Янсуар, Резеда Гарипова. Режиссёры – Резеда Гарипова. «Яңа форматтагы әлеге спектакль яшүсмерләр белән дә, өлкәннәр белән дә кара-каршы утырып сөйләшергә чакыра; кем өчендер бу спектакль-медитация булыр, кем өчендер – спектакль-экзальтация», – диелә тамаша хакында алхәбәрдә.

«Әкият» курчак театрының сәнгать җитәкчесе, драматург Илгиз Зәйниев Тинчурин театрында «Мәдинә» трагедиясен сәхнәләштерә.

К.Тинчурин театры «Күрәсем килгән иде…» спектакле белән үзләренең легендар артистлары – Исламия һәм Хәлил Мәхмүтовларны искә алды. Тамашачыларга Исламия Мәхмүтовага багышланган видеоязма күрсәтелде, викторина уйнатылды. Җиңүчеләргә Мәхмүтовларга багышланган «Мәхәббәт чишмәсе» китабы бүләк ителде.

Әлмәт театры Х. Сарьян әсәре буенча сәхнәләштерелгән «Агыйделнең арьягында» спектакле премьерасына әзерләнә. Әлмәтлеләр яңа спектакль белән тамашачыны 3 февраль көнне сөендерәчәк.

С.Өметбаев исемендәге Минзәлә театры гыйнвар уртасында Айгөл Әхмәтгалиева әсәре буенча режиссер Дамир Сәмерханов сәхнәгә куйган «Син кайда иден?» музыкаль комедиясен тәкъдим итте. Бүген әлеге спектакль – кабат сәхнәдә.

Кәрәшен җырлары – бер китапта

Яков Емельянов исемендәге Мәдәни үзәктә Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, сәнгать фәннәре кандидаты Геннадий Макаровның «Яңгыра, кәрәшен җыруы» дигән китабын тәкъдим итү кичәсе узды.

«Китапта Татарстандагы 300 авыл, Самара, Оренбург, Чиләбе өлкәләрендә һәм Башкортстанда күмәк рәвештә көн күрүче кәрәшеннәрнең җыр сәнгатенә хас халык җырлары бирелде. Җыр текстларында диалект, җирле сөйләм үзенчәлекләре саклануга игътибар ителде, җыр сүзләренең язылышы әдәби орфография нормалары белән туры килмәскә мөмкин», – диде автор.

Халык соравы буенча китап интернетта да урнаштырылган. «Китапка Татарстанның көньяк-көнбатыш төбәкләренә хас чуаш җырлары үрнәкләре дә кертелде. Алар ике телдә дә башкарылган һәм халык иҗатында татар-чуаш икетеллелеген чагылдыра. Җырларны ике телдә дә башкару бу төбәкләрдә борыңгы чорлардан бирле гамәлдә булган һәм өлешчә бүгенгәчә саклана», – ди ул. Кәрәшеннәрнең «Бәрмәнчек» дәүләт фольклор ансамбленең сәнгать җитәкчесе Эльмира Кашапова Геннадий Макаровны кәрәшен җырлары, уен коралы музыкасы буенча остаз дип атады. «Ул безнең ансамбльнең атасы. Геннадий Макаров җыйган фольклор материаллары ансамбльдә беренче тапкыр уйналды, җырланды», – диде ул.

Мәдәни үзәк директоры Людмила Белоусова «Туым җондызы» кәрәшен фестивален үткәргән вакытта балалар һәм яшьләр өчен кәрәшен җырларына ихтыяҗ туганын әйтте.

«Китап материалларын әзерләгәндә балалар һәм үсмерләр коллективларының кәрәшен җырларына булган ихтыяҗлары исәпкә алынды. Халык көйләре һәм тарихи, дини тематика буенча иҗат ителгән җырлар кертелде. Бу эшкәртмәләр музыка һәм сәнгать мәктәпләре, балалар иҗат үзәкләрендә оештырылган фольклор ансамбльләрендә катнашкан балаларның башкару мөмкинлекләреннән чыгып эшләнде», – диде китап авторы.

Кичәдә китапка кертелгән көйләрне Нәҗип Җиһанов исемендәге консерваториянең фольклор ансамбле, «Бәрмәнчек» дәүләт фольклор ансамбле, Казан дәүләт мәдәният институтының «Җомга көн» ансамбле, «Балтырган» балалар ансамбле һ.б. яңгыратты.

Зилә МӨБӘРӘКШИНА.

Рамазанга әзерлек

Рамазан җитүгә төгәл 2 ай кала Казан мәчетләрендә халыкны Коръән укырга өйрәтә башлаячаклар. Татарстан мөфтияте һәм Казан Ислам университетының Коръән-хафизлар әзерләү үзәге башкала мәчетләрендә барлык теләүчеләр өчен Коръән укырга өйрәнү дәресләре программасын әзерләде. Махсус оештырылачак курслар атнасына 2 тапкыр ике ай дәвамында гарәп алфавитын, тәҗвид һәм Коръән уку кагыйдәләрен өйрәнүне күздә тота. Дәресләрне Коръән-хафизлар үзәге белгечләре катнашында Рәҗәб аеның беренче көнендә, ягъни 2 февральдән Казанның 7 мәчетендә башлап җибәрү ниятләнә. Алар – Казанның «Рәшидә» (Чәчәкле ур., 24), «Әниләр» (Газовая ур., 18), «Зәңгәр» (Сара Садыйкова ур., 8), «Казан нуры» (Фатыйх Әмирхан ур., 3), «Нурислам» (Муса Бигиев ур., 36), «Иман нуры» (Дорожная ур., 32), «Гаилә» (Җәүдәт Фәйзи урамы, 2) мәчетләре. Курсларны уңышлы тәмамлаучыларга сертификат тапшырылачак. Әлеге чара Ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгы кысаларында үткәрелә.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) хәдисендә болай диелгән: «Раҗәб – чәчү ае, Шәгъбән – су сибү, ә Рамазан – уңыш җыю вакыты», шуңа да Рамазанга әзерлекне мөселманнар 2 ай алдан башлыйлар. Рамазан үзе – Коръән ае булып санала, чөнки бу айда Изге Китап иңә башлаган һәм ай дәвамында мөселманнар аны тулысынча укып чыгып өлгерергә омтыла.

Эльмира СИРАҖИ.

Геройга багышланган кичә

Санкт-Петербургның Татар мәдәни үзәгендә Ленинград блокадасына багышланган «Татар кунак бүлмәсе» дип исемләнгән очрашу узды. Ул 18нче укчы Мга Кызыл байраклы дивизиясе командиры генерал-майор, хәрби фәннәр докторы, Ленин орден иясе Минзакир Әбсәләмовка багышланган иде.

Чарага шәһәр һәм өлкә татар җәмәгатьчелеге вәкилләре, тарихчылар, туган якны өйрәнүчеләр һәм илебезнең хәрби тарихына битараф булмаганнар чакырылган иде. Кунаклар алдында хәрби тарихчы, Тосно районының хәрби тарих музеена нигез салучы Олег Зимин, Санкт-Петербург журналисты, язучы, «Блокадалы Ленинградта яшәүче» билгесе белән бүләкләнгән Рәхим Теләшев (фотода) чыгыш ясады. Кичәне Фирая Рәшитова алып барды.

Очрашуда генерал-майор Минзакир Әбсәләмовның сугышчан батырлыклары һәм 18 нче укчы дивизиянең 1944 елның 26 гыйнварында Тосно бистәсен немец-фашист илбасарларыннан азат итүдә керткән өлеше искә алынды.

Кичә ахырында җирле артистлар чыгыш ясады, О.Берггольц исемендәге драма театрының «күчмә бригада»сы атаклы «Тормыш юлы» әсәрен укыды.

1 нче биттә – Оренбург эшмәкәре Альбина Әбсәләмованың кызы Азалия мамык шәл читен бәйли. Фото гаиләнең шәхси архивыннан алынды.

«Татаркино» хисап тотты

«Мир» кинотеатрында «Татаркино» оешмасының республикабыз районнары кино хезмәткәрләре катнашында узган җыелышында директор Миләүшә Айтуганова үткән елга нәтиҗә ясады, алдагы елда башкарыласы эшләрне барлап чыкты. Быел «Мир» кинотеатрында бу беренче һәм бердәнбер очрашу булырга мөмкин, чөнки мартта аны реконструкциягә ябалар. Бу хәбәр бик шатландыра, чөнки биредә гап-гади конофильмнардан тыш, халыкара мөселман кино фестивале кысаларында төрле чаралар уза һәм чит ил кунакларын искә бинада каршы алу оят иде.

Былтыр төшерелгән «Без – 41 нче ел балалары» быел республика буенча прокатка чыгачагы турында искәртелде. Узган елда субсидиягә төшерелгән сигез проект арасында «Мишка» балалар фильмына һәм «Хыял» нәфис фильмына игътибар юнәлтелде. Алар һәм «Күңел күзе» дип исемләнгән комедияне шулай ук быел республикабыз экраннарында күрергә мөмкин булачак.

Үткән ел «Мультфест» фестивален уңышлы башлап җибәргән иделәр, быел аны дәвам итеп, Татарстан халыкларының үз телләрендә мультфильм төшерүне шарт итеп куймакчылар. 2021дә «Панорама» фестивале республикада үткәрелгән Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елына багышланган булса, быел аны дәвам итеп, Россия Федерациясендә узачак Халык һөнәрчелеге һәм матди булмаган мирас елына бәйләргә ниятлиләр.

Яңалыклардан исә Болгарда Ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгы уңаеннан уздырылачак кино фестивален әйтеп үтәргә мөмкин. Моңа кадәр Татарстан кинофильмнарының электрон каталогы юк иде, быел аны да эшләргә исәпләре бар. Моннан тыш кино һөнәренә өйрәткән мәгариф-белем бирү үзәге булдыру күз уңында тотыла. Беренче тапкыр онлайн-кинотеатр оештырачакларын да әйтеп куйдылар.

2019 елда «Кино һәм театр» проекты зур уңыш белән узган иде. Быел видеога төшерелгән иң матур спектакльләрне күрсәтүне дәвам итмәкчеләр. Моннан тыш «Кино һәм музыка» дип исемләнгән очрашуларда юбиляр композиторларның иҗатлары игътибар үзәгендә булыр дип көтелә. «Киноклуб 12» проекты исә кино белән бәйле юбиляр язучыларны, актер, режиссерларны искә алуны күз уңында тота.

Тагын бер шатлыклы яңалык – февральдән кинотеатрларга билетны, театрларга, музейларга кебек, Пушкин картасы ярдәмендә сатып алып булачак. Әмма бу райондагы кинотеатрлар өчен шактый кыенлыклар тудыра, моның өчен махсус терминаллар сатып алу кирәк һ.б. Сөйләшүдә байтак сораулар шул мәсьәләгә багышланган иде. Пушкин картасы программасы кысаларындагы кинофильмнарны балалар, яшүсмерләр карарлык булырга тиеш. Бу максатта әдәби әсәрләр буенча төшерелгән фильмнарга игътибар биреп, үзебезнең Татарстан киноларын популярлаштыру җаен уйлаячаклар.

Үзәк экраннарда күрсәтелгән «Ералаш» үрнәгендә безнең Татарстанда «Шкодники» шәлкеме эшләнә. 9 ел буена 500 дән артык серия төшерелгән. Төрле дәрәҗәле фестивальләрдә, хәтта Франциянең Канны шәһәрендә уза торган балалар һәм яшүсмерләр өчен фильмнар фестивалендә җиңү яулаганнар. Иң куандырганы шул – быел «Шкодники» шәлкеменең һәркайсы 45 минутлык ике альбомы өчен прокат таныклыгы алуга ирешкәннәр. Пушкин картасы программасы кысаларында күрсәтү өчен ул да бер дигән.

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

Яшь мөэминнәр җыены

Бу көннәрдә Болгар ислам академиясе базасында Мөселман яшьләре форумы бара. Чара Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгы уңаеннан уздырыла торган күпсанлы чараларның берсе булып тора. Быелгы кышкы форум да, узган елгы кебек үк, ике мәйданчыкта һәм бер-бер артлы – егетләр һәм кызлар өчен аерым үтә. Уначенче тапкыр оештырыла торган форумда 60 егет һәм 60 кыз катнаша. Әлеге җыеннар мөселман яшьләренең дини белемен арттыру, әхлагын камилләштерү, аларны рухи кыйммәтләргә, татар халкы традицияләренә карата игътибарын һәм хөрмәтен арттыру ниятеннән оештырыла.

Форумны Мөслимәләр җыены башлап җибәрде. Кызлар Казан, Мәскәү, Чиләбе, Уфа, Оренбург, Самара һәм башка төбәкләрдән җыелды. Алар өчен ял базасында рухи үсешкә, дини-әхлакый яктан камилләшүгә, физик яктан чыныгуга юнәлдерелгән эчтәлекле программа каралган. Форумда катнашучылар Коръәндә исемнәре аталган хатын-кызлар (Фиргавен хатыны Асия, Ибраһим, Нух, Йосыф, Әюб пәйгамбәрнең хатыннары) турында лекцияләр тыңлады.

Мөслимәләрнең эстафетасын егетләр кабул итеп алды һәм Болгар ислам академиясе базасында җыелды. Форумда катнашучылар мөселман кешесенең әхлакый сыйфатлары хакында дәрес ала. Ир кешенең үзе, гаиләсе һәм мөселман өммәте алдындагы бурычлары буенча фикер алышуларда катнаша.

Әлеге форум яшьләргә белемнәрен ныгытырга гына түгел, берләшергә, танышырга, рухи яктан баерга һәм үзләренең социаль башлангычларын тормышка ашырырга мөмкинлек бирә. Мәсәлән, Мөселман яшьләре форумының иң популяр проекты булып намазга һәм ислам нигезләренә өйрәтү буенча «Ислам. Беренче адымнар», өммәтне борчыган мәсьәләләр буенча Фикер алышу клубы, авыру балаларга ярдәм күрсәтүче "Кәгазьгә яңа тормыш бүләк ит" хәйрия акциясе һәм башкалар тора. Шуңа күрә форумны нәзарәтнең социаль проектлар генераторы дип атарга мөмкин.

Тукай бүләгенә тәкъдимнәр җыела

«Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе турында Нигезләмә" нигезендә 2022 елда Г.Тукай бүләген алу өчен тәкъдимнәр кабул ителә. Материалларны 15 февральгә кадәр тапшырырга мөмкин.

Премия иң күренекле, иҗтимагый популярлык алган, милли мәдәният үсешенә зур өлеш керткән, автор әсәренә, яңалыкка һәм оригиналь әдәбият һәм сәнгать әсәрләренә (сынлы, музыка, театр, эстрада-цирк, кино, архитектура һәм шәһәр төзелеше), югары һөнәри осталык дәрәҗәсе белән аерылып торган, шулай ук сәнгать һәм әдәбият белеме өлкәсендә күренекле фәнни тикшеренүләргә өлеш кертkән нә өчен бирелә.

Татарстан Республикасы министрлыклары һәм ведомстволары, шулай ук мәдәният һәм сәнгать учреждениеләре Мәдәният министрлыгы, предприятиеләр, фәнни учреждениеләр, югары уку йортлары, иҗтимагый берләшмәләр аша тәкъдим ителгән эшләр һәм әсәрләр характерына туры килә торган юнәлешләр буенча үз тәкъдимнәрен кертә алалар.

Тәкъдимнәр түбәндәге адрес буенча кабул ителә: Казан шәһәре, Пушкин ур., 66/33, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, 114 кабинет, тел. 264-74-73 (Е.Ю.Чемерисова).

Төрек-татар дуслыгы

Төркиядә Әмирхан Еникинең иҗтимагый мәсьәләләр яктыртылган хикәяләре төрекчәгә тәрҗемә ителеп, китап буларак дөнья күрде. Шушы көннәрдә ул сатуга чыкты.

Татар әдибенең хикәяләрен Бартын университеты филология фәннәре галиме Альп Әрән Дәмиркая тәрҗемә иткән. Китапта Әмирхан Еникинең Икенче дөнья сугышыннан соңгы чорда язылган хикәяләре урын алган.

Тәрҗемәче хикәяләр җыелмасы булган әлеге китапны «Система колы» дип атаган. Мондый исем Әмирхан Еникинең «Гадәт колы» хикәясенә нигезләнеп алынган.

* * *

Истанбулда татар-төрек рәссамы Айгөл Окутан җитәкчелегендә төрек-рус рәссамнарының рәсем күргәзмәсе ачылды. Бәйсез сәнгать фонды тарафыннан оештырылган күргәзмә «Күпер» дип исемләнгән. Анда 50 гә якын әсәр урын алган.



Күргәзмәне ачу тантанасына Төркия Мәдәният министрлыгы вәкиле Җошкун Йылмаз, Фатих районы хакимият башлыгы Әргүн Туран, Бәйсез сәнгать фонды Башкарма комитеты башлыгы Хулия Языҗы катнаштылар.

Россиянең Истанбулдагы баш консулы Андрей Буравов чыгышында күргәзмәнең чын мәгънәсендә күпер ролен башкаруына басым ясады. Күргәзмәнең координаторы Айгөл Окутан «Күпер» күргәзмәсенең чишмә башы булып Алабугада үткән «Басня» иҗат лабораториясе эшчәнлеге торуын белдерде.

* * *

Төркиянең Гази университеты галиме, язучы Искәндәр Өксүз сәясәтче, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе Садри Максуди хакында мәкалә язган. Ул милләттәшебезне «шәкерт-остаз» мөнәсәбәтләре эчендә анализлаган.

Искәндәр Өксүзнең күләмле мәкаләсе төрки дәүләтләр һәм тугандаш халыклар дуслыгы, туганлыгы һәм хезмәттәшлек фондының матбугат органы – «Дәнгә» журналының соңгы санында һәм милли стратегия тикшеренүләр советының «Милли фикер» электрон басмасында дөнья күрде.

Мәкаләдә Садри Максуди Арсалның бөек шәхес булып җитешүендә татар халкының милли үзенчәлекләре, тәрбия һәм омтылышлары зур роль уйнавын белдерелгән. Төрек галиме язмада Садри Максудинең милли аңын үстерү һәм белем офыгын киңәйтүдә зур роль уйнаган абыйсы Һади Максуди, Исмәгыйль Гаспралы, Василий Радлов, Йосыф Акчура, Лев Толстой, Әхмәт Мидхәт, Габдерәшит Ибраһим, Муса Бигиев кебек остазлары белән мөнәсәбәтләрен анализлаган.

Язучы Искәндәр Өксүз Садри Максуди Арсалның эшчәнлеге һәм хезмәтләренең бүгенге төрки дөнья белгечләренә юл күрсәтүче маяк буларак хезмәт итүен, аның дистә еллар буе бик күп сәясәтчеләргә, тарихчыларга, тюркологларга, төрки милләтче һәркемгә, шул исәптән үзенә дә остаз булуын ассызыклаган.

* * *

Түбән Кама белән Төркиянең Мармарис шәһәре арасында икътисад, мәдәният, мәгариф, туризм, спорт өлкәләрендә дуслык һәм хезмәттәшлекне ныгытуга юнәлдерелгән килешү имзаланды. Килешүдә үз имзаларын Түбән Кама районы Башкарма комитеты җитәкчесе Рамил Муллин һәм Мармарис мэры Мехмет Октай куйды.

«Түбән Кама нефть химиясе сәнәгате үзәге булып тора, ә Мармарис – үз чиратында, туризм үзәге. Мин безнең бу юнәлешләрдә үзара файдалы хезмәттәшлек булачагына ышанам», – диде Мехмет Октай.

Рушания АЛТАЙ.

● Дөньяда ун илдә генә турыдан-туры гражданлык алу мөмкинлеге бар, моның өчен җирле бизнеска яки күчемсез милеккә инвестицияләр кертергә кирәк: Сент-Люсия, Антигуа һәм Барбуда, Доминиканада – кимендә 100 мең доллар; Сент-Китс һәм Невиста – 150 мең доллар; Гренадада – 208,3 мең доллар (бу дәүләт паспорты 141 илгә визасыз керү мөмкинлеге бирә); Вануатуда – 226,5 мең доллар; Төркиядә – 1 миллион доллар; Мальтада – 1,1 миллион доллар; Кипрда – 2,4 миллион доллар; Австриядә – 23,7 миллион доллар.

● Дөньяда Чан фамилияле 100 миллион кеше яши – бу Җирдә иң таралган фамилия санала.

● Согыд Гарәбстанында дөньяда иң зур кунакханә төзелә: 1,4 миллион квадрат метр мәйданда 10 мең бүлмә булачак.

Чит динлене читкә тибәләр

(Ахыры. Башы 2 нче биттә).

Поплар башта елга суын "изгеләштергәннәр" (ягъни араларыннан иң олы поп себерке белән елгага су бөрки). Аннары ике жандарм киенгән килеш суга керә. Алар елганың тирәнрәк җирендә туктап кала. Чукынмас өчен батып үләргә теләүчеләрне тотып калачаклар, янәсе. Жандармнар яшь дьяклар булышлыгы белән татар картларын, хатын кызларын һәм бала-чагаларын суга кысрыклап төшерә башлый. Андагы елаулар бала-чагаларның кычкыру-чинаулары акылга сыймаслык күренеш булган. Поплар исә тыныч кына яр өстеннән карап торган. Чөнки алар өчен мондый күренешләр гадәти хәлгә әйләнгән була. Олы яшьтәге ак сакаллы поп су эчендәге татарларның башларына себерке белән су бөркеп чыккач, чукындыру церемониясе башлана.

Судан кешеләрне берәмләп сөйрәп чыгара башлыйлар. Ирләрнең түбәтәйләрен салдырып ташлап, хатын кызларны елатып, бала-чагаларны кычкыртып чукындыралар. Муеннарына калайдан ясалган тәре тагалар. Баулары сүс талкышыннан үреп ясалган була. Аны тиз генә чишә алмаслык итеп юешләп чияләп бәйләп тә куялар. Әбием сөйләгәннәрдән: "Әни әйтә иде, шул тәреле бауны муенга көчләп такканчы, пычак салсалар җиңелрәк булыр иде", – дия иде. Бу чиркангыч чукындыру церемониясе берничә сәгать дәвам итә.

Шуннан соң йортларны су бөркеп "изгеләштерәләр". Тәреләр, иконалар, православие байраклары күтәреп, авылдаш руслар (әлегрәк татарларны руслаштыру максаты белән авылга русларны күчереп утыртталар) катнашкан бер төркем Янгилде урамнарын, татар халкына ят булган тавышлар белән чиркәү җырларын җырлап әйләнә. Урам капкалары, чишмәләр янына агач тәреләрен куеп чыгалар. Бер көн эчендә авыл тәреләргә күмелә. Авыл халкы бу мәхшәр көне тәэсиреннән айный алмый интегә, балалар көнозын ашамый, көтүләр куылмый, сыерлар савылмый, чишмә янындагы тәреләрдән куркып, хатын-кыз суга бармый. Коянтә чиләкләр күтәреп, ирләр үзләре суга барырга мәҗбүр була.

Якшәмбе көннәрендә авыл халкын Колангы чиркәвенә барырга мәҗбүр итеп карыйлар. Халык йөрмәгәч поплар берничә тапкыр жандармнар чакыртып, халыкны куып алып барып та карый, ләкин алар юлда качып бетә. Янгилде халкы ислам диненә кайту нияте белән яши. Аларны исламга кайту юлларына өйрәтүчеләр дә, өндәүчеләр дә үз диннәренә кайтучылар да арта бара".

Рәсми документларда бу кешеләр инде православие динендә булып санала, аларга рус исем-фамилияләрен тагалар. Алар өчен мәчетләргә керү, ислам йолаларында катнашу җинаять санала. Ислам йолаларын үтәгән муллаларны яисә исламга кайтырга өндәүчеләрне берничди судсыз Себергә сөргенгә озаталар. 1867 елның апрель аенда Казан губернасыннан берничә этап мәкруһ Турухан краена озатыла. Зөя төрмәсендә ябылып ятканнарның хатыннары күп мәртәбәләр төрмә капкасы янына килеп, бер-берсе белән таныша. Шул капка янында алар ирләрен Себергә җибәргән очракта алар артыннан китәргә сүз куеша. Шундый теләкле хатын-кызлар шактый була. Автор аларны татар "декабристка"лары дип атый. Бу хатыннар башта Пермьгә кадәр баржага утырып бара. Аннан соң Енисей елгасына кадәр бер ничә мең чакрымнар араны, җәяү үтәләр. Юлда аларның нинди авырлыклар кичергәннәрен бер Аллаһы Тәгалә генә белә. Автор бу турыда сакланып калган документларга таянып яза. Татар хатын-кызының дине һәм милләте өчен үзен аямыйча көрәшкә әзер булырлык рухи көчкә ия булуы сокландыра.

Әсәрнең иң җан тетрәткеч өлеше, мөгаен, шул "декабристка"ларның берсе – Гарфиҗамалның иренә язган хатыдыр.

Сөреләчәк мәкруһларның берсе Фәтхулла Габдулловка төрмәгә хатыны менә мондый хат керттерә:

"Сезки, хәләл җефетем Фәтхулла, без хәләл хатыныңнан-Гарфиҗамалдан күптин-күп сәламнәремне язам. Фәтхулла, җаным, үтенеп сорыйм синнән, Гайфулла кебек үзеңне чукындырып хурлыкка кала күрмә. Бөтен авыл халкы сиңа кяфер дип әйтер. Битеңә төкерерләр. Әгәр син рус буласың икән, ул вакытта бу якты дөньяда чыннан да ни өчен яшәргә? Бу якты дөньяда яшәүнең кызыгы калмый. Әгәр дә сине Себергә җибәрәләр икән мин дә синнән калмыйм, синең белән бергә барам. Артыңнан калмыйча. Аллаһы Тәгаләнең кодрәте зур ташламас.

Ичмасам кызыбыз авыл халкы каршысында хур булмас. Минем хатыным бар дип әйт. Өмет баглыйм сиңа, Фәтхуллам".

Х гасырдан ук ислам динен кабул итеп, мәктәп-мәдрәсәләр төзегән мәдәниятле халыкка, әлбәттә, укырга-язарга өйрәнергә кирәк була, ләкин бу эш тәүлән, балалар уку-язуны, дин сабакларын үзләренең бабаларыннан, әбиләреннән өйрәнә. Кызларга, дин сабагыннан башка, киндер туку, сугу, чигү, оек бәйләү, ипи салу, ашарга пешерүгә өйрәтәләр. Алар шулай итеп мөстәкыйль тормышка өйрәнә. Физик көч таләп иткән эшләрне күбрәк ирләр башкарган. Шулай итеп, тырыш, эшчән, эчкечелекне белмәгән аек татар гаиләләре барлыкка килгән.

Ешкына кайбер "белгеч"ләрдән ишетергә туры килә, имеш, исламда, хатын – ул иренең берcharacterнинди хокуксыз колы. Әсәрдә күренгәнчә, татар хатын-кызлары берничди дә кол түгел, киресенчә, ирләре белән бер сафка басып үзләренең диннәре, гореф гадәтләрен саклап калу өчен көрәшкән. Дөньяда алар өчен иң начар нәрсә чукыну, чукынып руска әйләнү булган.

Әлбәттә, адым саен кабак яисә аракы кибете булган, гадәттәге эчкечелек, шуның белән бәйләнгән төрле вәхшилекләр хөкем сөргән Россиядәге чынбарлык мөселман-татарны үзенә җәлеп итә алмаган.

Шул ук чорда, 1861елда, танылган рус рәссамы В.Перов Россиядә эчкечелек, әхлак нормаларының түбән булуына борчылып, үзенең "Сельский крестный ход на Пасхе" дип аталган әсәрен иҗат итә. Чукынып руска әйләнгән кешене ни көтүе картинада ачык күренә.

Ләкин төрле аяк чалуларга карамастан, XIX гасырның икенче яртысы – XX гасыр башы – Россиядә ислам һәм мөселман-татар мәдәниятенең иң югары чәчәк атуы чоры була. Бу чорда татарлар Россиядә иң күп укучы халыкларның берсе була. 1913 елда татар телендә 340 исемдә китап бастырыла (әрмән телендә – 257, грузин телендә – 232, украин телендә – 228, белорус телендә – 2 китап). Болар өстенә татар телендәге бик күп газета һәм журналлар чыга. Алар Казанда гына түгел, шулай ук Уфада, Оренбургта, Петербургта һәм Мәскәүдә басыла.

Карагруһчы О.Кашинның чыгышларына җавап итеп кайбер рус авторларының татарларга карата нинди фикердә булуларын әйтеп китәргә була. С.И.Монастырский 1884 елда басылып чыккан тарихи-этнографик әсәрендә:

"Что касается обрусенія татаръ, то это дѣло отдаленнаго будущего; а теперь пока они оказываются болѣе развитыми, нежели окружающіе ихъ русскіе, и потому заботы объ обрусеніи татаръ будутъ безплодны, пока не возвысится умственный и матеріальный уровень самихъ русскихъ". (С.Монастырскій Иллюстрированный Спутникъ по Волгѣ. Историко-статистическій очеркъ и справочный указатель. 1884 г.)

Чыгышы белән Самарадан булган этнограф, фольклорчы С.Г.Рыбаков яза:

"Татары – главные представители ислама, выселились изъ Казанской губерніи. Отличаясь энергией, подвижностью, они ведутъ жизнь осѣдлую, трудовую, промышленную, они живутъ зажиточно, и нередко среди нихъ встрѣчаются богачи. Одежда их чистая, нерѣдко красивая, пища разнообразная и питательная. Умственное развитіе Уфимскихъ татаръ довольно высокое: мусульманская образованность сильно развита у нихъ, почти не встрѣчается татарина который не умѣлъ бы по своему читать и писать; что татары стоятъ на довольно высокой культурной ступени и, какъ увидимъ ниже, безспорно превосходятъ духовно всѣ другія народности Уфимской губ... – Что вы русскую вѣру держите? – говорятъ они напримѣръ крещеннымъ татарамъ, – развѣ вы не такіе же татары, какъ и мы, у насъ своя есть вера: зачѣмъ же вы въ русскую вѣру перешли? Богъ не проститъ, что вы перемѣнили свою вѣру... Вы совсѣмъ русскіе стали, носите длинные волосы, хорошо ли это! Вѣдь ваши головы полны вшей; Богъ и пророгъ велѣли брить головы, чтобы всѣ вѣрующие были чисты; а вы вотъ приняли русскую вѣру, и стали косматые, грязные". (С.Рыбаков Исламъ и просвѣщение инородцевъ въ Уфимской губерніи. С.-Петербургъ 1900.)

Россиядә рус булмаган халыкларга бүген туган телләрен өйрәнү тыела, руслаштыру сәясәте бара. Мондый тыюлар хәтта патша Россиясе чорында да булмаган, татарлар башлангыч, урта, хәтта югары белемне үз телләрендә мәдрәсәләрдә алган. Ил башлыгы дәүләтебездә бары тик патриотизм гына милли идея була ала, безне берләштерә торган башка берничди дә идея юк, дип тәкрарлый. Моны ул милли идея русның җирлегеннән, аның йөрәгеннән чыга, дип расламакчы була.

Әмма рус һәм православие диненә булмаган, үзенең туган телендә белем ала алмаган милләтнең бу илнең патриоты булуы, әлеге патриотизм идеясе кысаларына сыя алуы бик шикле. Шуның өчен исламга каршы сәясәт һәм руслаштыру алып барыла түгелме? Православие никадәр генә изге күренмәсен, ә рус теле ничек кенә иң "бөек һәм иң кодрәтле" булмасын, рус империализмы татарны руска әйләндерепбетерә алмады һәм бетерә алмаячак.

Россия империясендә андый милли идея крепостной коллыкка таянган самодержавие чорында да булган, ләкин крепостное право беткәннән соң, самодержавие үзе дә озак яши алмаган.

Академик Д. С. Лихачев милли идея турында:

– "Россиянең берничди дә аерым миссиясе юк һәм булмады да. Халыкны мәдәният кенә коткарачак, берничди милли идея дә эзләргә кирәкми, бу – мираж. Мәдәният – барлык уңышларыбызның нигезе. Милли идеядәге тормыш башта котылгысыз чикләүләргә китерәчәк, ә аннары башка расага, башка халыкларга, башка дингә карата түземсезлек тудырачак. Түземсезлек исә террорга китерәчәк. Кабат нинди дә булса бердәм идеологиягә әйләнеп кайтырга ярамый, чөнки бердәм идеология иртәме яки соңмы фашизмга китерәчәк".

Бүген Россия үзенең рус булмаган милләтләргә карата сәясәте белән фашизмга таба бара түгелме?

Григорий Явлинский: "Россиянең милли идеясе кешегә хөрмәт булырга тиеш", – диде.

Бәлки, бүгенге көндә, татарның милли идеясе – милләтләрнең бер-беренә хөрмәт белән карауны булдырырга тырышудыр.

Атнаның сәяси мизгелләре

СУГЫШ ИСТЕРИЯСЕ ЧАМА БЕЛМИ

Украина тирәсендә куертыла торган сәяси вә хәрби киеренкелек көннән-көн көчәя бара. Мәгълүмат чараларында бу җәһәттән купкан сугыш истериясе инде маньякларга хас ниндидер тыелгысыз характер да ала бара. Аңа мөнәсәбәтле яклар (Көнбатыш, НАТО, Россия, һәм Украина) һәркайсы, үзе һөҗүм итәргә җыенмавы турында белдерсә дә, бер-берсен начар нияттә гаепли, шуңа сылтап, әзерлек чараларын арттыра. Мондый шартларда инде, гомуми картинаны ачыклау өчен, конкрет фактларга гына таянырга кала. Әйтик, АКШ Украинага заманча сугыш кораллары белән хәрби ярдәм күрсәтә башлады. Узган атнада хәрби очкыч белән анда шундый 80 тонна корал (200 миллион долларлык) китерелгән. Игътибарны исә Россия һәм Беларусь кораллы көчләренең тиздән Беларусь полигоннарында үтәчәк "Союзная решимость-2022" атлы хәрби өйрәнүләре дә җәлеп итә. Шул максатларда, Россия гаскәрләренең анда Ерак Көнчыгыштан китерелүе дә мәгълүм. Вашингтон исә моны Россиянең Украинага һөҗүм итү планы белән дә бәйләп карый.

Бу дүшәмбедә инде үзенең хәрби кораблары вә очкычларын Болгария, Румыния һәм Литвага җибәрәчәге турында НАТО игълан итте. Көнчыгыш Европага өстәмә көчләр җибәрергә әзер булулары турында шулай ук Испания, Нидерланд һәм Дания белдерде. Шундый ук ниятләрен АКШ та яшерми. Ул үзенең андагы көчләрен 60 меңлек өстәмә гаскәр белән ныгытмакчы икән. Украинага Россиядән һөҗүм куркынычы янавын сылтау итеп, АКШ, Бөекбритания, Алмания һәм Австралия аннан инде үз дипломатларының да бер өлешен чыгарыргa ният иткән. Донбасстагы законсыз көч структуралары вәкилләре исә Украинаның конфликт зонасына өстәмә танклар һәм артиллерия күчереп урнаштыруы турында хәбәр итә. Ә Европа Берлеге илләренең тышкы эшләр министрлары шурасы бу атнада Брюссельдә үткән утырышында (анда АКШ Дәүләт секретаре Э.Блинкен да катнашкан) Россиянең Украинага карата агрессив гамәлләрен гаепләп чыккан. Күренә ки, сугыш истериясе бүген, хактан да, төрле тарафтан куертыла.

Фоат УРАЗАЙ.

Мәдәният цифрлашуга йөз тота

«Казан Экспо» халыкара күргәзмә үзәгендә Татарстан Мәдәният министрлыгының чираттагы еллык коллегиясе булып узды. Утырыш башланганчы күргәзмәдә кайбер мәдәният казанышлары белән танышырга мөмкин иде.

«Переход» компаниясе проекты буенча тормышка ашырылган экскурсиядә 1910 елгы Казан буенча виртуаль сәяхәт итәргә теләүчеләр бик күп булып чыкты. Проектны борынгы Казанның 3 мең фотосын кулланып, тарихчы, археолог, архитектор, реставратор, дизайнер, компьютер программалары белгечләрен җәлеп итеп, бик бөртекләп эшләгәнгә күрә халык кызыксынып карады. Хәзерге Казанны да күпләп фотога алганнар. Нәтиҗәдә, виртуаль күзлек киеп, тарихи Казанны, бер төймәсенә баскач исә, бүгенге шәһәр күренешләрен тамаша кылырга мөмкин. Әлеге сәяхәтне ашыкмыйча Милли музейда карарга була.

Күргәзмәдә шулай ук Илдар Гатауллин җитәкчелегендәге «Милли хәситә» җәмгыяте җитештергән милли костюмнарны, калфак, түбәтәйләрне, каюлы күн читекләрне күрергә мөмкин иде. Композитор Салих Сәйдәшевнең дирижер таякчыгы, олуг рәссамыбыз Бакый ага Урманче рәсемнәре, шагыйрь Сибгат Хәким шигыренең кульязмасы,

Вилдановлар гаиләсе ясаган домбра, кылкубызлар, Кәгъбәне каплаган тукыманың Милли музей фондларында сакланган Россиядәге иң зур кисәге шулай ук мәдәният хезмәткәрләрендә зур кызыксыну уятты.

Утырышта беренче булып сүз алган Милләт эшләре буенча федераль агентлык җитәкчесе Игорь Бариновның Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының авторлар коллективын «Габдулла Тукайның тормышы һәм иҗаты буенча материаллар» хезмәте белән «Ключевое слово» Бөтенроссия иҗтимагый премиясенең «Иң яхшы фәнни проект» номинациясендә җиңү яулавы белән котлавы коллегиягә җыелучыларда горурлык хисләре уяткандыр. Горурланырлык та, чөнки бәйгегә 62 субъекттан 340 гариза кабул ителгән булган, шуларның утыз бере - Татарстаныбыздан.

Россия Федерациясе Президентының иҗтимагый проектлар буенча идарә башлыгы урынбасары Александр Журавский грантлар өчен ярышта активлыгыбыз өчен мактады. Үткән ел нәтиҗәләре буенча республикабыз грантка тәкъдим ителгән проектлар саны буенча Россиядә - дүртенче, ә җиңүчеләр арасында икенче урында. Быел да Татарстаныбыздан тәкъдим ителгән проектлар бик күп. Сан ягыннан безне Мәскәү генә узып киткән. Сүз уңаеннан, быел грант акчасы 8 миллиард тәшкил итәчәк, киләсе елга исә аны 10 миллиардка җиткерү каралган.

А.Журавский 2022 елда тормышка ашырыласы иң зур проектлардан Г.Камал театры өчен яңа бина төзелешен һәм Н.Фешин исемендәге Казан сәнгать училищесы нигезендә гамәлгә куелачак креатив индустрияләр мәктәбен искә алды. Бу мәктәп 12 яшьтән алып 17 яшькәчә балалар, яшүсмерләр өчен каралган. Биредә анимация, 3D графика, фото, видео, яңа компьютер технологияләре студияләре эшләячәк, эшмәкәрлек нигезләрен өйрәтү каралган. Проект 58 миллион сумлык федераль грант хисабына тормышка ашырылачак.

Мәдәният министры Ирада Әюпова яңа елда мәдәният оешмалары урнашкан биналарны яңарту эше дәвам иттерелеп, музейларны капиталь ремонтлауга басым ясалачагы турында әйтте. Лаеш районына бу максатта 20 миллион сум бүлеп бирелгән инде.

КАМАЗның 50 еллыгы уңаеннан Чаллыдагы «Мастеровые» театры өчен яңа бина бирелүе, «Культура» милли проекты кысаларында Түбән Кама яшь тамашачы театрының бинасы реконструкцияләнәчәге турында хәбәр бик сөендерде.

Яңартылган биналарда мәдәният оешмалары тагын да нәтиҗәлерәк эшли башлар дигән өметен белдерде министр. Үткән елгы нәтиҗәләргә карагандa

Болгар, Зөя музей-тыюлыклары, «Әкият» курчак театры һәм Казан циркының үзләре эшләп алган акча күләме арткан. Бүтән театр, концерт залларында да бу күрсәткечнең артуы күзәтелә, шул ук вакытта билет бәяләре элеккечә калган.

Күптән түгел узган стратегик сессия нәтиҗәләре министрны борчуга салган: уку йортлары һәм эш бирүчеләр арасында тыгыз элемтә юк икән. Министрлар Кабинеты каршындагы иҗтимагый һәм икътисади тикшеренүләр үзәге, Икътисад, Хезмәт һәм социаль яклау министрлыклары белән бергә кичекмәстән кадрлар укытып чыгару һәм үз белгечлекләре буенча эшкә урнаштыру мәсьәләсен хәл итәргә кирәк, юкса бик авыр хәлгә калуыбыз бар, дип нәтиҗә ясады И.Әюпова.

Кадрлар мәсьәләсе уңай хәл ителсен өчен, беренче чиратта, хезмәт хакын карарга иде дә, бу хакта коллегиядә бөтенләй сүз булмады, чөнки министрның чыгышыннан аңлашылганча, мәдәният тармагында уртача хезмәт хакы болай да 39 193 сум тәшкил итә. Менә шулай, җәмәгать!

Хезмәт хакы кәгазьдә генә булса, Пушкин картасын кулланып билет алучыларның саны Татарстаныбызда күп булуы уйдырма түгел, чынбарлык. Пушкин картасы буенча иң күп билет сатучылар арасында Камал, Качалов театрлары, Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе беренче урында тора. Алабуга музей-комплексы, Казан Кремле, Тәтеш музейлары шулай ук алдынгылар рәтендә.

Казан федераль университетының Мәгълүмати технологияләр һәм интеллектуаль системалар институтының өлкән мөгаллиме Виталий Абрамовның чыгышы мәдәният тармагындагы хезмәт хаклары кебек үк, уйдырмага охшаш иде. Егет метагаләм булдыру турында хыяллары белән уртаклашты. 2013 елда Мәдәният министрлыгы, федераль университет һәм Дәүләт идарәсенең цифрлы үсеше, Мәгълүмати технологияләр һәм элемтә министрлыгы XIV гасыр Болгарны компьютер ярдәмендә торгыза башлый. Баш сөякләренә карап, персонажлар ясыйлар, борынгы шәһәрләрне торгызалар. Уеннары үзләренә шул дәрәҗәдә ошап китә ки, якын киләчәктә компьютер уенында бөтен Татарстанны гәүдәләндерергә карар кылалар. Метагаләм уенына бөтен дөньядан кем тели, шул катнашып, ул милләттәшләрне, халыкларны берләштерү, дуслаштыру чарасы булачак дигән өметен белдерде В.Абрамов. Егетнең сүзләренә караганда, бүген Сингапур һәм Кытайның Чэнду шәһәре метагаләм булдыру белән мәшгуль. 2025 елга метагаләмнең базары 800 миллиард доллар тәшкил итәчәк, имеш. Сингапурның метагаләм булдыруы гаҗәп түгел анысы. Бернинди табигый ресурслары да булмыйча, хәтта эчә торган суны да Малайзиядән кертеп, зур икътисади үсешкә ирешә ич ул. Сингапурда кеше гомеренең озынлыгы Россия белән чагыштырганда 14 елга артык. Сәламәтлек буенча дөньяда беренче урында торалар. Метагаләм булдырганчы, 1959-1990 елларда Сингапурда эшләгән премьер-министр Ли Куан Ю кебек коррупциягә каршы аяусыз көрәш ачаргадыр, бәлки. Республикабызда әле һаман да байтак мәктәп, китапханә, музей, клубларның әбрәкәйләре урамда урнашкан. Әбрәкәй ярыгыннан чын галәмне күреп яшәгән халыкка компьютер галәме турында сөйлә, имеш...

Вице-премьер Ләйлә Фазлыева үткән ел нәтиҗәләре буенча алдынгы мәдәният хезмәткәрләренә бүләкләр тапшырганнан соң, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлек вәкилләре белән проект офис утырышлары булды.

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

Ничәнче төн бер үк төш күрәм мин, Мин исемсез нәни кош икән...

(Күренекле шагыйрь, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе Зөлфәтнең тууына 75 ел)



ЗӨЛФӘТ

ДӘШӘ КОРЪӘНДӘГЕ ҺӘР АЯТЬ

Дөньялыкның һәрбер дене дәшә,
Дәшә Корьәндәге һәр аять:
Мәхәббәтсез яшәү дөрес түгел,
Мәхәббәтсез яшәү –
Җинаять!

Нур уйнаклый төпсез киңлекләрдә...
Нурлар – чиксезлекнең юлдашы...
Тик сөюсез яшәп буламыни? –
Юкны сөйләмәгез, валлаһи!

Яратмаска яратылган булсам,
Булсын бу гомерем төш кенә!..
Яратусыз еллар килә икән,
Мин – юк...
Мине «үлде» дисеннәр...

Яратмыйча яшәү – гомерсезлек.
Бу – тумыштан үлем!
Бу – җәза...
Бүтән җәза уйлап табып булмас,
Күпме эзләсәң дә дөньяда...

Иң зур каргыш булып калыр һаман
Сиратларның кылыч үткере:
– Юлың фатихасыз булсын берүк!
– Мәхәббәтсез гомер иткере!

...Юк-юк! Болай гына әйтә куйдым...
Сайрасын кош,
Талда талпынып,
Ае-елы, сәгатьләре түгел,
Мәхәббәтле булсын
Һәр минут!..

...Чиксезлектән
шомырт чәчәгедәй
Коелганда сөю җаннарга,
Җилдәге бер яфрак булып тибрән
Безгә аткан серле таңнарда...

КҮРЕШӘ КАЛСАК

Остазыбыз Мөхәммәт Мәһди ядкяре

Томанлы таңда наз иңә җиргә,
Әйтерсең сыер бозавын ялый...
Ходайның изге сәгате иңде –
Ужымнар шыта, Мөхәммәт абый...

Газаплы ләззәт, ләззәтле газап
Җылы туфрактан гарешкә аша.
Ходаем, берүк ярдәм ит җиргә –
Җир уҗымлаган мәлләр ләбаса...

Яшәүнең сере ачылган мәлләр...
Тик крестьян гына сизенә моны:
Сискәнә җирдә ужымнар түгел –
Фани дөньяның мәңгелек моңы.

Безнең бетүләр шушы микәнни
Дигән шикелле, күңел ут йота –
Тынычлан, адәм баласы, диеп,
Мөхәммәт абый, ужымнар шыта...

Йөргән җирендә, хәтта гүрендә
Ужымнарга күз саласы килә,
Игенен чәчкән бер крестьян булып,
Басу түрендә каласы килә.

Шул басу түре – бар дөньяң синең,
Бар дөньяң шушы ужым бит инде.
Тургайлар никтер оча эзләнеп,
Кайда соң үзе, диләр шикелле.

Исә дә исә ужымнар җиле...
Вакыт алдында без һаман сабый.
Күрешсәк анда, сөйләрмен таңда
Ужым шытканын, Мөхәммәт абый...

КАНАТ ҖИЛЕ

Күтәрелде кошлар иле белән...
Наис Гамбәр

Безнең бәхет бары Мөслимдәдер...
Кайтыйк әле, Наис, Мөслимгә бер –
Өшәнгән бу бәгырь җылынсын...
Барыйк әле иртүк Ык ярына,
Тездән чумып салкын чыкларына,
Авыз итик каен сулышын!

Сукмакларга үлән үскәндер бит,
Тик учаклар әле исәндер бит –
Сагынгандыр безне сукмаклар...
Үзебезчә тик бер сөйләш кенә,
Чылтыр чишмәләргә эндәш кенә –
Телләреңә былбыл кунаклар!

Тынып ыгы-зыгы, алкышлардан,
Колак салыйк әле шул кошларга –
Моң тәменә алар өйрәтте...
Күтәрелсен кошлар иле белән –
Шул кошларның канат җиле белән
«Өф»ләп дәвалыйк бер йөрәкне.

Кайтыйк әле, Наис, Мөслимгә бер!
«Кыз сукмагы» синең исеңдәдер –
Безнең ярлар асыл яр иде!
Асылъярлар һаман шунда сыман...
Тәрәзәдән – гөлләр арасыннан
Караттырган чаклар бар иде!

Шул сукмактан тик бер үтик әле,
Таныш тәрәзләрне чиртик әле...
Ай калыккач, зәңгәр эңгердә
Зарыккандыр сөйгән ярлар көтеп!
...Тибрәнмәс шул инде пәрдә чите –
Кабатланмый сөю бу җирдә...

Ә шулай да кайтыйк Мөслимгә бер!
Моң чишмәсе бары Мөслимдәдер –
Кипкән иреннәргә моң тисен!
Күтәрелсен кошлар иле белән –
Шул кошларның канат җиле белән
Җиллиселәр килә, җиллисе!

Әйдә, киен! Калсын бу мәгыйшәт!
Гомер уздырабыз монда нишләп?! –
Тормыйк, табында, дип, аш кала...
Кайтыйк әле газиз Мөслимгә бер –
Беркая да качмас мескен дәвер,
Дәвам итәр бездән башка да...

КУРКУ

Ничәнче төн бер үк төш күрәм мин,
Мин исемсез нәни кош икән...
Кемдер мылтык төзи астан миңа –
Тын алганын хәтта ишетәм.

Йолдыз серен аңламакчы идем,
Серен төшенмәкче болытның.
Кемдер мылтык төзи астан миңа! –
Сайравымны хәтта оныттым.

Кемдер мылтык төзи, мылтык төзи!
Очам кичке нурда ялтырап.
Күтәр мине, канат, биеккәрәк!
Янчы, кичке кояш, яктырак!..

Күкнең кеме соң сез, сак йолдызлар?
Чиксез ерак ялтыр ташлармы?
Әллә инде, афәтләрдән куркып,
Артык биек менгән кошлармы?

...Ничәнче төн күрәм бу төшне мин,
Шомландыра ул төш, тетрәтә.
Мин уянам. Шомлы курку белән
Кош сулкылдый эчтә – күкрәктә.

Ничәнче төн шомлы төш күрәм мин,
Һәм куркудан каба сулуым:
Кош булуың хәтта шомлы чакта
Җинаятьтер – кеше булуың...

КАРЛАР ТИК ТОРА

Мөдәррис Әгъләмгә

Бүген моңсу...
Иске зур каланың
Үзеннән дә иске йортында
Авыр уйлар килеп тукталалар,
Яңа уйлар йөрәк портына.

Их син, сәйях дустым, нәни гигант!
Без ракета күк, тик бер аерма:
Ракетаның тыш катлавы яна,
Безнең исә – йөрәк тойгыларның
Атмосфера катлауларында.

Илне дөрләтерлек ялкын ята
Җил иркендә калган күмердә.
Илдә көчек булсаң да бик ярый,
Тик ил өчен кирәк өрергә!

Чатнап күктә яна яшен ташы,
Төшмәгән ул ләкин күкләрдән, –
Шул ут безне җиргә атып бәргән,
Шул ут безне күккә күтәргән.

Сырттан сыйпамыйлар –
куркынычтыр! –
Тик кирәкми авыр суларга:
Илдә бүре булсаң да бик ярый,
Тик ил өчен кирәк уларга!

...Ага вакыт җиргә ак кар булып,
Ага еллар, уза гомерләр.
Беренче кар булсаң да бик ярый –
Ил җанында кирәк эрергә.

Ява карлар, ашыккандай җирнең
Караларын акка күмәргә.
Шагыйрьлек тә ярый – моның өчен
Җырлы иткән җылы көннәргә
Үзең белән кирәк түләргә.

Ага вакыт җиргә ак кар булып,
Бәгырьләрдә гүли бу вакыт,
Күзләренә кара,
Көчең җитсә,
Шул вакытны юлда туктатып.

Их син, сәйях дустым, нәни гигант!
Карлар төшми, карлар тик тора! –
Тибрәнгәләп күккә күтәрелә
Безнең шушы иске йорт кына.

Моңсу бүген... Иске планетаның
Үзеннән дә иске шул Вакыт –
Көче җитте! –
Сорау ала бездән,
Күзгә карап, юлда туктатып...

БОЛДИНО КӨЗЛӘРЕ

Империядә авыр, шыксыз кара төннәр.
Болдинода – Пушкин.
Илдә – карантиннар.
Тып-тын аллеяда япа-ялгыз бара...
Бик еракта аңа әзерләнә яра –

Соңгы авыр яра, соңгы канлы яра.
Көзге болыт күктә, илдә төннәр кара.

Пьяна! Сәрхуш елга! Хәтерләп кал төсен –
Көтмәгәндә беркөн куркып айныр өчен!

Хәтерләп кал, көзге төнгә чумган авыл!
Нәфрәт кыса җанны, уйның җанда давыл.

Постлар, карантиннар –
эпидемик дәүләт.
Котылу юк аннан җаныңны да түләп!

Төнге этләр өрә кара донослардан!
...Якты шампан чыжлый
алтын подносларда.

Ә тегендә гөрли мазуркалы заллар,
Таңга кадәр шаулый искитмәле баллар! –

Мәгърур һәм сабыр алтын эполетлар,
Һәм сайлана авыр алтын пистолетка

Авыр, шомлы пуля –
әзерләнә яра...
Көзге болыт күктә, илдә төннәр кара.

Үтерүчеләрнең вакыты бик кысан! –
Пушкин гына сабыр, Пушкин гына уйчан:

Сулык-сулык тибә күкрәгендә аның
Туган илнең моңы, туган илнең җаны...

Ә туган ил монда, ә туган ил – галәм,
Юк, пистолет түгел, кулда – каурый каләм.

Ул үзе, бер мәңге үлмәс сагыш сыман,
Аллеяда бара... Болдинода таман.

Канат җилпи җанда әйтеләсе сүзе,
Шагыйрь түгел, гүя газизләрнең үзе!

Аллеяда бара...
Ул нәкъ шулай барыр
Көткән чакта аны соңгы канлы барьер...

Йә, кайсыгыз аңа төзәр пистолетны?
Йә, кайсыгыз анда яңа эполетлы?!

Мәдәни җомга
28 гыйнвар
№3, 2022

Таулар

Тукай районындагы Таулар авылы XVII гасыр ахырында ук нигезләнгән булса да, Россия архивына килеп эләккән урыс документларында аның крестияннары турындагы эш 1702 елдан бирле саклана. "В Мензелинскую в приказную избу стряпчему и воеводе Федору Федоровичу Люпшину..." дип башланган ошбу документта сөйләнгән хәлләрне воеводаның приказлар йортында Семен Пушкарев атлы керәшен урысчага тәрҗемә кылып торган. Бу эш – Казан өязенең Алат юлында урнашкан Түбәяз (Төбәяз, Төбәк-?) авылыннан служилый татар Нәдер Биктимеров белән Уфа өязендәге Таулар авылыннан ясаклы татар Корманай Токмәтовның (Төхфәтов, Тукмөхәммәтов-?) бер-берсенә дәгъвалары турында. Бер тынычбилгеләрсез язылган документны ялгышларсыз гына аңлавы да читен. Имеш, Корманайның яланга чыгарылган алашасын служилый Нәдер урлап алып киткән дә, аны Төкәй (Тәкый, Токай-?) Балтачев атлы крестиян аты белән алмашкан. Ә Таулардан Корманай үзенең югалган алашасын эзләп килгәч, Нәдер белән Төкәй урманга яшерелгән ике атны да (эз җую максатыннандыр) суеп үтергән икән. Корманай каракларны җинаять өстендә тоткач, шул ук урман эчендә үзара йодрык сугышлары да булып алган һәм, ниһаять, ошбу катлаулы җинаять эше Минзәлә воеводасы каршында, суза-суза, 1703 елның 17 маена кадәр тикшерелгән. Минзәлә воеводасының приказлар йортында 1702 елның 25 декабреннән 1703 елның 2 гыйнварына кадәр каралган икенче бер эш Таулы Байлар авылы крестияны Сәет (Сәгыйт) Илкинның икенче берәүдән – Яммәт Туйкин атлы кешедән үзенә тиешле акчаны дәгъвалавы хакында.

Игътибар иткәнсездер: Таулар авылы ул чагында Таулы Байлар дигән исем белән аталып йөргән. Димәк, Таулар авылын нигезләүчеләр Иске Байлар авылыннан күчеп утырган булырга тиеш. 1870 елда "Таулар" гына булып йөргән авылны 90 хуҗалык тәшкил иткән. 1884 елда тауларлылар барысы да – 1079 җан иясе типтәр булып язылган. Алар 2326 дисәтинә җирдән файдаланган. Хуҗалыкларда 111 баш эш аты, 71 баш сыер, 718 баш сарык, 63 кәҗә асраганнар.

1911 елда Таулар авылында 492 ир-ат һәм 397 хатын-кыз гомер иткән. 1913 ел мәгълүматлары буенча, Тауларда бер хуҗалык кына ни сәбәпледер имана җирсез калып, иген икмичә яшәгән. Ә 34 хуҗалык 4 дисәтинәдән дә кимрәк мәйданнан файдаланган. Калганнары 5-8 дисәтинәдән алып 25, хәтта 100 дисәтинәгә кадәр җирдә иген иккән һәм таза тормышлы крестияннар булып исәпләнгән. Бу вакытта авылдагы хуҗалыклар саны 160 тан артса да, йортларда барлыгы 101 эш аты, 107 сыер, 718 сарык һәм 41 кәҗә генә исәпләнгән. Авылның 70 хуҗалыгы сыерсыз, ә 32 гаилә сыңар мал да асрамыйча гомер иткән. Шул ук вакытта 65 гаилә вәкилләре тирә-якка төрле промыселларга йөргән, Күзкәй базарында сату иткән.

Дөрес, әле 1870 ел мәгълүматлары буенча ук Тауларда байтак кешенең арба тәгәрмәче һәм чабата үреп көн итүе ачыклана. Моннан тыш, байтак гаиләләр йон тетеп, киез һәм киез итек басып акча асраган. Кемдер калач пешереп саткан, кемдер олаучылык белән кәсеп иткән. Шул ук 1870 елда авылда 7 кибет тотылу – авылның бөтенләй үк көрчеккә терәлмәвен раслап тора. 1870 елга кадәр, атнаның һәр сишәмбе көнендә, Тауларда атналык базар да эшләп килә әле.

Шул нисбәттән, Уфа архивында 1864 елдан бирле сакланып калган бер гыйбрәтле документ бар. Шул елның 7 апрелендә тауларлылар авыл җыены үткәрә һәм ел саен, 10-16 июнь көннәренә туры китереп, авылда атналык ярминкә үткәрергә, дигән карар кабул итә. Карарга Йорт старшинасы Кормашев һәм авыл старостасы Бикмөхәммәт Бикчәнтәев кул куя. Ә эш йөртү өчен вәкил итеп Габделкаһир Мәҗитовны сайлыйлар. Гариза Оренбургтагы губерна идарәсенә дә юллана. Ләкин, ни галәмәт, соңыннан нәкъ совет чорында модага кергән бумеранг "уены" шикелле үк, ул гариза Күзкәй волосте башлыклары карамагына кайтып төшә. Ә Күзкәй авылыныкылар, билгеле ки, ярминкә-базарларны фәкать Күзкәйнең үзендә генә уздыру, үз казнасын баету яклы. Таулар авылы крестиянарының "приговоры" да шул елның 19 декабренда Күзкәй волосте "сходкасына" куеп тикшерелә һәм, әлбәттә, үтенеч кире кагыла...

Мондый авыл җыеннары Тауларда да күп тапкыр һәм төрле мәсьәләгә багышлап үткәрелгән. Әйтик, 1915 елда уздырылган бер җыен 77 хуҗалыкта яшәгән 210 ир-атның узган елда салым өчен акча түләмәвен тикшергән дә, әлеге бурычны инде һәр ир-аттан 1 сум 41 тиен күләмендә 200 кеше җилкәсенә салуны карар иткән. Шушындый ук җыеннарда теләсә кайчан урман яки әрәмәлекләрдәге агачларны кисмәү, чабылмаган печәнлек-яланнарны җигүле атлар белән таптатмау, тәгаенләнмәгән урыннарга чүп-чар түкмәү һәм үләксәләр ташламау, вакыты килештерелмичә торып иген кырларыннан көлтә яки әрәмәлекләрдән утын ташымау кебек карарлар да кабул ителгән.

1920 елда авылдагы хуҗалыклар саны 169 га җиткән, авыл өч коедан файдаланган.

Инде Таулар авылының үзебезгә мәгълүм рухи башлыклары исемнәрен дә атап үтик. 1814 елның 9 июлендә мәчеткә Габденнасыйр Ихсан улы имам булып билгеләнә. 1821 елда указлы Мансур Ихсан улы азанчы булып эшли. Табылган документлар 1874 елда Фәхрелислам хәзрәт Шәрәфетдин углының имам-хатыйб булып торганлыгын раслый, әмма ярты елдан соң аны Шаһимәрдән Шәрәфетдин улы алыштыра. 1888 елгы документта Фәхрелислам хәзрәт янә имам вазифасын үти, ләкин авылда инде Мөхәммәтҗан Мөхәммәтшин атлы яңа имам да пәйда булган.

1905 елда Тауларда яңа мәчет сафка баса. Аның имам-хатыйбы – һаман шул ук Фәхрелислам Шәрәфетдин улы Нигъмәтуллин. Ул 1850 елда туган, Калмия авылы мәдрәсәсендә Габделкаһир Каһарман углында белем алган. 1875 елда аңа указ тапшырганнар. Әнә шул указ кайтып җитмәү сәбәпле, Тауларда Мөхәммәт Мөхәммәтшаһ улы Идрисов та имамлык итеп торган. Мөхәммәтҗан хәзрәт исә тумышы белән 1860 елгы, ул Югары Тәкермән мәдрәсәсендә Котбетдин Сиражетдин углыннан белем алган. Болардан тыш авыл мәчетендә Шәйхелислам Мөхәммәтдин улы мәзин булып торган, анысы 1869 елгы. 1911 елда да

● Таулар авылы мәчете.

шушы ук имам һәм мәзин мәчетне тота.

Әлбәттә, Таулар авылы мәчете каршында мәдрәсә дә эшләгән. Анда имам-хатыйб Мөхәммәтҗан Идрисов мөдәррислек итә. Нәкъ менә шушы имам Минзәлә өязенең түрәләре каршында буза куптара:

– Салымны татар милләте дә түли бит. Ә нишләп земство акчасы урыс мәктәпләренә генә бирелә? Татар мәктәпләрен нигә рәнҗетәсез?

Ошбу таләп өяз күләмендә революция сыманрак кабул ителә. Әмма шул ук елда Таулар мәдрәсәсенә һәм бүтән татар мәктәпләренә дә һичьюгы 30 сум (ике ат бәясе) күләмендә акчалата ярдәм бирелә башлый.

Мәдрәсә турында берничә сүз. Аның бинасы 4 тәрәзәле, бер мичле, калай түбәле була. Анда кадими ысул белән 35 балага белем бирәләр. Ләкин 1910 елларда Таулар мәдрәсәсенә дә җәдитчә укыту үтеп керә. Әлеге хәл шимчылар һәм сатлыкҗаннар ярдәмендә губерна башлыкларына барып җитә. 1913 елның 6 октябрендә вице-губернатор Казан мәгариф попечителе Васильевка 9 пункттан торган хат юллый һәм җәдит мәктәпләрен милләтчелектә гаепли, алар турында фактик мәгълүматлар тупларга боера. 1911 елда Иж-Бубый мәдрәсәсенең юкка чыгарылу тарихын да, бер гасырдан соң бүгенге татар мәктәпләренә нинди аяусыз һөҗүм оештырылуын да без яхшы беләбез.

Татар мәктәп-мәдрәсәләренә тискәре караш илдә хакимият алышканнан соң да үзгәрми. Совет власте 1920 елда шәһәр һәм авылларда мәчетләр ачарга рөхсәт биргән булып кыйланса да, алар каршына катгый таләпләр куела. Мәчетләрне ремонтлау, яктырту, җылыту диндарларның үз җилкәсенә калдырыла. Диндарлар саны, мулла-мәзиннәрнең алмашынуы, гаилә хәлләре, хәтта мал-мөлкәтләре турында да совет органнарына хәбәр итеп торылырга тиеш була. Теләсә нинди мәктәп ачу өчен дә югарыдан рөхсәт алу һәм устав раслату таләбе куела һ.б.

Ләкин халыкны башка төр афәтләр дә көтеп тора әле. 1920 елның 27 маенда Татарстан автономиясен төзү турында карар дөнья күрсә дә, өч ай үтүгә, 20 августта ук Казанга азык-төлек развёрсткасы үткәрү хакында фәрман килеп төшә. "Шартларның ниндилегенә карамастан һәм азык-төлек нормаларына зыян китереп булса да, развёрстканы үткәрү мәҗбүри. Татарстан 10 миллион 120 мең пот ашлык җыеп тапшырырга тиеш!" Авылларга продразверстка отрядлары юллана. Республиканың улчактагы Җир эшләре комиссары Юныс Вәлиди бу гамәлне "халыкны талау" дип, ә развёрстка хуплаучыларны "Мәскәү холуйлары", "милләт хыянәтчеләре" дип атый. Чөнки бүген әле һаман аерым бер төркем шәхесләр аны "лаек, шәп җитәкче" итеп танытырга тырышкан Сәетгалиев Татарстанга 10 миллион да 120 мең пот күләмендә төшерелгән развёрстка планын 15 миллион да 400 мең потка җиткереп үтәү һәм Мәскәү түрәләре алдында йөз аклау, танылу турында хыяллана. Имеш, "дөнья революциясен коткарырга кирәк, ә аның мәнфәгатьләре белән чагыштырган чакта татар халкы бернәрсә дә тормый".

Менә шундый күрсәтмә төшерелгәнгә күрә Татарстан халкыннан 10 миллион да 130 мең пот ашлык, 411 мең дә 74 пот мал ите, 17 миллион 900 мең данә йомырка, 10 мең 923 пот май, 9 мең 313 пот бал, 30 мең 270 пот кош ите, 2 миллион 297 мең 231 пот печән җыеп-талап алалар. Монысы гына җитмәгән, 1921 елның 11 маенда Татарстанга В.Ленин имзасы куелган яңа бер күрсәтмә килеп төшә. Анысы инде халыктан янә 500 мең пот ашлык фуражы җыюны таләп итә. Июнь аенда ук Мәскәүгә 200 мең пот күләмендәге "яңа ясакны" да озаталар. Ләкин Татарстанның Совнарком рәисе Кәшшаф Мохтаров "дәүләт фондында ашлык

һәм фураж чиктән тыш аз калды”, дип миһербанлыкка чакырырга батырчылык итә. Тик соң инде, “дөнья революциясе хакына” Татарстан крестияннары тулаем шәрә калдырылган була. 1921 елның җәендә башланган коточкыч ачлыкны һава шартларына, корылыкка аударып калдыру гына үзен һич акламый, халыкның йөз меңнәргә җитеп кырылуында Татарстан халкын талап чыгу – иң төп хата. Әлеге коточкыч ачлык, әлбәттә, Таулар авылын да уратып узмаган. 1921 елда авылда 939 кеше яшәгән булса, бер кыштан соң аларның 625 е генә исән калган. Татарстан халкы да бу ачлык өчен 500 меңгә кадәр кеше җаны белән түли. Ләкин Минзәләдәге политбүлек мөдире Молчанов халыкның коточкыч дәрәҗәдә кырылуын һаман азсына, күрәсең. Ул Мәскәүгә “мондагы халыкның совет органнарына мөнәсәбәте дошманнарча”, дигән хәбәр җибәреп ята. ВЧКга тик шул гына кирәк, ул ач халыкны “ипкә кертү өчен” Татарстанга яңадан-яңа җәза отрядлары һәм полклар юллый. Шунысы хак: халыкны хакимият хуҗалары түгел, ә шул елны тыкрык-бакчаларда мул булып үскән алабута һәм Америкадан килеп җиткән ярдәм саклап кала...

Әмма халыкны әле яңа афәтләр көтә. 1929 елның 30 сентябрендә Минзәләдә кантон ярлылары конференциясе уздырыла, ул крестиян хуҗалыкларын колхозларга кертеп бетерү бурычын куя. Гәрчә бу карар большевиклар партиясенең Мәскәү залларында кабул ителсә дә, аны менә шул рәвешчә – ярлылар, хатын-кызлар, комсомоллар авызыннан әйттерәләр.

Ноябрь аенда ук Күзкәй волостендагы 25 торак пунктта күмәк хуҗалыклар оеша. Шул ук айда кантон газетасы “элеккеге Минзәлә волостендагы 56 авылның һәркайсында да колхозлар төзелде”, дип рапорт бирә. 1930 ел башында инде кантон составындагы барча авылларның 57 процентында крестияннар күмәк хуҗалыкларга берләште, дигән рапорт та онытылмый. Әмма үзәк газеталарда И.Сталинның “Уңышлардан баш әйләнү” дигән мәкаләсе дөнья күрү колхозлар төзелешендә тукталыш ясарга мәҗбүр итә.

Таулар авылында да “Алмаз” хуҗалыгы 1929 елда төзелә. Ләкин кантон газетасының 1931 елның 1 мартында дөнья күргән саны 40 авылда колхозлар таралуны раслый. Таулар ул исемлеккә эләкми кала, чөнки 1931 елның февралендә колхоз яңадан оешып өлгерә. Әмма кантон күләмендә колхозлашу темпы түбән була әле. Газета 1931 елның 20 сентябрь санында да фәкать 34 процент хуҗалыкның гына күмәк хуҗалыкларга берләшүен раслый. Бу берләшүнең халыкны нинди кайгыларга салуын шул заманның бер җыры шәп аныклый:

Күмәк тормыш әйбәт, диде
Юлбашчыбыз Ысталин.
Колхозларда эшли-эшли,
Тузып бетте ыштаным...

Шунысын да яшерерлек түгел: колхозлар төзелә башлау белән үк авылларда кулак буларак таланучы “халык дошманнары” пәйда була. Аларны сайлау хокукларыннан мәхрүм итәләр, “паразит сыйныф” сафына теркиләр. Менә шундыйлардан бер гаилә.

“Шәйхелислам Мөхәммәтдинов. Азанчы. Хокуксыз. Хатыны 53 яшьтә, кызы – 17дә, кызы – 13тә, кызы – 9да, улы – 5тә. Мөлкәте: 2 ат, 1 сыер, 7 сарык, 1 йорт, 1 абзар, 1 амбар, 1 мунча. Революциягә кадәр һәм революциядән соң 1929 елга кадәр мулла булып тора. Бервакытта да үзе эшләми, яллап эшләтә”.

Икенче гаилә: “Гыйльман Насыйров. Сатучы (сәүдәгәр), хокуксыз. Үзе 65 яшьтә, хатыны 65тә, улы – 28дә, килене – 30да, оныгы – 7дә, оныкчасы – 4тә, оныкчасы – 2дә. Мөлкәте: 2 ат, 2 сыер, 15 сарык, 8 умарта, 2 йорт, 1 кәнүшнә, 2 абзар,1 чиннек, 1 абзар, 1 мунча, 1 лапас, 1 суырткыч. Революциягә кадәр сәүдәгәр, аннан соң 1929 елга кадәр икенче рәзрәт патинт белән сату иткән. Хөкүмәткә каршы кеше”.

Өченче гаилә. “Хәлим Хәбибуллин. Сатучы. Үзе – 50дә, хатыны – 45тә, уллары – 25 һәм 23тә, кызы – 2дә, уллары – 19, 16, 14 һәм 8дә. Мөлкәте: 3 ат, 3 сыер, сарык, 2 йорт, 1 мал өе, 1 абзар, 1 амбар, 1 мунча, йорт нәрсәләре. Сәүдәгәр, икенче рәзрәт патинт белән сату иткән. Яллы хезмәт тоткан. Нык контыр”.

Дүртенче гаилә: “Гәрәй Галимов. Сатучы, хокуксыз, 50 яшьтә. Хатыны – 50дә, улы – 14тә, кызы – 10да, улы – 5тә. Мөлкәте: сарай, мал абзары, баз өсте, ихата, амбар, мунча, ат, сыер, 10 сарык”.

Бишенче гаилә: “Гәрәй Миңлегалиев. Крәстиян, хокуклы. Үзе – 55тә, хатыны – 55тә, уллары – 24, 22, 17, 15, 13 һәм 11 яшьләрдә, агасының кызы – 14тә. Мөлкәте: йорт, баз өсте, лапас, сарай, амбар, мунча”.

Әлеге гаиләләрнең кайберләре туган җиреннән, бер казыксыз калдырылып, Себергә сөрелергә хөкем ителгән. Икенчеләре, яшәү хакын даулап, суд юлларын таптаган. Гыйльманов Харис бер генә оешма тарафыннан да аклау-яклау таба алмагач, читтә качып йөрергә мәҗбүр булган. Гаиләсендә 8 кеше, алар әлегә авылда гомер сакларга маташа, ә 28 яшьлек ир үзе сукбайлыкта...

Таулар авылының тагын бер “контыр кулагы” Шәфыйк Хәбибрахмановны, нәкъ Харис Гыйльманов кебек үк качып йөргән чакта, Воровский совхозына барып эләктерәләр. Ул шунда барып эшкә урнашкан булган икән...

1934 елда гына да Минзәлә якларыннан 812 кеше читкә сөрелгән. Әле сөрелмичә, туган җирендә калган килеш тә бер хокуксыз коллар хәлендә тотылган мескеннәр дә никадәр бит!

Менә бер хокуксыз гаилә: “Гыйззәтуллина Мәшәррәфә, 1883 елда туган, гаиләсендә 8 җан, шуларның берсе – 5, икенчесе 12 яшьлек бала. Хуҗалыгында өе, аты, сыеры бар. Революция чаклы йорт хуҗасы 3-4 дисәтинә җирне арендага алып чәчкән, тегермәнче булган, чана ясаган, патент алып 1929 елга кадәр сәүдә иткән. Революциядән соң да 4-5 дисәтинә җирне арендага алып чәчкән. 100 пот ашлык тапшыру заданиесенә тартылган, 55 потын тапшырган. 35 сум 40 тиен күләмендә авыл хуҗалыгы налогы түлисе калган”. Минзәлә район халык суды 1931 елның 17 ноябрендә М.Гыйззәтуллинаны бер ел мәҗбүри эшкә тартырга карар кыла.

Икенче типкәләнгән гаилә: “Гыйльметдинов Фәрдетдин, 1884 елгы, гаиләсендә 6 кеше, хуҗалыгында өе, аты, сыеры һәм 2 сарыгы бар. 1929 елга кадәр чана ясаган, патент алып сәүдә иткән. Ашлык тапшыру буенча 100 пот заданиенең 48 потын тапшырган”. Район халык суды аны 7 ай мәҗбүри эшкә тартырга хөкем иткән.

Өченче хокуксыз гаилә: “Вәлиев Һади, 1885 елгы, урта хәлле крәстиян, гаиләсендә 3 кеше. Ашлык тапшыру заданиесе – 60 пот, шуның 23 потын тапшырган”. Район халык суды Һадины 7 ай мәҗбүри эшкә хөкем иткән...

Болар кебек – хокукларыннан мәхрүм ителгәннәр Тулбайда 27 гаилә исәпләнгән, тора-бара 32 гә җиткән. Йә ата-бабасы мулла, йә әтисе хәлле крестиян булган өчен генә “контыр” саналган һәм сайлау хокукларыннан мәхрүм ителгән бичаралар һәрбер авыл саен “тезелешеп” торган. Йә санагыз: Күзкәй авылында – 56, Тулбайда – 42, Ырыста – 11, Дәвектә – 47, Гөлектә – 53, Иске Байларда – 34, Туерда – 25, Калмияда – 27, Яңа Байларда – 7, Колышта – 11, Батракта – 4, Калмашта – 25, Тауасты Тәкермәндә – 46, Югары Тәкермәндә – 64, Хуҗаматтә – 23, Югары Байларда – 18, Боерганда – 23...

Ә кулакка чыгарылып, байлыклары соңгы бакыр тиененә чаклы талап алынган, үзләре ярым шәрә көенчә Себергә сөрелгән крестияннарны “яңа хакимият коллары” дип атау да ялгыш түгел. Мисалга, менә, “халыклар атасы сөекле иптәш Сталин” фатихасы белән, Татарстан Үзәк Башкарма комитетыннан Минзәлә кантонына төшерелгән күрсәтмәдән юллар:

“Саклык кенәгәләре, дәүләт заемы облигацияләре кулакларның өч төреннән дә тартып алынырга тиеш. Конфискацияләнгән наличный акчаларны ашыгыч рәвештә Дәүләт банкының филиалларына китереп тапшыру мәҗбүри. Бу средстволарны кантон һәм район ихтыяҗларында файдалану катгый тыела. Кулаклардан тартып алынган саклык кенәгәләре ашыгыч рәвештә Республика саклык кассасына юлланырга тиеш”. Татарстанның ЦИК рәисе Моратхуҗин, ГПУ башлыгы Кандыбин, наркомфин Татищев, Татарстан прокуроры Филиппов кул куйган мондый күрсәтмә-боерыклар түбәнгә елга-инешләр шикелле агылып торган. Ә кантон белән районнарның үзләрендә дә “тугры сталинчылар” су буе бит әле! Алары да “иң-иң түбәннәргә” боерыклар юллауда саран түгел.

“Яшерен. Ашыгыч. Күзкәй вулбашкарма рәисенә. Сезнең вулыста якынча ... кулак хуҗалыгы бар. Сөрелүче кулак гаиләләре үзләре белән балталар, пычкылар, тимер һәм агач кәрәкләр, агач эшкәртү кораллары, камытлар, шлеялар, йөгәннәр алып китәргә тиеш. Раскулачивание турында биш көн саен мәгълүматлар бирергә. Павлов, Уразаев”.

“Сыйнфый көрәшнең кискенләшүе сәбәпле авыллардагы кулаклар һәм алар яклы кешеләр тарафыннан икмәк амбарларына ут төртүләр булырга мөмкин. Сакны көчәйтегез”.

Инде явызлардан-явыз, кансыз фәрман: “Гаять яшерен һәм ашыгыч! Икенче категориядәге кулак гаиләләре 24 апрельдә Хуҗәмәт авылына туплана. Аларны сез 17 сәгатькә китереп җиткерергә тиеш! Кантон башкомитет рәисе Фазлыев. Сәркатип Уразаев”.

Гаепсезгә туган җиреннән куылучы крестияннарны 25 апрель төнендә үк җәяүләп, штыклар белән куа-куа, эшелоннарга алып китәләр. Аннары поезддагы мал вагоннарында еракка, котыплы Себергә... Ә колхозга керүчеләргә хезмәт көненә – “таяк”. Әмма шәхси йортың, лапас-мунчаң өчен салымны үзең үстергән мал ите, йомырка, йон бәрабәренә кичектерми түлә!..

Түзгән безнең халык. Бернинди ирек, азатлык, бәхет күрмичә яшәсә дә, афәтләрен дә, сугыш гарасатларын да кичергән. 1941 елның 22 июнь таңында башланган Бөек Ватан сугышы да дөньяны урталай бүләргә хыялланган Гитлер белән Сталин дуслыгының каһәрле җимеше булды. “Риббентроп-Молотов пакты” буенча Польшаны, Балтыйк һәм Карпат буйларын бүлешүдән башланган килешү бәйдән ычкынган Гитлерның Советлар иленә басып керүе белән тәмамланды. Җир шарында моңарчы күрелмәгән сугыш халыкны “Бөтенесе дә – фронт өчен, һәммәсе дә – җиңү өчен!” дигән девиз астында көч куярга мәҗбүр итте. Михнәттән башлары чыкмаган авыл кешеләре шул җиңү хакына һәр хуҗалыктан 40 ар килограмм ит, ике йөзәр литр сөт, йөзәр данә йомырка җыеп тапшырырга мәҗбүр булды. Авыллар бер генә трактор һәм машинасын да калдырмыйча, аларны фронтка озатты. Көннән-көн күбрәк рәвештә тол кала барган хатын-кызлар һәм аларның ярым-ятим балалары үгез, сыер, хәтта бозау да җигеп, иген икте, җилкәләренә капчыклар асып, Әгерҗе тимер юл станциясеннән тоз яки 45-50 чакрымдагы Курья амбарыннан чәчүлек ашлык ташыды. Шул газаплардан тыш әле Минзәлә районы халкы яңа самолет һәм танклар өчен 8 миллион да 300 мең сум акчасын җыеп, аны фронт мәнфәгатьләренә озатты. Таулар авылының гына да 70 тән артык ир-егете сугыш яуларына китеп, кан түкте. Анда башын салган авылдашлар да, киләчәк буын хакына дип тылда көч куйган якташлар да күңелләрдә һәйкәл булып яши.

Рәис ГАБДУЛЛИН,
Вахит ИМАМОВ.

“Тарихың тирән, Тауларым!” китабыннан.

Башбирмәс Аксакал

Татарстан Аксакаллар шурасы рәисе, Бөтендөнья татар иҗтимагый үзәге президиумы әгъзасы, аның актив эшчәнлеге катнашында төзелгән "Миргазиян" мәчетен гамәлгә куючы җәмгать эшлеклесе – Рәүф әфәнде Абдулла улы Ибраһимов 80 яшьлек гомер бәйрәмен каршылады. Милли җанлылыгы булган милләттәшләребез арасында, аны белмәгән кеше юктыр дип уйлыйм.

Рәүф әфәнде, туксанынчы елларда татар иҗтимагый үзәге оештырылуның беренче көннәреннән үк башлап җибәргән эшчәнлеген хәзерге көннәрдә дә дәвам итә. Конституциядә бирелгән миллилек хокукларыбызның үтәлешен таләп итеп, төрле югарылыктагы җитәкчеләргә, депутатларга, президентларга милләтнең зарларын белдереп язып тора. Миллилегебезне яклап оештырылган митингларны алып баручы буларак, халыкка бик кирәкле мәгълүматны җиткереп тора.

"Звезда Поволжья" газетасының һәр санында диярлек аның репликалары һәм көн кадагына туры килгән мәкаләләре басыла. Халыкчан карашлы "Безнең гәҗит"тә дә, аның миллилегебезне яклап язган кыю фикерле мәкаләләрен укып торабыз.

Рәүф әфәнде, һич ару-талу белми: аның тырышлыгы белән дөнья күргән китапларны барлап үтик әле:

"Казан ханнарының җәсәдләрен җирләү", "Кабан шәһәрчеге ягъни Казан ханнары резиденциясе", "Пародияләр", "Ихласи Миргазиян", "Вафа хәзрәт Гыйлаҗый", "Касим хәзрәт Нуруллин", "Әхмәт Зәки хәзрәт Сафиуллин" һ.б.

Кызганыч, булдыклы, милли җанлы шәхесләребезгә хөрмәт күрсәтеп, аларның хезмәтләрен бәяләп, юбилей кичәләрен хөкүмәт югарылыгында үткәрүләр каралмаган. Бер тиен хезмәт хакы алмыйча, хәзерге көннәргә кадәр эшләп торган, суверенитет алуда иң зур тырышлык куйган милли хәрәкәт вәкилләрен кыерсытып яшәү гаҗәп хәл түгелмени?

Без, Татарстан Аксакаллар шурасы әгъзалары һәм милли хәрәкәттә катнашучылар, булдыклы һәм хөрмәтле җитәкчебез – Рәүф Абдулла улы Ибраһимовны 80 яшьлек юбилее белән ихлас күңелдән тәбриклап, алдагы көннәрдә дә милләтебезгә хезмәт итеп яши торган хәерле гомер теләп калабыз.

Рәфкать ИБРАҺИМОВ.

Фәтхулла АБДУЛЛИН

Соңгы сәяхәт

Кайчандыр бер табактан ашаган туганнар бу хәлгә төшәр дип кем уйлаган.

Башта ару гына гәпләшеп, дөнья хәлләрен сөйләшеп утырды алар. Шуннан соң гына Кадыйр йомышын әйтте:

– Абый, әйдә, машинаң белән кайтып, әтинең каберенә чардуган корып килик әле.

Ул сәламәтлек өчен зыянлы цехта эшләп, илле биш яшьтән пенсиягә чыгарга әзерләнеп йөри. Яше турында белешмә кирәк булгач, күптән түгел генә авылына кайтып килгән иде.

Сәхби өстәл өстендәге төпчек савытына сөялгән калай кисәгенә ымлады:

– Машина төзек түгел.

Кадыйр да шул калай кисәгенә күз төшереп алды. Абыйсының кәефе күтәренке чагында, диванга кырын төшеп, машина номерына карап ята торган гадәтен ул белә иде. Нишлисең, һәркемнең бер яраткан шөгыле була бит инде.

– Нәрсәсе төзек түгел соң аның?

– Карбюратор эшләми.

Энесе илленең өске ягында булса да, җәһәт кенә сикереп торды.

– Әйдә карыйк әле. Мин дә техниканы әзрәк беләм бит.

– Карбюраторын гына түгел, моторын да карыйсы бар. Быел Кырымнан кайтканда да төчкереп тенкәгә тиде.

Әйе, Сәхби сәяхәт итәргә ярата анысы. Ел саен, кая да булса барып, ял итеп кайта. Инде күрмәгән җире дә калмагандыр. Әле бүген дә, соңгы сәфәрендә күргән мажараларын сөйләп, энесен көлдереп алды.

Кадыйр тагын телгә килде:

– Әйдә әле. Мотор сүтеп җыйган бар минем.

– Соң бит инде.

– Соң дип... Гаражыңда ут бардыр ич?

Сәхби аның сүзләрен әллә ишетмәде, әллә ишетеп ишетмәмешкә сабышты, дәшмәде.

Картлык кемгә дә шатлык түгел шул. Әле үткән атнада гына, аяклар сызлый, дип зарланып торган иде. Инде колагы да катылана башлаган бугай моның, дип, абыйсын җәлләп куйды энесе эченнән генә.

Өч аршин җиргә Кадыйр үзе дә чардуган кора алган булыр иде, билгеле. Әтисен җирләгәндә укучы бала гына иде шул – урынын хәтерләп кала алмады. Хәер, сугыштан соңгы ачлыкта – кәнаралаш үлем-китем булып торганда, кая инде ул чардуган корулар... Һәркемнең үз хәле хәл. Мәрхүмнең баш очына имән казык кагалар да китәләр иде. Исәя төшкәч, аны ФЗӨгә җибәрделәр. Аннары, дөнья куып, бу турыда бөтенләй онытылды.

Еллар үтеп, менә шул уч төбе кадәр белешмә кирәк булгач, туган якка кайту Кадыйрның күңелен айкады да ташлады. Ул, ни өчен икәнен үзе дә аңламастан, зиратны әйләнеп чыкты. Әнисенең каберенә карап, озак кына уйланып торды. И гомерләр, гомерләр... Кабер өстендәге тупыл күккә үрләгән. Тимер рәшәткә бөтенләй тутыгып беткән – нинди төскә буялганын да белерлек түгел иде. Ә менә ничаклы гына эзләсә дә, әтисенең каберен тапмады... Кадыйр әллә каян, күкрәк түреннән, бәгырьне телгәли торган инрәү авазлары чыгарып ыңгырашып куйды:

– И-эх!..

Дөньялар рәтләнгәч булса да, ник кайтмаска инде югыйсә, ә? Ник кайтмаска?..

Кадыйр уйларыннан арынып башын күтәрде.

– Сине бит авылда әтинең каберен беләдиделәр.

– Капка ягыннан уналтынчы багана турында инде.

– Ул гомердән бирле ничә тапкыр койма баганаларын алыштырганны беләсеңме соң син?

Сәхби әллә ишетмәде, әллә... тагын җавап бирмәде, диванга кырын төшкән килеш кенә шырпы кабын чөеп уйнарга тотынды. Аның бу кыланышы Кадыйрның ачуын китерә башлады. Ни өчен туган авылга кайтырга теше-тырнагы белән карыша соң әле бу, дип уйлады ул күңеленнән генә. Ни өчен? Әти кабере турында сүз бара лабаса монда...

– Әйдә кайтып килик инде, – дип үгетләвен дәвам итте ул, әле һаман аның йомшаруына өметен өзмичә. – Мин Мөбарәк абый белән сөйләштем. Ярдәм итәрмен, диде.

– Куйдырсыннар. Әти бит бөкресе чыкканчы колхозда эшләде.

Анысы хак инде дип килеште Кадыйр күңеленнән генә. Кайбер кешеләр сыман көн үтсенгә генә йөрмәде, булсын дип эшләде. Шул риясызлыгы өчен аны авылда олысы-кечесе хөрмәт итте.

Шырпы кабын чөю Сәхбине туйдырды бугай, ул аны өстәлгә ташлады да, торып телевизорын кабызды. Анда яшелчәләрен черетеп яткырган база җитәкчесен тәнкыйтьлиләр иде.

– Болай кимчелекләрне экранга чыгарып, үзебезнең авторитетны гына төшерәбез ич без, – дип сукранырга керешге ул, ризасызлыгын яшермичә.

– Барысын да ал да гөл итеп күрсәтү, синеңчә, әйбәтмени? – диде Кадыйр аңа каршы. Ул, абыйсын «тешләп алырга» җай чыкканга куанып, мыек астыннан гына елмаеп алды. – Халык сукыр түгел...

Сәхби, бик зур сер сөйләгәндәй, тавышын түбәнәйтте.

– Телевизорны хәзер кем генә карамый. Дусы бар, дошманы...

– Дошман, имеш!.. Тырнак астыннан кер эзләп гомерең үтте инде.

Сәхби тиз генә җавап бирмәде, өстәл астында утырган шешәдән аракы салып эчте дә, бөкесен ябып, кире урынына шудырды. Аннары телевизор каршыннан китеп газеталар караштыра башлаган энесенә төбәлде.

– Бернәрсә дә аңламыйсың син, Кадыйр. Яши дә белмәдең.

Кадыйр, абыйсына җавап кайтарганчы, бераз уйланып торды. Әйе, чыннан да, тормышның рәте-чиратлары булмады бугай шул. Кая җибәрсәләр, шунда барып, ни кушсалар, шуны эшләп йөрде, кешеләр сыман машина да ала алмады. Бар тапкан-табыннаны бер-бер артлы дөньяга килгән балаларына китеп барды.

(Дәвамы бар).

Татарстан һәм Казахстан: уртак тамырлар һәм үзгәлек

Хәзер татарлар да, казахлар да үзләрен Алтын Урданың төп варислары дип күрсәтә. Моңарчы Алтын Урданың көнбатыш өлеше, ягъни Ак Урда варислары – татарлар, ә көнчыгыштагы Күк Урда варислары – казахлар диген ниндидер үзара аңлашылган компромисс бар иде кебек. Әмма соңгы елларда казах фәнни элитасының бер өлеше бу фикерне кире кагуын көчәйтә һәм бәйсез дәүләт шартларында мөмкин булган зур финанс ресурсларын казахларны Алтын Урданың төп варислары итеп танытуга юнәлтә. Сәяси яктан Мәскәү контролендәге, тарих фәнен үстерүдә максатлы стратегиясе булмаган һәм акча кытлыгы кичерүче Татарстан исә моңа каршы тору өчен элеккедән калган мөмкинлекләрен генә кулланырга мәҗбүр.

Ә менә узган ел ахырында үзбәкләр Самарада Аксак Тимергә һәйкәл куярга җыенуны игълан иткәч, көтелмәгәндә татарларның да, казахларның да сәяси-тарихи мәнфәгатьләре бер-беренә туры килүе аңлашылды. Татар тарихында яман эз калдырган бу кешенең исемен шул рәвешле мәңгеләштерү ниятенә татарлар да, казахлар да кискен каршы чыкты.

Казахларның Алтын Урдадагы татарлар урынына дәгъва итүе аларның Казахстанның төньягында һәм Россиянең казахлар тупланып яшәгән кайбер төбәкләрендә элек-электән яшәвен нигезләү теләге белән дә аңлатыла. Ә чынлыкта хәзерге казах дәүләтчелегенең башлангычы булган Казах ханлыгы Алтын Урдадан түгел, ә XV-XVI гасырда шактый көньякта оешкан Чагатай Олысыннан ярала.

Алтын Урда чоры өчен үзара шундый тарткалаш булса да, татарларның XIX гасырда казахларның социаль үсешенә зур өлеш кертүен кире кагучылар юк. Исламның казахларга тәэсире формаль рәвештә генә булган ул чорда татар имамнары аларның тормышында исламның ролен көчәйтүгә күп көч куя. Татар имамнарының миссионерлык чорында хәзерге Казахстан җирләрендә мәчетләр генә түгел, дистәләрчә мәдрәсә дә ачыла. Казахларның киләчәк элитасы татарлар тәэсиркән, җәдидчелек юнәлешендә белем бирүче шул мәдрәсәләрдә белем ала. Уфадагы «Галия» мәдрәсәсенең роле аерыча зур була. Анда казах халкының киләчәк элитасы уку белән беррәттән, кыргыз һәм казах балалары өчен гарәп имласындагы беренче әлифба басыла, 1913-1914 елларда казахларның кулдан язылган «Садак» журналы чыга.

Казахларның Алаш автономиясе дип аталган беренче тупраклы автономиясе татарларда да шундый ук хәрәкәт булган чорда, 1917 елда төзелә. Алаш автономиясе төзелү икенче Бөтенкыргыз корылтаенда (1917 елның 18-26 декабре) игълан ителә. Ә бер ай алданрак 1917 елның 20 декабрендә Уфада татар халкы Милләт мәҗлесе Идел-Урал штатын игълан итә. 1919 елда Кыргыз крае, ә 1920 елның августында хәзерге Казахстанның зур өлешен үз эченә алган Кыргыз АССР (1920-1925) төзелә. 1924 елда кыргызлар аннан аерым республика булып аерылып чыга. 1920 елның маенда хәзерге Татарстан җирләрендә ТАССР төзелә.

Татарларның союздаш республика статусына ирешү өчен көрәше «солтангалиевчеләр» эше, ягъни фирка эчендәге беренче киңкүләм «чистартулар» белән тәмамлана. 1937 елгы Сталин конституциясен кабул итү алдыннан булган икенче омтылыш та кире кагыла. Казахларның язмышы исә бәхетлерәк була һәм 1936 елның 5 декабрендә Казах АССР хәзерге Казахстан җирләре белән РСФСРдан аерылып чыга һәм, тулы хокуклы союздаш республика статусын алып, Казах ССР дип атала башлый. Татарстан исә Совет берлеге җимерелер алдыннан тагын бер омтылыш ясап карый, әмма анысында да Россия кысаларында калып, үз хокукларын күпмедер дәрәҗәдә арттыруга гына ирешә ала.

Совет чоры үзенең ахырына якынлашканда, казах милләтчелеге сәяси фактор буларак сизелә башлый. Мәсәлән, 1979 елгы Целиноград (1961-1992 елларда исеме шул рәвешчә саклана, хәзер Нур-Солтан) вакыйгалары. Анда казахлар үз республикаларында алманнарга автономия өлкә бирү идеясенә каршы митингларга чыга. Ә Совет берлеге таркалуның 30 еллыгы һәм бу ел башындагы хәлләр уңаеннан иң еш искә төшерелгәне – 1986 елның декабрендә Алматыда булган бәрелешләр. Ул чакта казахлар Мәскәүнең Казахстан коммунистлар фиркасе үзәк комитетының беренче секретаре вазифасына Геннадий Колбинны китереп куюына каршы күтәрелә. Иминлек көчләре белән бәрелешләрдә барлыгы 170-200 кеше һәлак булган дип исәпләнә. Күп кенә белгечләр бу вакыйганы ул чакта Казахстан хөкүмәтен җитәкләгән һәм республикадагы әлеге иң югары кәнәфигә утырырга теләгән Нурсолтан Назарбаев эшчәнлеге белән бәйли.

Шушы ике күтәрелешне берләштереп караганда, аларның барысы да казах халкында ресурсларны көчәйтү теләгенә нигезләнгән дияргә була – хакимият, финанс һәм башка ресурсларны туплап, казахларның республикадагы тәэсирен арттыру. Әмма сүз республиканың хокукларын арттыру һәм һич тә бәйсезлек алу турында бармый. Балтыйк республикаларында, Грузия яки Әзәрбайҗандагы кебек зур бәйсезлек хәрәкәтләренең Казахстанда булмавы да шуның белән аңлатыла. Казахларның үз бәйсез дәүләтчелекләрен торгызу идеясе тирәсендә тупланган милли зыялыларның ниндидер бер тотрыклы төркеме дә булмый. Шул сәбәпле, Татарстанда Татар иҗтимагый үзәге тирәсендә тупланып республика кысаларыннан читкә дә чыккан татар халык фронтыннан аермалы, казахларның суверенитет өчен көрәш хәрәкәте булмый.

Гомумән алганда, Казахстан Үзгәртеп коруны һәм Совет берлегенең төрле урыннарында күтәрелгән милли азатлык көрәшен сүлпән генә каршылый. Алай гына да түгел, Казах ССРда иң тәэсирле кеше булган Н.Назарбаевның 1991 елда бәйсезлеккә һич тә омтылмавы, киресенчә, Совет берлеген саклап калу өчен тырышуы күпләргә мәгълүм. Ул хәтта 1991 елның декабрендә берлек таркалып, өметләре челпәрәмә килгәнгә кадәр дә, яңартылган Совет берлегенең премьер-министры урынына билгеләнеп, Мәскәүгә күчү турында хыяллана.

Ягъни Казахстан өчен бәйсезлек күктән төшкән «өлгермәгән алма» кебек була. Өлгермәгән дигәндә, анда милли зыялылар тирәсенә тупланган милли хәрәкәтнең оешмавы күз алдында тотыла. Һәм шунда ук бу бушлыкны Н.Назарбаев билгеп ала. Шундый ук тәрәккыят, ватандашлар сугышы башланган Таҗикстаннан кала, Үзәк Азиянең барлык республикаларында да була. Үзгәртеп кору нәтиҗәсендә иҗтимагый тормышта демократия өчен ачылган мөмкинлекләргә карамастан, бу җөмһүриятләрнең берсендә дә чын сәяси көчкә ия милли хәрәкәтләр оешмый. Шуның нәтиҗәсендә исә, анда барлыкка килгән яңа илләр бик тиз арада авторитар режимнар астында кала. Ул режимнар кайсындадыр көчлерәк, Кыргызстанда исә беренче инкыйлаб нәтиҗәсендә үк җимерелерлек йомшак була.

Күп кенә белгечләр фикеренчә, һәм алар бәлки хаклыдыр да, Казахстан казах милләтен булдыру эшенә шушы көннәрдә генә ныклап керешә. Казах милли элитасының Совет берлеге таркалганнан соң иң курыккан нәрсәсе илнең төньяк өлешенең аерылуы иде. «Рус дөньясы» тарафдарлары ул җирләрне «Көньяк Себер» дип атый. Совет чорында анда күпчелекне руслар тәшкил итә, шулай ук шактый гына украиннар, алманнар, татарлар һәм хәзерге Россиядәге башка халыклар да яши, казахлар бик аз була, ә кайбер урыннарда хәтта булмый диярлек.

Бәйсезлек елларында бу куркыныч вәзгыять төзәтелә, моның өчен хәтта илнең башкаласын да көньяк-көнчыгыш читкә якын булган Алматыдан үзәктәрәк урнашкан Астанага (2019 елда Н.Назарбаев президент вазифасыннан киткәч Нур-Солтан дип үзгәртелде) күчерәләр. Совет берлеге җимерелгәнчегә кадәр күбрәк авыл җирләрендә яшәгән, башкаларга караганда күбрәк бала табучы казахларның шәһәрләргә күченүе дә моңа ярдәм итә. Шулай ук, казах булмаган халыкларның акрынлап Россиягә күченүе дә күзәтелә. Әмма кайбер башка элекке совет республикаларыннан аермалы буларак, күпләп күченүләр булмый. Хәтта күченеп киткән руслар да бер өлеше, республикада икътисади вәзгыять тотрыклылангач, кире кайта. Һәрхәлдә төньяк җирләр мәсьәләсе хәл ителә. Әмма болар – этник миграция мәсьәләләре генә.

Ә казахларның дәүләт дәрәҗәсендәге милләт булдыру эше берничә ел элек кенә башланды. Моңа 2014 елдагы Кырым вакыйгаларыннан соң Россиядәге югары җитәкчеләрнең казахларның үз дәүләте булмаган диген сүзләре этәрде. Шуның нәтиҗәсендә тарихи мирасны фәнни дәрәҗәдә генә түгел, кинематограф аша да таныту эшенә күбрәк игътибар бирелә башлады. Милләт төзү эшенең иң югары ноктасы былтыр казах телен кирилл хәрефләреннән латин язуына күчерү булды. Россия казах теленә бәйле бу үзгәрешне андагы русларның хокукларын бозу дип күрсәтергә тырышса да, ул тема тиз арада онытылды һәм аны хәзер Россиянең пропаганда медиасы гына күтәргәләп ала.

Гыйнвар вакыйгалары казах милләтен кору эшендәге иң йомшак урынны күрсәтте. Ул – ырулар бүленеше, ягъни бер этнос эчендәге төрле ыруларга бүленү. Казахлардагы бу күренеш борынгы тарихтан ук килә. Анда этник яктан да чыгышлары белән төрле булган өч жүз (казах ыруларының борынгы берләшмәләре) – Өлкән, Урта һәм Кече жүзләр XVIII гасырда берләшү нәтиҗәсендә Казах ханлыгы төзелә һәм ул соңрак Россия империясенә кушыла. Казахстан бәйсезлеге чорында ырулар бүленеше бетми, киресенчә, көчәя генә. Казахлар бу ырулар бүленешен дөрес һәм хәтта казах этномилләтенең өстенлеген күрсәтүче, «чын күчмә халык» рухын саклауда ярдәм итүче күренеш дип саный. Ләкин бу һич тә уникаль күренеш түгел, һәм милләт оешу барышында, җәмгыятьтәге тәрәккыят кануннары нигезендә, ул юкка чыгарга тиеш. Шуңа күрә ныклап оешкан һәм тулысынча танылган милләтләр арасында андый ыру бүленешләре юк. Казахстанда исә дәүләт бер яктан бердәм казах милләтен оештырырга тырышты, һәм шул ук вакытта хакимияттәге элиталар ырулар бүленешен сәяси практика буларак саклап калуны алга сөрде.

(Дәвамы 18 нче биттә).

Оренбург шәле челтәрле бизәк,
Кышкы юллар төсле каймалар.
Язларымны хәтерләтә торган
Андый шәлләр тагын кайда бар?
Сибгат Хәким.

●Әбсәләмовлар гаиләсе.

ОРЕНБУРГ

Халык җырларына кергән Оренбург шәлләрен кем генә белми дә, аның нәфис, җылы челтәрләренә төренеп хозурланасы килми икән? Оренбург шәлләре өчен кулланa торган кәҗә мамыгы да, ак болытларга охшап, күңел дигәнен әллә кайларда йөртә...

Дөнья күләмендә данланган нәфис Оренбург шәлләрен бәйләү сере гасырлар дәвамында буыннан-буынга тапшырылып килгән. Элек-электән бу яклардагы татар авылларында кызларны, ә кайвакыт малайларны да, мәктәпкә кергәнче үк, шәл бәйләргә өйрәткәннәр, бу һөнәр тормыш алып баруны җиңеләйткән. Өлкәнең Переволот районы Зубочистка авылында да шулай. Мәгъмүрә әбисе оныгы Альбинаны («Оренбург шәлчеләре» предприятиесенең директоры Альбина Фаил кызы Әбсәләмова) да алты яшеннән шәл бәйләү серләренә өйрәтә башлый. Ә әбисе белән әнкәсе – шәл бәйләүнең тирә-якта дан алган осталары. Аларның шәлләре бизәкләре һәм нәфислеге белән күз карашын уятырлык. Аңлашыла ки, бер урында озак утырырга яратмаган, табигатьтән бирелгән холкы белән тиктормас кызчыкның һич кенә дә бәйләү инәләренә карап утырасы килми. Ул әле курчаклар белән әвәрә килергә, иптәшләре белән урамда уйнарга ярата. Әмма әбекәйне тыңламыйча булмый, кызчык шәл каймасын бәйләп утырырга мәҗбүр. Нәселдән килгән осталык күчәме, кулы да көннән-көн йөгерекләнә, әнисе кебек нәзек итеп җеп эрләргә дә өйрәнә. Ниһаять, кызчык җиде яшендә беренче шәлен бәйләп чыга. Аны саткан акчага кызга беренче сыйныфка бару өчен мәктәп формасы алалар. Тора-бара Альбина да шәлләр бәйләүдә остара. Ул бәйләгән шәлләрне мәктәптә осталык бәйгеләренә куялар, олимпиадаларга чыгаралар. Альбина үзе бәйләгән шәл белән «Молодое дарование» Бөтенроссия конкурсында да җиңә.

1990 еллар – илдә сәясәт алмашынып, бериш предприятиеләр таркалган, икътисади хәл дә мөшкелләнгән чор. Бу елларда Зубочистка авылы татарлары шәл бәйләүне арттыра. Телевизор караганда да, күрше-тирә белән кичләрен әңгәмә корганда да куллары эштән туктамый. Альбина да һәр буш вакыты табылды исә, инә белән җеп алып, эшкә тотына. Шәлләрне сатып, кием-салым алалар, шулай итеп гаиләгә дә күпмедер файда килә...

Альбина шәл бәйли-бәйли медицина көллиятендә дә укый, 18 яшендә кияүгә дә чыгып куя. Ире Фаил, шәһәр егете булса да, кәҗә мамыгы, шәл бәйләү дигән төшенчәләрне үз тәҗрибәсеннән чыгып белә. Аның әтисе гомере буе Оренбург мамык (пух) фабрикасына чимал хәзерләүче булып эшләгән, улы Фаилне дә үзе белән йөрткән. Әтисе улына дебетне (бу якларда кәҗә мамыгы шулай атала) классификацияләргә өйрәткән. Егет дебет сыйфатын бәяләү нечкәлекләрен кечкенәдән үк белеп үскән. Килен кайнана туфрагыннан була диюләре дә хак, ахры. Кайнанасы Нәсимә дә матур-матур шәлләр бәйләп гомер иткән.

Альбина белән Фаил бергә укый, ир менеджмент буенча югары белем ала, хатыны көллиятне тәмамлап, хастаханәдә эшли башлый. Фаилнең, Альбина кияүгә чыкканда өе, машинасы булса да, яшьләргә тормыш итәргә сәмән кирәк. Әмма акча дигәннәре житми, шәфкать туташының биш меңлек хезмәт хакы җан асрарлык түгел. Альбина белән Фаил озак киңәшә, отышлы гамәл юрый, ниндидер эш башлыйсы килә, шиналарны монтажлау эшен көйләп тә, автокибет тә ачып карыйлар. Сөйләшүләр исә һаман да үзләре белгән һөнәргә барып тоташа, Альбинаның кечкенәдән өйрәнгән эше дә искә төшерелә. «Мин шәл бәйли беләм, әнкәем шул эшнең остасы», – дип ул. Шул арада беренче бала да дөньяга аваз сала.

2001 елда алар, үзләре дә сизмәстән, шәл бизнесына кереп китәләр. Әбсәләмовларны көтмәгәндә Мәскәүдә узган Бөтенсоюз халык казанышлары күргәзмәсенә чакыралар. Әлбәттә, витриналарда берсеннән-берсе матур шәлләр торуын теләгәннәрдер, Альбинаның мәктәптә укыганда «Молодое дарование»дә катнашуын искә алып, аны үзләрендә калган элемтәләр белән эзләп тапканнар. Шәлләрен алып, уларын әнкәйләренә калдырып, яшьләр Мәскәүгә юнәлә. Шулай итеп аларны күргәзмәләр дөньясы үз эченә бөтереп ала. Башта Россия төбәкләрендә, алга таба Гарәб Әмирлекләре, Казахстан, Германия, Италия кебек илләрдә үткәрелгән халыкара күргәзмәләрдә катнашалар. Әүвәл үзләре бәйләгәннәрне генә сатып кайталар. Гаиләгә акча керә башлый. Шәл сорап мөрәҗәгать итүчеләр дә барлыкка килә, сорау арта. Инде гаиләнең һәм әнкәйләренең бәйләгәне генә җитми, туган-тумачалардан җыеп бара башлыйлар. Берәр ел шулай эшлиләр. Әмма, хезмәт күп куелса да, бу алым әллә ни табыш китерми. Бер шәлне бәйләү өчен тотылган мамыкны аялау, тарау, эрләү вакытларын исәпләсәң, 400 сәгать таләп ителә. Юлына, урынына түләгәч, кергән акчасы ташка үлчим кала. Гаиләдә исә һаман ничегрәк эшләсәк әйбәт булыр икән, дип киңәшләшү бара. Эшмәкәрлекне ныгытырга дигән фикергә киләләр. Дебет сатып алалар да, аны яз көне, авылларда яшәүче хатын-кызларга таратып, җәй буе шәл бәйләтәләр. Сентябрьдән март ае башларына кадәр вакыт - шәлчеләрнең әзер тауарны сату сезоны. Дебет елына бер генә тапкыр әзерләнә, аны мамык кәҗәләреннән март азагында, апрель башында тарыйлар. Әбсәләмовлар дебетне сатып ала, үзләре юа, тетә, кылларын чүпли, аялый, аннары әзер мамык авыллардагы оста бәйләүчеләр кулына күчә. Шуннан соң әзер шәлләрне җыеп алып юалар, тарттыралар. Алга таба булышчы хатын-кызлар да кирәк була башлый...

Һәрбер авылның шәл бәйләүдә үз бизәге, үз алымы. Әйтик, Саракташ районында элек-электән бары тик җылы шәлләр генә бәйлиләр, челтәр шәл бәйләүне үз итмиләр. Ә инде күршеләрендә, киресенчә, челтәр, нәфис шәлне кулай күрәләр. Һәр авылда тирә-якка мәгълүм эш остасы була. Альбина йөри-йөри тегеяки бу авылда кайсының әйбәт бәйләгәнен күрә, хәтта шәлгә күз төшерү белән, аның кем кулы аша үткәнен һич ялгышусыз танырга өйрәнә. Әбсәләмовлар өлкә авылларыннан иң оста шәл бәйләүчеләрне җыеп предприятие булдыра. Һәрбер авылда оста бәйләүче биш-алты кеше табыла. Андыйларның исәбе, туплый торгач, 100 дән арта. Әмма пандемия кайбер оста шәлчеләрне дә алып китә. «Бу - 20 ел дәвамында алып барылган хезмәт нәтиҗәсе инде. Хәзерге вакытта 104 шәл бәйләүче белән эшлибез», – ди Альбина ханым. Әмма эш елдан-ел кыенлаша, тауар әйләнеше арта. Шәлләрне сату өчен күп йөрергә кирәк, үзләре генә чималны эшкәртеп өлгерә алмыйлар. Элек бәйләүчеләр шәлләрне шампунь салып өйдә юа, киерә торган булса, хәзер тормышлар яхшыргач, берсенең дә керне өйгә кертәсе, пычрак эш белән шөгыльләнәсе килми. Нәтиҗәдә юуларының да сыйфаты начарлана, кылларын тиешенчә чүпләми эрләү гадәткә керә, тигез эрләнмәгән дебеттән яхшы сыйфатлы шәл килеп чыкмый. Чөнки җеп бер утыруда шәллек эрләнми икән, аның нечкәлеге үзгәрә, мондый җептән матур шәл килеп чыкмый.

Шуңа да Альбина белән Фаил 2014 елда, мамыкларны эшкәртү, җеп эрләү цехын булдыру хасиятенә керешә. Эшне бина арендалаудан (берничә елдан үзләре дә салып чыгалар) башлыйлар, анда кирәкле җиһазларны алып урнаштыралар. Барлык пычрак эш шунда башкарыла: мамык юыла, аялана, тарала. Әмма цехның эше беренче елларда ук бик әйбәт килеп чыкмый. Әбсәләмовлар, үз хаталарыннан сабак алып, җайлап, эшне камилләштерә бара. Алар 2015 елда Италиягә барып, үрнәккә Оренбург ягы кәҗәләренең мамыгын биреп, килешү төзеп кайта. Итальяннар шул дебеткә ярашлы итеп, Әбсәләмовлар теләгән машиналарны эшләп бирә. 2016 елда техника Италиядән кайтартыла. Хәзер цехта биш заманча машина гөрләп эшли. Аларның берсе дебетне иләк аша үткәреп кылдан аера, ул мамыктан авыррак булгач, аска төшеп китә, ә өстә ак болыт кебек дебет күпереп кала. Фабрикада хәзер сыйфатлы җеп эрләнә. Алар шушы ук цехта салават күперенең барлык төсләренә маныла. Бу – Россиядә бүген шундый табигый дебеттән җеп эрләтә һәм бары тик кул белән генә бәйләнгән шәлләр, башка кием-салым әзерләп чыгара торган бердәнбер предприятие. (Оренбургта шәлләр җитештерүче икенче бер предприятиедә шәлләр машина белән бәйләнә). Тора-бара шәлләрне ел әйләнәсе сату да җайга салына. Әбсәләмовлар Оренбургта үзләренең фирма кибетләрен дә булдыра. Бүген әзер продукцияне халыкка җиткерү өчен берничә кибетләре эшләп тора, икесен кибет-музей итеп җиһазлаганнар. Күптән түгел «Оренбург шәлчеләре» предприятиесе Казанның «Туган авылым» комплексында да үз сату ноктасын булдырды.

Оренбург дебете утыра торган сыйфатка ия. Мамыкны дөрес итеп эшкәртмәсәң, бәйләнгән тауар кечерәергә, формасын югалтырга мөмкин. Шәлләрнең 20 ел буе киелүен теләгән Әбсәләмовлар бу мәсьәләне дә

ШӘЛЛӘРЕ

уңай хәл иткән. Оренбургта машина заводында аларга автоклав эшләп биргәннәр. Башта дебетне технология буенча югары температурада киптереп утырталар да, аннары андый мамыктан бәйләнгән шәл хәлендә формасын югалтмый.

«Оренбург шәлчеләре» предприятиесе ассортименты гаять бай: 3200 төрдәге тауар житештерелә. Алар арасында кием-салым да, кардиганнар, җылы һәм челтәр шәлләр, шарф, палантин, өчпочмаклы косынкалар, бармакча-бияләйләр, баш киемнәре, хәтта бизәнү әйберләре дә бар. Бер исемдәге тауарлар да бер-берсен кабатламый, катлаулылыклары, төсләре, бизәкләре белән аерыла. Арада эксклюзив, авторлык эшләре дә бар...

Әбсәләмовлар ел саен өч тоннага якын дебетне «Донской» дигән шәхси хуҗалыктан сатып ала. Әмма соңгы елларда аның хуҗасы булган абзый олыгая, кәҗәләрне улына калдыра. Ә ир-егеткә ул маллар кирәкми, файдасы юк, ди. Альбина белән Фаил хафага кала. Чөнки предприятие шәлләрне бары тик Оренбург дебетеннән генә бәйли.

Өлкә җитәкчеләре фестивальләргә, күргәзмәләргә барамы, үзләре белән Альбина белән Фаилне дә чакыра. Затлы кунакларга бүләкләрне дә Әбсәләмовлардан алалар. Чөнки кулдан бәйләнгән асыл шәлләр – өлкәнең бренды исәпләнә. Шуңа күрә «Оренбург шәлчеләре» югары җитәкчеләр белән дә үзара дустанә мөнәсәбәттә эшли. Альбина ханым авыл хуҗалыгы министры, вице-губернаторга керергә, хәлне аңлатырга мәҗбүр була. «Алга таба эшчәнлекне дәвам итү өчен чимал юк», – ди. «Без сезгә булышабыз», – диләр. Шулай итеп «Оренбург шәлчеләре» предприятиесенә грант бирелә. Биш елга 15 миллион сумга якын грант алына (Әбсәләмовлар үзләреннән 10 миллион сум өсти). Янә кызу эш башлана, ферма биналарын төзетәләр. 2020 елда 1000 баш кәҗә тотыла башлый. Бүген предприятиенең 1600 кәҗәсе бар. Әлбәттә, бу гаилә өчен дә күпмедер дәрәҗәдә кыенлыклар тудыра, хәтта 2020 ел Әбсәләмовларның үзләре өчен дә зур сынау чорына әверелә. «Оренбург шәлчеләре» предприятиесе гаилә бизнесы буларак, ир белән хатын кая барса да, бергә юлга чыга, бергә йөри. Хәзер Фаилгә шәһәрдән 200 чакрым ераклыктагы фермага китәргә, бер көн булса да кунып, эшләрне җайлап кайтырга кирәк. Альбина исә предприятиедә эшне алып бару өчен шәһәрдә кала. «Беренче вакытларда, без ул кәҗәләрне ник алдык икән, дип күз яшьләремне дә түккән мәлләр булды. Хәзер ияләшеп киләбез», – ди Альбина ханым. Шулай итеп Әбсәләмовлар ширкәте мамык кәҗәләре асраудан алып әзер шәл бәйләүгә кадәр тулы циклы предприятиегә әверелә...

Соңгы елларда авылларда эш урыннары бетерелүе халык файдасына түгел. Алар арасында шәл бәйләп кенә тормыш алып баручылар бар. «Оренбург шәлчеләре» фабрикасы – авылларның оста куллы шәлчеләре өчен, әлбәттә, уңайлы эш урыны. Шәл бәйләүчеләр еш кына Әбсәләмовларга шатлыклы күз яшьләре белән рәхмәт әйтеп шалтырата. «Сез биргән эш – безнең ипиебез», – диләр. Әмма авылларда хезмәт хаклары түбән булгач, пенсияләрнең дә кечкенә булуы сер түгел. Бәйләүчеләрнең күбесенең лаеклы ялда булуы да шуннан киләдер. Хәзерге вакытта иң өлкән бәйләүчегә – 86, иң яшенә 42 икән. Альбина ханым яшьләрне шәл бәйләүгә утыртып булмавына гаҗизләнә. «Халык та ничектер ялкауланып киткән кебек. Кайбер авылларда акча юк, дип утыралар, бәйлиселәре килми», – ди ул. Әбсәләмовлар Оренбург шәленең даны дәвам итүен, осталык серләренең буыннан-буынга тапшырылып баруын, һөнәрнең дә сакланып калуын тели. Фабрика шәлчеләренә дә алмаш әзерләү кирәк. Шуңа да алар төбәкнең дүрт районындагы мәктәпләрдә, укытучыларына эш хакы түләп, укучыларны шәл бәйләргә өйрәтә. Кайбер мәктәпләрдә атнасына - өч, кайберләрендә дүрт сәгать бәйләү дәресе керә. Бүген 74 бала шәл бәйләү серләренә өйрәнә. Алар арасында малайлар да бар. Альбина ханым аларны кызыксындырырга тырыша, бүләкләр, премияләр биреп, мактап җибәреп үсендерә...

Төбәктә уздырыла торган Шәл туе да бу һөнәргә кызыксынуны көчәйтергә, шәлләрнең сыйфатын тагын да яхшыртырга, бизәлешләрне кабатланмас итеп төрләндерергә ярдәм итә. Альбина ханым «Туй»ны ире Фаилнең абыйсының хатыны, ягъни килендәше белән бергәләп үткәрә. Саракташ районында өч ел рәттән шундый бәйрәмне гөрләткәннәр. Бу көнне шәл турында җырлар яңгырап торган, музыка-бию ямьләндергән залга авыллардан автобусларда килгән шәлчеләр җыела. «Туй»да һәрбер районга мәйданчык бирелә, анда шәлчеләрнең ел буе матур итеп бәйләгән, тырышып әзерләгән эшләреннән күргәзмә ясала. Алар бәйрәмдә үзара таныша, аралаша, тәҗрибә уртаклаша, бер-берсенең каймаларының, челтәр палантиннарының бизәкләрен күрә, аны ничек бәйләве белән кызыксына, өйрәнә. Оештыручылар, эксперт-лар шәлчеләр алып килгән кул эшләрен бәяләп, аларга баллар куеп, урыннар билгели. Шәл туенда яңа гына компаниягә килеп кергән оста шәлчеләр дә исәпкә алына, аларга «Ел ачышы» дигән номинациядә грамоталар бирелә. Яшәүнең яме, хезмәтнең тәме күренеп киткәндәй була. Бәйләүчеләр илһамланып, осталыкларын шомартып, камилләштереп тагын да матуррак шәлләр бәйләргә тырышалар...

Бүген Әбсәләмовларның ике җиткән уллары һәм әле мәктәптә укучы 11 яшьлек кызлары бар. Алар шушы мамык эшендә кайнашып, аның барлык нечкәлекләрен, мәшәкатьләрен белеп үсә. Әбсәләмовлар гаиләсендә әтиләре нәрсә әйтсә, шулай эшлиләр. Аны күз карашыннан аңларга күнеккәннәр. Фаил улларын да шулай тәрбияләгән. Бу йортта бер-берсенә каты дәшү дә, кычкыру да, ямьсез сүзләр әйтү дә юк. Әтиләренең улларына бер генә күз карашы белән каравы да җитә. Чөнки балаларның да әтиләренә ихтирамы зур. Альбина бүген тормыштагы уңышларының төп башлангычын үзенә акыллы ир туры килүендә күрә. «Аллаһ миңа бик әйбәт кеше насыйп итте. Бу – хатын-кыз өчен зур бәхет. Ирең сине аңласа, үзен гаилә башлыгы итеп куя белсә, барысына да өлгерәсең, эшләрең дә уң була. Фаил – һәрнәрсәдә терәгем. Ул күп сөйләшми, тыйнак, киң күңелле кеше», – ди.

Альбина Фаил белән бергәләп һәрвакыт күргәзмәләрдә йөргәч, балалар күбрәк дәү әниләре Флюра ханым янында тәрбияләнә. Алар Коръән сүрәләрен дә белә, догалар да өйрәнгән. Әмма Әбсәләмовларга улларын һәм кызларын бик ерак юлларга да үзләре белән алырга туры килгәләгән. Аеруча Азалия күкрәк баласы булган чорда күргәзмәләргә еш чакыралар, ерак юлларга чыгарга туры килә, кызчыкны ана сөтен имүдән мәхрүм итәселәре килмәгәч, аны үзләре белән алалар. Берсе машинада бала караганда, икенчесе эш белән йөри. Зур уллары Тимур холкы белән әтисе Фаилгә охшаган, аның кебек төпле, оешкан, әтисенең сүзеннән чыкмый торган ир-егет. Ул Санкт-Петербургта җиңел сәнәгать институтын тәмамлап, эрләү буенча технолог белгечлегенә ия булган, хезмәт күнекмәләрен дә үзләренең цехында алган. Хәзер дипломлы белгечкә мамык эшкәртү цехын тулысынча тапшырганнар, анда алты кеше хезмәт куя.

Уртанчы уллары Динислам да шулай ук Санкт-Петербургта Халыкара бизнес факультетында икенче курста белем ала. «Аның фикерләве башкача. Ул физик эшләргә бик тартылмый, акыл белән исәпли, уйлап башкарыла торган хезмәтләрне, идарә итүне ярата».

Альбина кызлары Азалияне дә алты яшеннән шәл бәйләргә өйрәткән. Әле быел көз, әтиәнисе белән Калугага ярминкәгә барып, үзе бәйләгән кечкенә генә шәлләрен сатып кайткан. Тулага барып та 30 мең акча эшләгән. Альбина белән Фаил шуңа бераз акча өстәгән дә кызга кыйммәтле айфон алган. Азалия татар мәдәниятенә тартыла, биергә дә, җырларга да ярата, «Татар кызчыгы» конкурсында алып баручы буларак та катнашкан. «Минем янда йөри, барысын да күреп үсә инде», – ди А.Әбсәләмова. Бүген карап торышка кызлар кебек Альбина ханым кайнана, дәү әни булырга да өлгергән. Улы Тимур үз гаиләсен корган, әти-әнисе белән бер йортта яшиләр...

А.Әбсәләмова 2015 елда җәмәгатьчелек эшенә дә кереп китә. «Ак калфак» Бөтендөнья татар хатын кызлары иҗтимагый оешмасы рәисе Кадрия Идрисованы читтән торып белсә дә, алар таныш булмый. А.Әбсәләмова К.Идрисова белән Казанда Эшмәкәрләр корылтаенда таныша, икенче корылтайда да күрешәләр. Ә беркөнне Оренбург татар милли-мәдәни мохтарият җитәкчесе Р.Зәбиров А.Әбсәләмовага, Казаннан аны өлкәнең «Ак калфак» татар хатын-кызлары оешмасы рәисе итәргә дигән тәкъдим килүен җиткерә. Оренбургта «Ак калфак» оешмасы булган, әмма өлкәнең иң актив хатын-кызлары да бу хакта белмәгән. Альбина ханым, эшләргә алынгач, өлкә татарларын күтәрергә кирәк дип, беренче тапкыр 2015 елда Бөтендөнья татар хатын кызлары корылтаен үткәрә. Дөньяның төрле почмакларыннан җыелган 300 аккалфаклы өч көн дәвамында Оренбургның татарларга бәйле күп кенә истәлекле урыннары белән дә танышты, күп кенә мәсьәләләрне уртага салып сөйләште. Хәзер Оренбургның 18 җирлегендә «Ак калфак» оешмасы эшләп килә, ел саен өлкә оешмасының съезды уза, ел дәвамында башкарылган эшләргә йомгак ясыйлар, уй-ниятләре белән уртаклашалар. Алар арасында «Татар кызчыгы», «Татар малае», «Әбекәй матуркай», «Туган авылым» конкурслары, «Шәл туе» – аеруча зур проектлардан.

Сөембикә КАШАПОВА.

Зөлфәт – якташым, ямьле Ык буена урнашкан Мөслим районыннан, татарның теле, татарлыгы аеруча нык сакланган төбәктән. Шагыйрьләр, әдипләр төбәге - бу як. Чөнки Зөлфәттән кала, аннан Харрас Әюп, Наис Гамбәр, Шәмсия Җиһангирова, Факил Әмәк, Асия Минһаҗева кебек шагыйрьләр һәм күренекле прозаик Фоат Садриев чыккан. Мөслим ягы кешеләре, Зөлфәт әйтмешли, авыз тутырып, тәмләп сөйләргә ярата, хәтта ачулануларын да лирикага, шигърияткә төрә белә. Шуңа күрә дә Зөлфәтнең шушы якның бәрәкәтле туфрагыннан үзенә дәрт-дәрман һәм шифалы сүл, илһам алып яшәве бик табигый.

ЕЛАННЫ САЙРАТКАН

Зөлфәтнең (Дөлфәт Маликовның) тумыштан килгән, туган туфрагында бөреләнгән куәтле шигъри талантын башлап ачкан һәм канатландырып җибәргән беренче остазы – Рәдиф Гаташ. 1960 еллар уртасында Рәдиф, университет тәмамлагач, әлеге төбәкнең Урәзмәт авылы урта мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укыткан вакытта була бу. Ә инде булачак шагыйрьнең аннан соңгы үсеш-өлгереш һәм бәрәкәтле иҗат дәвере, 1977 елда Мәскәүдә, Язучылар союзы каршында Югары әдәби курсларда укып кайтуын исәпкә алмаганда, Казан чорына туры килә. Монда ул университетның татар филологиясе бүлегендә белем ала. Күп еллар буена республика газета һәм журнал («Яшь Ленинчы», «Чаян») редакцияләрендә эшли, үзен үтә үзенчәлекле шагыйрь итеп таныткан һәм Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе алу югарылыгына күтәргән ялкынлы шигырь китапларын чыгара.

Башкортстанда яшәгән күренекле татар һәм башкорт шагыйре Нажар Нәҗминең Зөлфәтнең «Ике урман арасы» (1995) җыентыгына бәя биреп, хат рәвешендә язган мәкаләсендә мондый юллар бар: «Син - Ходай рәхмәте белән дөньяга килгән бик тә серле шагыйрь. Ул серне, ике урман арасындагы серне, гомер һәм иҗат серен киләчәктә ачучылар табылыр әле». Бу мәртәбәле бәяләмә Зөлфәтнең шәхесенә һәм иҗатына, чыннан да, гаҗәеп дәрәҗәдә туры килә. Ул иҗат иткән шагыйрьләрнең укучы күңеленә язгы яшен кебек көчле тәэсир итүенең серле һәм төп сәбәбе - шагыйрьнең шәхси-аерым иҗат стилендә, аның сурәтле-ассоциатив фикерләү үзенчәлегендә.

Зөлфәтнең сурәтле-сәнгатьчә фикерләвендә аеруча көчле гәүдәләнгән һәм бөтен иҗаты буенча бара торган берничә үзенчәлекле алым бар. Шуларның иң характерлысы – шагыйрьдә әверелү логикасының, ягъни бер күренештән икенче күренешкә әверелү яки төрле халәткә һәм кыяфәткә күчү тойгысының гаҗәеп дәрәҗәдә үскән булуында. Фәндә бу алым, аерым төсмерләренә һәм төрләренә карап, төрле исемнәрдә йөртелә: сынландыру, җанландыру, персоналаштыру, антропоморфизм, метаморфоз...

Сәхнә әсәре язганда автор һичшиксез белергә һәм сакларга тиешле бер таләп бар: ул үзе иҗат иткән геройлары роленә керә белергә, үзен башкалар урынына кую осталыгына ия булырга тиеш. Шигърияттә дә «ролевая лирика» дигән жанр төре бар. Бу очракта шагыйрь үзен, Сөембикә яки Батырша урынына куеп, шигырен аларның уй-кичерешләрен чагылдыра торган монологка кора.

Ә менә чын, талантлы шагыйрь, минемчә, үзен башкалар урынына гына түгел, ә табигатьтәге төрле җансыз һәм җанлы күренешләр, стихияле көчләр урынына да куя белергә, иң мөһиме – аларны үзенең хис-кичерешләре, теләк-омтылышлары белән өретү югарылыгына күтәрү осталыгына ия булырга тиеш. Зөлфәт шигырьләрендә нәкъ шушы сыйфатның калку булып гәүдәләнүен күрәм. Мәсәлән, шагыйрь бер очракта үзен шифалы яңгыр алып килүче болытка, икенче очракта яшенле давылга, өченче очракта йөрәге ярылганчы сайрый торган сандугачка тиңли.

Ходай яраткан гүзәл тереклеккә, әйтик, атка сокланганда ул үзен кешни-кешни чабып йөрүче колын итеп тоя, ә инде табигатьтәге яклаучысыз тереклек ияләрен якларга кирәк булганда хәтта мылтык төзәлгән кошка әверелә, адәм затының вәхшилеген менә-менә атылачак кош булып, турыдан-туры үзе татып карый. Янә килеп, табигать тарафыннан ирекле һәм куәтле итеп яратылган затны тоткынлыкның кимсетүен, мәсхәрәләвен күрсәтү өчен, шагыйрь тимер читлектәге арысланга әйләнә. Хайваннар патшасының шунда һәм дә цирк аренасында калҗа һәм өйрәтүченең кулын ялаучы мәхлук хәленә төшүен ачынып тасвирлый.

Вакыт-вакыт Зөлфәт үзенең киң мәгънәле мәхәббәт тойгысын да шул ук әверелү алымы аша белдерә. Мәсәлән, иле өчен янып яшәвен күрсәтү өчен, ул урыны-урыны белән мондый образлар куллана:

Беренче кар булсаң да бик ярый –
Ил җанында кирәк эрергә.
Илдә көчек булсаң да бик ярый.
Тик ил өчен кирәк өрергә.
Эт шикелле мин яларга әзер
Туган илнең һәрбер ярасын.

Шагыйрьнең төрле хайваннарга, кошларга әверелә алу сәләтен мин зооморфизм (грекча зоо – хайван, морфе – форма, рәвеш) дип атар идем. Ләкин Зөлфәт антропоморфизм, ягъни «кешеләштерү», төрле нәрсәләргә кеше сыйфатларын бирү алымын да бик оста эшкә җигә һәм аны табигать күренешләренә, әйләнә-тирәдәге әйберләргә мөнәсәбәттә генә түгел, ә масштаблы-күләмле, хәтта шартлы яки күзгә күренеп тормаган объектларга карата да куллана. Вакыт образын ул болай күз алдына бастыра:

Бөек Вакыт ята көлемсерәп,
Караган да шушы юләренә –
Башын салып гамьсез мендәренә...

Монда вакыт агышының кешегә, заманга карата битараф, гамьсез булуы бик оста тасвирланган. Ә менә авыр хәлгә төшкән илен «кешеләштергәндә» шагыйрь икенче төрле сурәт тудыра:

Хәлең ничек, диеп сорау бирәм,
Туган илем исә тын гына.
Елмая да, күзләремә карап,
Авыр башын сала кулыма.

Зөлфәтнең «Җирдән кайтышлый» дигән поэмасы да тоташы белән диярлек антропоморфизм алымына корылган. Әлеге поэмада автор адәм заты тарафыннан төрлечә кыерсытылып, кимсетелеп яши торган Җир шарын җанландыра һәм, телгә китереп, аннан кешенең табигатьне, җирне рәнҗетеп яшәвенә бәйләнешле зарын һәм кискен гаепләү сүзләрен әйттерә.

Шагыйрь иҗатында аеруча еш һәм яратып кулланыла торган икенче саллы үзенчәлек антитеза-контраст алымына, ягъни төрле күренешләрне капма-каршы куеп сурәтләүгә, төрле антиподлар тудыруга кайтып кала. Шул ук вакытта Зөлфәт, кирәк булса, капма-каршы башлангычларны берләштерә яки бербөтенгә җыя да белә. Контрастлар шагыйре Зөлфәт менә шушы закончалыкның җегәрлеген, искиткеч куәтә ия бүлуын тулысынча аңлап эш итә һәм иҗади мәсләген чагылдырган махсус язмасында, шигырь турындагы эссесендә дә бу алымнан уңышлы файдалана:

«Шигырь көчленең кулында камчы булганчы, бичараның керфегендә тамчы булсачы!

Чын шигырь уен белән куен гына түгел.

Шигырь – назлы бишек тә, яу атына салынган ияр дә».

Яки менә шагыйрьнең «Йөрәгемне былбыл чакты» дигән җыентыгын ачучы «Ходай сулышы» дигән шигыреннән отышлы бер мисал:

Мин былбылдан сезне
чактырмын,
Тыңлатырмын елан сайравын.

Игътибар итик: былбыл булып чагу, елан булып сайрау... Чын талант иясе һәм ассоциатив фикерләү остасы гына ут һәм су кебек үзара килешмәслек, бер-беренә дошман булып тоелган каршылыкларны шулай бербөтенгә берләштерә ала. Ә бит төптән уйлап караганда, Зөлфәтнең бу көтелмәгән гыйбарәләрендә зур дөреслек бар. Шагыйрь ул һич тә матур җырлар гына җырлап-сайрап торучы сандугач түгел. Кирәк чакта ул елан булып чага да һәм күңелләрне еланның шифалы агуы белән дәвалый да!

«Мәхәббәт», «Ат йокысы» кебек сюжетлы шигырьләрнең укучы күңеленә көчле тәэсир итүенең сәбәбе дә капма-каршы башлангычларны чәкештерү алымына коруда. Беренче шигырьдә шагыйрь биегәндә өрлекләрне сыгылдыра һәм хәтта аю булып аюга пычак белән бара торган әзмәвердәй ирне сөйгәне алдында аягыннан ектырса, икенчесендә тулпар булып дөньяга килгән, әмма иясе тарафыннан камыт кидерелеп, йөк арбасына җигелгән атны тасвирлап, «камыт үтерә диләр канатлыны!» дигән фәлсәфи нәтиҗә чыгара.

Аерым шигырьләрдә генә түгел, «Йөрәкләрдә үлмәс дастан» поэмасында да антитеза-контрастлар әсәрнең буеннан-буена бара. Анда Зөлфәт балачакның һәм, гомумән, халыкның киләчәккә юнәлгән өмет-хыялларын һәм омтылышларын гәүдәләндерүче символик Шаһрезадә

ЗӨЛФӘТ ФЕНОМЕНЫ

образын тудыра һәм әкиятче кызның XXI гасырның техникага, машиналарга гына табынучы вәхшиләре тарафыннан яндырылуын сурәтләп, дөньяның киләчәк язмышы турында уйланырга мәҗбүр итә. Шушы ук циклны дәвам итүче «Тыным бетте» шигырендә исә автор, легендалар буенча, кальга нык булсын дип, Түбән Новгород Кремленең манара нигезенә бикләп калдырылган көянтәле кызны әле дә исән итеп күз алдына китерә һәм нәзек җилкәсенә яу кайтару йөге йөкләнгән әлеге кызның чын табигый вазифасы һәм халәте иректә генә яшәргә тиешле гүзәллек булуына басым ясый:

Абау! –Матурлыкның
нәфис җаны биктә!
Абау – ул җан
җансыз таш эчендә калган!
Абау – матурлыкны
коткарырга кирәк!
Абау! – матурлыкның тыны
тәмам беткән!

Лев Толстойның Зөлфәт иҗатындагы тагын бер үзенчәлекле якны ачарга ярдәм итүче кызыклы фикере бар. «Сәнгатьнең төп бурычы – дигән ул, – кеше, халык рухы турында дөреслекне әйтү». Әлеге шагыйрьнең шигырьләренә дә шәхеснең, халыкның рухи дөньясы хакында дөреслекне әйтү хас. Күп кенә уртакул яки ташкаүлчим шагыйрьләрдән аермалы буларак, ул үзе кичерешләрендә, тар кысаларда торып кала торган интим хис-тойгыларында гына чокчынмый, иң мөһиме – халык булып та уйлый, кичерә. Бу, әлбәттә, аның үзен башкалар урынына куя белүеннән килә.

Шагыйрь иҗатына хас янә бер үзенчәлек – халкыбызның үлемсез «Кара урман» җырындагы кебек, татарның ачы язмышын үзәккә куеп гәүдәләндерү. Шигырьләренең исемнәре үк шуны раслап тора: «Адашкан болыт», «Сөембикәнең хушлашу догасы», «Чор сурәте», «Татар теленең каргышы», «Сират күпере», «Алабута баскан», «Соңгы язмыш яры». Бу бөек Тукайның *«Кузгатмакчы булсаң халык күңелләрен, | көйләү тиеш, әлбәт, ачы хәсрәт көен, |кирәк түгел, мәгънәсе юк көлке, уен»* дигән шигъри юлларында чагылыш тапкан һәм дә бөтен иҗатын сугарган сәнгати-эстетик мәсләгенә теләктәшлек күрсәтү һәм аны яңа шартларда дәвам итү дигән сүз. Шигырь турындагы әдәби-тәнкыйди эссесында автор «Татар поэзиясе – каргышлы язмыш поэзиясе» дип, әлеге өлкәгә мөнәсәбәтле үз карашын, үз бәяләмәсен дә белдерде.

Ләкин Зөлфәт ил һәм халык язмышына туры килгән афәтләр, дәһшәтләр өчен ачыргалану, аһ ору, борчылу белән генә чикләнми, ә шул бәла-казаларны тудырган сәясәтне, империячел җәмгыятьне, кан-яшь алып килгән сугышларны кискен фаш итеп чыкты, шуларга каршы баш күтәргән шәхес буларак чыгыш ясады. Янә шуңа басым ясарга кирәк: Зөлфәт һич тә пессимист һәм елак шагыйрь түгел иде, ул халыкны юатырга, хис-тойгыларын ягып, аның күңелен җылытырга, киләчәккә өмет уятырга омтылды. «Язган булса» шигырендә ул болай ди:

Инде: «Беттек!
Инде: «Беттек!
Безне бетерделәр!
– Көйдерделәр!» – дигән чакта да,
Атасы таң әгәр атар булса,
Көйгән туфракка да Чык тама...

Безнең эрага кадәр (65–80 еллар) яшәгән Рим шагыйре Квинт Гораций «Поэтик сәнгать» исемле эссесында асыл шигъриятнең образлы-сурәтле теле нинди булырга тиешлеге турында мондый мәгънәле фикер әйткән: «В стихах слова должны удивляться своему соседству». Зөлфәт, әлбәттә, бу сәнгати-ассоциатив канунны тирән үзләштергән һәм сүзләрне бөтенләй көтелмәгән бәйләнештә дә куллану осталыгына ирешкән хикмәтле шагыйрь. Аның тылсымлы иҗат феноменының, күңелләрне әледән-әле өтеп ала торган бик тә үзенчәлекле образлар, моңарчы колак ишетмәгән сурәтле гыйбарәләр тудыра алуының бер җитди сәбәбе һәм сере дә әнә шунда. Шушыңа инандыра торган алдагы мәгълүматларга өстәп, тагын берничә мисал китерик:

Булды бу хәл аның керфегеннән
Җем-җем итеп йолдыз коелганда.
Салават күперенә менеп.
Икәү бергә аска ташланыйк!
Яшен оялаган йөрәгемә,
Елан түгел – шөкер, мең шөкер!
Үз-үземне кайчак аңламыйм.
Әллә кеше, әллә алла мин.

Шагыйрьнең Вакыт галиҗәнапларын сурәтләүгә бәйләнешле гаҗәеп бер сыйфатына тукталыйк. Зөлфәт – вакыт образларын, вакыт тезмәсендәге мизгелләрне тасвирлау остасы да. Ул вакыт белән төрлечә эш итә, узганнарга һәм киләчәккә сәяхәт ясау белән бергә, вакытны кирегә таба да актыра һәм иң үзенчәлеклесе, тәэсирлесе – гүзәл һәм явыз мизгелләрне туктатып та калдыра. «Кәккүк» шигырендә болытлардан төшүче тамчыны, Идел өстендә очучы акчарлакларны, кәфен кисүче кайчыны, атарга җыенган мылтыкның чакмасын һәм хәтта фикер агышын туктатып калдыруы – моңа менә дигән мисаллар. Яки менә шагыйрьнең күңелнең иң нечкә кылларына тәэсир итә торган аерым мизгел сурәтләре:

Көянтәгә әнкәй
чиләк элде.
Суга китте. Димәк, таң ата.
Яки:
Бер төн кызы тын болында
Тыелып кына...
Таңны чакырды...
Ут эленде офык аръягында
Үләннәрдә чыклар яктырды.
Тын эңгердә ат пошкырып куйды.
Алсуланып томан уяна.
Кинән, җаным!
Шөкрана кыл, берүк!
– Шундый мәл дә бар бит дөньяда.

Безнең эрага кадәр үк яшәгән һун бабаларыбыз, ант эчкәндә, Тәңрегә якынаю өчен биек тау башына менә һәм шәрабларына кан тамыза торган булган. Зөлфәтнең таулар теле белән язылган һәм изге ант-дога булып яңгыраган шигырьләрендә дә шагыйрьнең кан тибеше, Ходай сулышы тоела.

Марсель БАКИРОВ,
филология фәннәре докторы.

РЕКТОР НИНДИ БУЛЫРГА ТИЕШ?

Казан федераль университетына яңа ректор билгеләнгән очракта, ул нинди сыйфатларга ия булырга һәм кайсы мәсьәләләргә аеруча игътибар итәргә тиеш?

Васил Гайфуллин, профессор, 1990-1996 елларда Татарстан мәгариф министры:

– Казан дәүләт университеты ректоры итеп татар кешесеннән куйсалар, әйбәт булыр иде. Татар кешесен куя алмасак – бу безнең көчсезлек итеп кабул ителәчәк. Ректор, беренче чиратта, галим булырга тиеш. Икенчедән, татар җанлы булсын. Күңеле, җаны белән татар булсын. Формасын гына китереп йөри торган кеше кирәк түгел. Булдыклы, дәрәҗәле, кая барса да сүзе үтә торган кеше кирәк.

Рүзәл Юсупов, Татарстан Фәннәр академиясе академигы, 1986-2002 елларда Казан педагогика университеты ректоры:

– Университет ректоры буларак татар халкының мәдәнияте, теле үсешенә файда китерә торган кеше кирәк. Федераль университет Россиянеке дип кенә милләттән читләшергә тиеш түгел. Татар теле һәм әдәбияты буенча белем бирүне җанландырып җибәрергә, бу юнәлешкә күбрәк студент алырга кирәк. Яңа ректор өстән куелган бурычларны болай да үтәр, ләкин без аннан татар халкына файда китерүне таләп итәргә тиеш.

Илдар Габдрафиков, тарих фәннәре кандидаты:

– Ректор, беренче чиратта, мәгарифне, фәнне үстерергә, галимнәргә эшләргә, студентларга укырга уңайлы шартлар тудырырга, иң яхшы белгечләрне җәлеп итәргә тиеш. Көнбатыш илләрнең телләрендә дә белем бирүне күздән ычкындырмаска кирәк.

Тәлгать Әхмәдишин, җәмәгать эшлеклесе:

– Мәктәпләрдә татар телендә белем бирә алырдай укытучылар җитми. Яңа ректор бу мәсьәләгә төптән карарга тиеш. Әхлак ягыннан югары дәрәҗәдәге, таләпчән җитәкче булуы мөһим. Казан университеты җитәкчесе итеп Энгель Фәттаховны, яисә шуның кебек кешене куйсыннар иде.

Энгель Фәттахов, Актаныш районы башлыгы, 2012-2018 елларда мәгариф һәм фән министры:

– Университет ректоры фән кешесе дә, хуҗалыкны алып бара белә торган оештыручы да, шул ук вакытта халыкара киңлектә танылган шәхес тә булырга тиеш. Аның Татарстанны да яхшы белүе мөһим. Федераль вузлар - республика, ил язмышын хәл итә торган уку йортлары. Ректор шуны тоеп, университетның исемен җисеменә туры китерерлек итеп эшләсен иде.

Эльмира Галимова, композитор, сәнгать фәннәре кандидаты:

– Яңа ректор мәдәниятне, сәнгатьне яхшы аңлый торган кеше булсын иде, чөнки сәнгать һәм мәдәният – милләтебезнең йөзе. Заманында педуниверситет аерым статуска ия югары уку йорты иде. Хәзер КФУ әлеге уку йортын үз эченә алды, ләкин музыка сәнгатен өйрәнү, музыка фәннәрен укытырлык укытучылар әзерләү күләмен чикләде. Шул сәбәпле мәктәпләрдә кадрлар кытлыгы сизелә башлады. Гомумән, мәктәпләрдә музыка фәнен, сәнгать дәресләрен алып барырлык укытучыларны университет әзерләргә тиеш. Яңа ректор шушы юнәлешкә дә игътибар итсен иде.

Рифат КАЮМОВ.

Сөйкемле булыр өчен

Польша журналисты Барбара Гавроньскаяның хатын-кызларга ун киңәше.

● Елмай: усаллык һәм дорфа сөйләшү матурлыкны юкка чыгара. Янәшә-тирәдәге кешеләр белән сабыр, ихлас сөйләшү матурлык нигезе.

● Атнаның бер көнен яки кичен үзеңә багышла. Чәчтарашка яки косметологка бар, һич булмаса, битеңә һәм муеныңа үзең битлек ясa. Яшьтән үк чисталыкка, пөхтәлеккә өйрәнсәң, теләсә кайсы яшьтә дә игътибарны җәлеп итәрсең.

● Өйдә киеп йөри торган киемең чиста һәм уңайлы булсын. Якыннарың моңа югары бәя куяр, синең исә кәефең күтәрелер.

● Макияждан файдалан. Хәзерге хатын-кызларның берсе дә косметикасыз урамга чыкмый. Ләкин сак булыгыз – ул “кычкырып” тормасын. Көндез җиңел, якты төсләрдә макияж кирәк, юкса яшегездән картрак күренерсез. Иң зур игътибарны күз һәм ирен буяуга гына бирмәгез – чама кирәк.

● Чәч – хатын-кыз күрке. Мода дип үзегезгә туры килми торган чәч ясатмагыз. Чәчегез макияж, өс киеме, тышкы кыяфәтегезнең тибы белән туры килсен. Максат – кимчелекләрне яшерү, яхшы үзенчәлекләрне күпертебрәк күрсәтү.

● Гәүдә авырлыгын күзәт: гимнастика ясa, җәяү йөр, ябык! Җиңел гәүдә, җиңел йөреш зур хезмәт таләп итә. Әз-әзләп көнгә 5 мәртәбә аша! Матурлыкның дошманнары – шикәр, тоз, әче тәмләткечләр, алкоголь. Дусларың – яшелчә-җимеш, сөт ризыклары.

● Киләсе көнеңә план кор! Бу сине кирәкмәгән борчулардан арындырыр. Эш көнендә 15 минут булса да күзеңне йомып, ял итеп ал. Ятып торсаң (мөмкинлек булса) тагын да яхшырак.

● Йорт эшләрен үзең генә эшләмә – иреңне, балаларыңны да эшләт. Бергәләп эшләгән эш араларны якынайта.

● Уңышсыз эшләрне башыңнан чыгар. Уңышсызлыкны сабырлык белән кабул ит. Ышан – ул вакытлы нәрсә, уңыш килер. Күңелсезлеккә, эч пошуга бирешмә.

● Мәшәкать тап, яңа күлмәк тек, фатирыңда йорт җиһазларының урынын алмаштыр, чәч төзәт, җырла, классик әдәбият укы.

Шушы 10 киңәшне генә үтәсәң дә, матурлыгың артыр, кешеләр сине яратыр, ә син елмаеп йөрерсең.

Әгъзам **ФӘЙЗРАХМАНОВ**
әзерләде.

«Туган тел – уй үстерә»

Минвәгыйз Зәйнетдиновның «Эзләп тапкан бәхетле» исемле китабындагы бер язма «Ана сөте буй үстерсә» дип атала. Әдәби-документаль басма былтыр Татарстан Фәннәр академиясе нәшриятында дөнья күргән.

Китап «Яшьләр»дә яшьнәгән чаклар», «Эзләп табу бәхете», «Елмаеп-көлеп алыйк», «Китап авторы турында да...» дип исемләнгән бүлекләрдән тора. Авторның алда чыккан китапларына карата әйтелгән берничә бәяләмә дә урын алган.

Китапта иң күзгә ташланганы – авторның туган як җанлылыгы, иманлы кеше булуы. Мәкаләләр һәркайсы олы ярату белән, мәсьәләгә җитди килеп язылган. Авторның Туган ягын гына түгел, аның кешеләрен, туган Татарстанын, сайлаган һөнәрен чын ихласлык белән яратуы, искиткеч күзәтүчән, кыйбласына гомере буе тугры калуы күренә. Ул үзенең ярты гасырдан артыкка сузылган журналистлык гомерендә очраган бер генә вакыйганы да игътибарсыз калдырмаган, әһәмиятле дип санаганнарын укучы белән бүлешеп-уртаклашып яшәгән. Хәтта, алай гына да түгел, кечкенә генә мәкаләнең дә геройларын йөрәге белән кабул иткәннән соң, очрашуларын еш кына фотосурәткә дә алып, документлаштырганнан соң гына каләмен эшкә җиккән. Ул язмаларны укыгач, авторны милләтебезнең чын милләтпәрвәре, үзенең тынгысыз эзләнүләре,эзләгәнен табулары белән бәхетле журналисты дип нәтиҗә ясарга тулы нигез туа. Җыентыкка «Әдәби-документаль» дигән мөһер сугылу да – бик урынлы. Тарихи кыйммәткә ия мәсьәләләр, олуг шәхесләр, республикакүләм үткәрелгән чараларның да зур пөхтәлек белән теркәлеп куелуы, аларның бүгенге көн күзлегеннән бәяләнүе – хәтта яшь журналистларга үрнәк итеп күрсәтерлек, кулланма вазифасын үтәрлек өлге-чыганак. Кайчагында зур романнар, калын китап булып әверелгән әсәрләр укыйсың, тик авторның нәрсә әйтергә теләгәне, максаты аңлашылмый. Күңелгә уелып кала торган вакыйга, аһ итәрлек әдәби герой очрамый. Ходай бирмәгән талантны әрсезлек белән генә яулап алып булмый шул! Язучы өчен дә, журналист өчен дә шулай. Кечкенә генә вакыйганы да һәр яклап ачып, төрле ягы төрле төсләр белән балкыган призма кебек сурәтли алу – билгеле, осталык, тәҗрибә, әшенә яратып алыну һәм Ходай Тәгалә бүләк иткән талант. Кыскасы, каләм әһеле буларак, артык күзгә кереп йөрмәгән, тыйнак М.Зәйнетдиновның «Эзләп тапкан бәхетле» исемле китабын укып канәгатьләнү, күп гыйлем алдым...

Алимә Әйденанова – Кырым татары. Бөек Ватан сугышы елларында зур батырлыклар күрсәтеп, 20 яшендә Кызыл Байрак орденына лаек булган курку белмәс кыю кыз, һәлак булганнан соң 70 ел узгач, РФ Президенты В.Путинның 2014 ел, 1 сентябрь Указы нигезендә Россия Федерациясе Герое исеме белән бүләкләнә. Алимә, сугыш башлангач, үз теләге белән фронтка китү уе белән, эшеннән аерылмыйча, өч айлык санитар-инструкторлар әзерли торган курсларда, аннан разведка мәктәбендә укый. Приморье армиясе штабының разведка бүлеге резиденты тарафыннан чигенүче дошманның тылына разведкага җибәрелә. Сабакташы Лариса Гуляченко белән Алимәнең туган ягы Джермаш-Кашик авылы тирәсенә парашюттан сикерәләр. Алимә, Төньяк Кавказ фронтының разведка бүлегенә кыйммәтле мәгълүматлар тупланган 80 радиограмма җибәрә. Әмма, ни кызганыч, 1944 елның февралендә алар кулга алына. Сорау алулар, аяусыз җәзалаулар, кыйнаулар башлана. Алимә һәм, ул оештырган яшерен төркем вәкилләре-якташлары нык тора, әммa Л.Гуляченко дошманга бирелә, радиостанциянең кайда яшерелгәнлеген әйтә...

Китапта Кырым татарларына кагылышлы тагын бер «Бәлки насыйп итәр» дигән кечкенә язма бар. Ул 1965 елда 200 000 тираж белән чыккан «Легенда Крыма» дигән китап турында. Мәкалә авторы М.Зәйнетдинов, әлеге китапны укып, өметләренең акланмавы, җыентыкка алхәбәр язган М. Рыльскийның кереш сүзендә үк, татарларның өнәмәве сизелеп торуын, ә инде «татарин» атамасының бары бер урында, анда да «слепой, нищий татарин» дип искә алынуын бәян итә. Туктамыш ханның, мәсәлән, тискәре герой итеп сурәтләнүе өстенә, «У него тело шерстью поросло, он был рыжий, голова у него была как у барана, зрачки у него поперек глаз стояли...», ә инде хан Кырым-Гәрәй турында: «Никакие жалобы и слезы его сердце не трогали, он упивался кровью своих жертв...» диелә. Җай чыккан саен нәкъ менә шундый сүзләр белән Кырымның төп халкын кимсетеп, мөнәсәбәтләрне үз файдасына борып, куертып күрсәтүләр, Тукай әйтмешли, яхшысына күз йомып, яманын эт кебек һаулап өреп торулар – бәлки, бу халыкны иленнән куура, депортацияләүгә төп сәбәп тә булгандыр?..



Кырым татарлары темасы бөтен төрки дөньяны тетрәндергән кебек үк Минвәгыйз Фәләх улын да тынычлыкта калдырмый. Ул бу темага тагын берничә мәкаләсендә туктала. Мәсәлән, «Һәркемнең үз каланчасы» дигән мәкаләсендә Александр Широкорадның «Битва за Крым. От Крымского ханства до возвращения России» дигән китабын укып, автор белән бәхәскә керә. «Татары не были коренным населением Крыма» дигән ялгыш фикерләргә каршы интернет, Википедия энциклопедиясе материаллары белән җавап бирә.

Укыган, алга барган саен, авторның шулкадәр олы гамь белән яшәвенә, ташка басылган чыганакларга да; «Семь дней», «Время покажет» кебек телевизион тапшыруларлардагы чыгышларга да битараф кала алмавына соклanmый мөмкин түгел. Шушы 135 битле китапта никадәр олы шәхесләребез искә алына да, аларның укучы өчен моңа кадәр билгеле булмаган яклары, нәселдәшләре, дәвамчылары турында сөйләнә, тамыр җепләре ачыкланган хәбәрләр җиткерелә, урау юллар белән эзләп табылган фотосурәтләре тәкъдим ителә.

«Исхакыйлар имамлык иткән дәвер бер безнең Лашман авылында гына да 80 елга җыела», ди автор үзенең «Бер җөмлә эзеннән» дигән мәкаләсендә. Чирмешән районының Лашман авылы – авторның кендек каны тамган, газиз туган җире. Шуңа күрә Лашман белән бәйле булган һәр вакыйга, Лашманда көн иткән һәр кеше, һәр шәхес кадерле аңа. Гаяз Исхакыйның тамырларына кагылышлы хатирәләр дә кат-кат очрап, мәгълүмат кырын киңәйтеп тора.

Аның туган ягында күренекле шәхесләр аз түгел. Әйтик, китапны ачып җибәргән «Эшкә бирсәң чын күңел» дигән мәкаләдә 1948-1979 елларда Утыз Имән авылында фельдшер булып эшләгән Фатыйх Нуруллин,1946 елдан Лашман авылында шулай ук фельдшер булып эшләгән татар егете Семен Степанов турында бәян ителә. Шуңа бәйләнешле рәвештә татар халкының мәшһүр шагыйре Габдерәхим Утыз Имәни әл-Болгари, Гаяз Исхакыйның 1966 елда Ленин ордены белән бүләкләнгән туганнан-туган энесе Касыйм мулланың кызы табибә Сайбә Исхаковаларның данлы хезмәт юлы турында сөйләнә. Эзләп табылган кыйммәтле материаллар, бәян ителгән вакыйгалар соклandыра да, уйландыра да.

Югарыда телгә алган шәхесләрне кабатламыйча, китап битләре буйлап алга таба китсәк, шулай ук гаҗәеп кызыклы, гыйбрәтле язмышлар, күренекле шәхесләр белән очрашуыбыз дәвам итәр. Алар: сәясәтче Садри Максуди, язучылардан: «Минем телемне мыскыл итүегез өчен күңелем рәнҗеде» дип язган урыс шагыйре Ярослав Смеляковны орышкан батыр холыклы Камышлы авылы егете Әнвәр Давыдов, төньяк Себер шахта-рудникларында газап чиккән Мин Шабай, генерал Шакир Гыйниятуллин, Кызыл Тархан авылында үз өендә музей ачкан Рәис Шәрәпов, педагоглар Әхсән Салихов, Шәмгун Туйсиннар; СССРның атказанган спорт мастеры Галимҗан Хөсәенов һ.б... Арада, билгеле, без күреп белгәннәре дә бар: Мансур Хәсәнов, Лена Гайнанова, Тәүфикъ Әйди, Фәридә Гаффарова, Рөстәм Нәбиуллин, Флорид Әгъзәмов, һ.б.. Кыскасы, саный китсәң, исемнәре телгә алынганнарга бәйле рәвештә тагын йөзләгән шәхесләрне атап булыр иде.Тик авторның Кубада алган тәэсирләре, Самарада Сталин өчен төзелгән бункирда булып, фотога төшүләрен сикертеп узып, мәкаләмә исем итеп алган гыйбрәтле мәкальнең кем тарафыннан яңгыравын укучыга җиткереп нокта куймак булам.

Ул – 1999 елда Казанда «Муса Бигиев – дин һәм җәмгать эшлеклесе» симпозиумында катнашкан Төркия җөмһүрияте башлыгы ярдәмчесе Хөррият ханым Эрсойның Татарстанда алган тәэсирләре белән уртаклашканда әйткән сүзләре икән.«Кыска гына вакыт эчендә дә Татарстан шактый үзгәргән. Татар үз телендә күбрәк сөйләшә башлаган. «Ана теле уй үстерәдер, ана сөте буй үстерәдер»... Чыннан да, дөрес бит. Шуның өчен телне күтәрү кирәк!» – дигән чит илдән килгән кунагыбыз саф татарча. М.Зәйнетдинов та нәкъ шул сүзләрне кабатлый.

Эльмира ШӘРИФУЛЛИНА.

Нур Әхмәдиев белән танышлыгым әллә ни еракка китми, егерме биш-утыз еллар чамасы. Кеше гомереннән өчтән бере, бу аз түгел. Нур Гариф улы белән безнең мөнәсәбәтләр шулай җылы булды дип әйтә алам.

●Дамир Гарифуллин, Нур Әхмәдиев, Фоат Садриев.

Талантлы замандаш

(Нур Әхмәдиев турында истәлек)

Танышуыбыз болай. 1993 елда мине Мәгариф министрлыгына чакырып алдылар. Тагын Казаннан Фәридә Мифтиева, Чаллыдан Илдус Гыйләҗев дигән укытучыларны да дәшкәннәр икән. Безнең алга рус мәктәпләренең алтынчы сыйныфында укучы татар балалары өчен әдәбиятыбыз буенча дәреслек-хрестоматия әзерләү бурычы куелды.

Моңа кадәр рус мәктәпләренең алтынчы сыйныфы өчен мондый кулланма бөтенләй дә булмаган. Укытучылар үзләре төрле чыганаклардан файдаланып эш иткән. Бу исә бик күп төрлелек, буталчыклык китереп чыгарган, бердәй белем бирүне кыенлаштырган.

Әлбәттә, дәреслек төзү аның бурычларын, төзелешен күз алдына китерүдән, программа төзүдән башлана. Без классикларыбыз Г.Тукай, Һ.Такташ, М.Җәлил, Г.Әпсәләмов, Ф.Хөсни, И.Гази, С.Хәкимнәрнең унике-унөч яшендәге балаларга белем һәм тәрбия бирерлек әсәрләрен сайлап алдык. Алга таба А.Әхмәт, З.Нури, Л.Ихсанова, Ш.Галиев әсәрләрен сайлауда да кыенлык кичермәдек. Ләкин шуны сиздек: әлеге авторлар мәктәп программаларында моңа кадәр дә булган, димәк, яңа исемнәр, әлегәчә өйрәнелмәгән әсәрләр дә кирәк. Әдәбиятыбызның хәзергесендә дә талантлы язучыларыбыз һәм аларның әсәрләре бихисап.

Эзләнә торгач, мин Радик Фәизов, Нур Әхмәдиев һәм Илгизәр Солтан иҗатларына тукталырга булдым. Моннан берничә ел элек "Кояш эзләүче малай" дигән китапны кызыксынып укыганым хәтергә килде. Аның авторы Нур Әхмәдиевнең бигрәк тә "Минем туган көнем" дип исемләнгән хикәясен яратып калганмын. Әсәр алтынчы сыйныфта укучы үсмерләргә кызыклы булыр, рус теле мохитендә белем һәм тәрбия алучыларга татарларның яшәү рәвешләре турында мәгълүматлар бирелү җәһәтеннән дә аның әһәмияте бар. Шулай ук аларга сугыштан соңгы еллардагы ашау-эчүгә булган кытлыкны аңларга да ярдәм итәр. Нәшрияттан адресын белеп, Әлмәт шәһәрендә яшәүче авторга хат юлладым. Шушы хикәя кергән китабын җибәрүен һәм аңардан әсәрен дәреслеккә кертергә рөхсәт бирүен үтендем.

Атна-ун көн уздымы- юкмы, Әлмәт каласыннан җавап килеп тә җитте.

"Хөрмәтле Фоат әфәнде! Хатыгызны алдым, рәхмәт. Дәреслеккә әсәрең кертелү автор өчен күңелле хәл, әлбәттә. Мин Сезгә ике китабымны җибәрәм. Аның берсендә "Минем туган көнем" хикәясе, икенчесендә класстан тыш уку өчен мин тәкъдим итәргә теләгән "Күктә ничә йолдыз бар?" исемле фантастик повесть. Укып карарсыз.

Сезгә сәлам белән, Нур Әхмәдиев. 24.09.93".

Бу хикәянең хрестоматиядә урын алуын укытучылар да хуплап каршылады. Минем тарафтан хикәягә бирелгән аңлатма балалар тарафыннан әсәрнең үзләштерелүен тәэмин итә, диделәр.

Чыннан да, бу хикәя балаларның күңелен матур итеп тәрбияләргә мөмкинлек бирә торган әсәрләрнең иң үтемлеләреннән. Без әлеге дәреслекне дүрт тапкыр үзгәртеп һәм тулыландырып чыгардык, шуңа күрә аның гомере шактый озын булды, чирек гасырга сузылды. Очрашкан вакытларда мәктәп укытучылары болай дия иде: "Әлеге әсәрне өйрәнү дәресләрен көтеп алабыз, чөнки алар бик җанлы һәм кызыклы булып үтә, моның төп сәбәбе – хикәянең һәм уйны, һәм хисне кузгатырлык итеп язылган булуында.Аның ярдәмендә балалар яшәешнең мәһим якларын төшенә, үзләре дә күңелләре белән ачыла".

Бу сүзләрне Н.Әхмәдиевнең үзенә дә әйтәләр иде. Чөнки Әлмәт, Азнакай якларындагы мәктәпләрдә ул еш була, аңа күп чакларда әлеге әсәр буенча сөйләшүләрдә катнашырга туры килә. Аңа еш кына сораулар бирәләр, кайбер нәрсәләрне ачыклавын үтенәләр. Димәк, аларны биредә сурәтләнгәннәр мавыктырган, шулай булмаса, балаларны кызыксындырып булмый.

Бу дәресләрне уздыру методикасына кагылышлы язмалар вакытлы матбугатта да күренгәләп барды. Бигрәк тә Казанның 77 нче мәктәп укытучысы Г.Гатауллинаның 2008 елда "Мәгариф" журналының өченче санында басылган мәкаләсе истә калган. Ул "Н. Әхмәдиевнең "Минем туган көнем" хикәясендә шәфкатьлелек, киң күңеллелекнең чагылышы" дип атала. Кеше өчен бик кирәкле әлеге сыйфатларны тәрбияләүдә әсәрнең әһәмиятле якларын аерып күрсәтә.

Берничә елдан соң очрашу насыйп булгач, Нур каләмдәшебез миңа рәхмәт әйтте.

– Мине укучыларның киң даирәсенә, бигрәк тә яшь буынга танытуда бу дәреслекнең роле дә булды, – диде.

Шулай, әсәрләре дәреслекләрдә урын алган авторларны халык тизрәк таный һәм хәтерендә саклый, алар иҗаты белән кызыксынып кала. Бу – күптән расланган хакыйкать.

Хикәянең язылуына утыз елдан артып китте. Әмма аның белән кызыксыну бүген дә дәвам итә. Әле шушы араларда гына аның "Мәдәни җомга" газетасында укучыларга кабат тәкъдим ителүе дә шуны күрсәтә.

Н. Әхмәдиевкә бер үк вакытта оештыручы булу сәләте дә бирелгән иде. Нефтьчеләрнең "Хәзинә" газетасында күп еллар буена редактор булуы шуны раслады. Ул дәвамлы рәвештә Татарстан Язучылар берлегенең Әлмәт бүлегенә җитәкчелек итте һәм зур абруй казанды. Аннан соң әлеге эшнең башына куелган кеше бөтен эшне тарката язды. Ул вакытта мин Татарстан Язучылар берлеге рәисе булып эшли идем. Әлмәт язучыларын ялгыш адымнар ясарга этәрә башлаган бу кешене гомуми җыелышта урыныннан читкә этәреп куярга туры килде. Ләкин кемне сайларга? Эшнең җитдилеген исәпкә алып, Нур Әхмәдиев тагын дилбегәне үз кулына алырга ризалык бирде. Эшне җайга салып, яңа кадр әзерләп, тыныч күңел белән җитәкчелекне аңа тапшырды.

Дөнья булгач, миңа аның туган авылы Әсәйдә дә булырга туры килде. Булган кеше бар яктан да булган шул. Биредә дә ул ата-бабалары нигезен саклаган, үзенә иҗат илһамы килерлек, гаиләсенә яхшы ял итәрлек шартлар булдырган. Миңа йоклау өчен урынны үзенең иҗат кабинетында әзерләп бирде.

– Синең бу бүлмәңдә йоклагач, күңелемә илһам өстәлмәсме? – дип шаяртып алуым истә калган.

Киң карашлы, илһамлы күңелле, чын кеше Нур Гариф улы Әхмәдиев белән аралашу, аның белән эш итү үзе күңелгә рәхәтлек һәм ышаныч бирә иде. Аңа кагылышлы истәлекләрне күңелдә барлаганда да шундый ук халәт кичердем. Замандашлары күңелендә уңай тәэсирләр калдырырлык итеп яшәү үзе бер талант бит. Хәер, шулай булмаса, укучылар күңеленә рәхәтлек өстәрлек әсәрләр язу да мөмкин түгелдер. Кешелекле, игелекле уйлар һәм хисләр белән сугарылган әсәрләре, укылган саен, аңа савап өстәләчәгенә иманым камил.

Фоат ГАЛИМУЛЛИН.

Айга кырын карама

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

29 гыйнвар (шимбә). ***Җомәдел ахир аеның 26 нчы көне. 27 нче Ай тәүлеге. Ай Кәҗәмөгез йолдызлыгында,5.54 сәгатьтә калка, 12.03 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 8.27 сәгать.***

Бу көннәрдә организм хәлсез, шунлыктан күбрәк йоклау файдалы. Нерв системасы, сизү әгъзалары зәгыйфь. Кан һәм лимфа авырулары кискенләшергә мөмкин. Кан басымын контрольдә тоту сорала.

Сөттә пешкән алма

Эч кибүдән интеккәндә, 2 алманы турап, 2 стакан сөт һәм ярты стакан суга салалар, кайнап чыккач, 7 минут пешерәләр, ач карынга ашап бетерәләр. Яисә помидор, чөгендер, кишер, болгар борычы, суганны (төгәл пропорцияләр юк, чөгендер генә башка яшелчәләрдән күбрәк булырга тиеш) иттарткычтан чыгаралар, тоз һәм шикәр кушып, пешерәләр, пыяла банкага салып, суыткычта саклыйлар. Иртән һәм кичен, ашар алдыннан, 1-3 аш кашыгы ашыйлар. Эчәклекнең эше җайга салынсын өчен, бу ризыкны даими куллану зарур.

30 гыйнвар (якшәмбе). ***Җомәдел ахир аеның 27 нче көне. 28 нче Ай тәүлеге. Ай Кәҗәмөгез йолдызлыгында,7.26 сәгатьтә калка, 13.06 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 8.31 сәгать.***

Айның иң яхшы көннәреннән берсе. Энергетикасы бик уңай. Көтелмәгән очрашулар берсеннән-берсе кызыклырак булачак. Хисләр тернәкләнә, аралашу теләге уяна. Сизү әгъзалары, аеруча күзләр зәгыйфь. Кан басымын контрольдә тоту зарур. Организмны чистарту, ач тору уңай нәтиҗә бирә.

Мүк җиләге

Мүк җиләге салкын тигәндә бик файдалы. Аңарда шикәр аз, ә биологик актив матдәләр, пектиннар, лимон һәм алма кислотасы, С, В, РР витаминнары күп. Ул калий, кальций, тимер, йод һәм марганецка бай. Бу җиләк антибиотикларның активлыгын арттыра, ялкынсынуны баса, температураны төшерә, бөердәге таш һәм комны чыгара. Цистит интектергәндә, мүк җиләген кайнар суга салып, салкын урында берничә көн төнәтәләр, аннан соң теләгәнчә эчәләр. Әмма ашказаны кислоталылыгы югары булганда бу җиләкне ашарга ярамый.

31 гыйнвар (дүшәмбе). ***Җомәдел ахир аеның 28 нче көне. 29 нчы Ай тәүлеге. Ай Сукояр йолдызлыгында,7.56 сәгатьтә калка, 14.31 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 7.56 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Бернинди вәгъдәләргә дә ышанырга ярамый. Бизләр системасы, кан тамырлары, эчәклек зәгыйфь. Үзеңне үпкәләткән кешеләрне кичерү зарур.

Ангинадан дәва

4 аш кашыгы бал, 2 аш кашыгы зәйтүн мае, уылган ярты баш суган, 1 чәй кашыгы лимон согын кушып, 4 тәүлек буе һәр 3 сәгать саен 2шәр чәй кашыгы кабалар. Ә йөтәлне йомшарту өчен 1 аш кашыгы ваклаган мандарин кабыгын 1 стакан суда

(**Дәвамы 18 нче биттә**).

Айга кырын карама

15 минут пешерәләр, сөзәләр, көненә 3 тапкыр, ашаганчы, чирегешәр стакан эчәләр.

1 февраль (сишәмбе). ***Җөмәдел ахир аеның 29 нчы көне. 1 нче, 2 нче Ай тәүлекләре. Ай Сукояр йолдызлыгында,8.27 сәгатьтә калка, 16.05 сәгатьтә бата. 8 сәгать 45 минуттан яңа Ай. Көн озынлыгы 8.40 сәгать.***

Тәүбә итү, гармониягә ирешү көне. Иҗат белән шөгыльләнү, айлык план төзү яхшы. Яңа туган Ай Җир белән Кояш арасында, үзенең караңгы ягы белән Җиргә караган. Ай идарә итә торган һәрнәрсә – хисләр, кәеф, хәтер, кан басымы зәгыйфь. Кан басымы болай да түбән булган гипотониклар өчен бигрәк тә авыр вакыт. Бу чорда укуда уңышлар, тиз савыгу, югары эшчәнлеккә өметләнергә ярамый. Ашаганда талымлы булу хәерле. Аралашуны чикләү зарур.

2 февраль (чәршәмбе). ***Рәҗәб аеның 1 нче көне. 3 нче Ай тәүлеге. Ай Балыклар йолдызлыгында, 8.47 сәгатьтә калка, 17.40 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 8.44 сәгать.***

Бик актив көн, хәвеф-хәтәр инстинкты, агрессия белән бәйле. Бүген чирләп китү ихтыяр көченең җитәрлек булмавын күрсәтә. Күзне арытмаска кирәк.

Астмадан – кестәрә

Сулыш кысылганда, астма интектергәндә, дару кестәрәсе (буквица) ярдәм итә. Кичен, эмальләнгән кәстрүлдәге ярты литр суга 2 аш кашыгы вакланган үләнне салып, кайнатып чыгаралар, сүрән утта 7 минут пешерәләр, җылы итеп төреп, төнгелеккә калдыралар. Иртән сөзәләр һәм көненә 3 тапкыр, ашарга 30 минут кала, 150 шәр мл эчәләр. Дәва курсы – 1 ай.

3 февраль (пәнҗешәмбе). ***Рәҗәб аеның 2 нче көне. 4 нче Ай тәүлеге. Ай Балыклар йолдызлыгында, 9.01 сәгатьтә калка, 19.10 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 8.48 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Теләсә нинди элемтә, танышулар, күмәк эш бүген кыен кичерелә. Озаграк йоклау хәерле. Тәмлерәк һәм күбрәк ашау теләге зур булса да, чаманы югалтмаска кирәк. Ач торырга ярамый.

Целлюлитка каршы крем

4 аш кашыгы зәйтүн маена 5 тамчы әфлисун эфир маен кушып болгаталар, целлюлитлы җирләргә сөртеп, 5 минут буе яхшылап ышкыйлар. Юалар. Көнаралаш кабатлаганда, уңай нәтиҗә 3 атнадан соң күренә башлый.

4 февраль (җомга). ***Рәҗәб аеның 3 нче көне. 5 нче Ай тәүлеге. Ай Кучкар йолдызлыгында, 9.11 сәгатьтә калка, 20.36 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 8.52 сәгать.***

Бүген юлда булу әйбәт. Ач тору тыела. Күңел нәрсә тели, күпме тели – шулкадәр ашарга була, бигрәк тә яшелчә файдалы. Башлаган эшне ахырына җиткезү зарур. Ашказаны-эчәк авырулары кискенләшү тискәре энергиянең артык күп туплануын күрсәтә. Кан әйләнеше системасы, ияк, муен, бронхлар зәгыйфь.

Кабак боҗралары

0,5 кг кабак, 2 стакан он, 1 аш кашыгы шикәр, 25 г чи чүпрә, 1 аш кашыгы май (камыр өчен), кыздыру өчен 300 г үсемлек мае, шикәр оны кирәк. Чистартып туралган кабакны газ мичендә томалап пешереп, төяләр. Он, шикәр, чүпрә, май һәм кабак боламыгыннан камыр басалар (ванилин кушарга да була), 2 сәгать кабарталар, аннары боҗралар ясап, тагын 20 минут күпертәләр һәм кайнап торган майда кыздыралар. Суынгач, шикәр оны сибәләр.

Татарстан һәм Казахстан: уртак тамырлар һәм үзгәлек

(Ахыры. Башы 11 нче биттә).

● Астанада Сабан туе.

Көнбатыш Казахстанда, ягъни элекке Кече җүз җирләрендә кайчандыр күчмә тормыш алып барган нугай татарларының варисларына исә иң аз өлеш тиде, «рәнҗетелделәр». Көнбатыш Казахстанда нефть, газ чыгарыла, ә акчалар күбрәк башкала Нур-Солтан һәм Алматы якларына агылганда, элитада исә бары тик диярлек Өлкән (Нурсолтан Назарбаев белән президент Касым-Җомарт Токаев та шул төркемнән) һәм бераз Урта җүз (күбрәк иминлек хезмәткәрләре, хәрбиләр) вәкилләре генә булганда, казахларның бу төркеме үзләрен мәхрүм ителгән дип санады. Ел башындагы протестларның нәкъ менә Актау һәм Җаңаүзән шәһәрләрендә башлануы да тиктомалдан түгел. Нефть чыгару үзәге булган Җаңаүзәндә нәкъ 10 ел элек нефтьчеләрнең протест күтәрелеше утлы корал белән бастырылган иде.

Хәзер казах милләтенең төп сәяси проблемасы – рус телле төньяк җирләре түгел, ә үзләре арасындагы ырулар бүленеше. Ыруларга бүлүне бетерми торып, чын бердәм сәяси казах милләтен оештыру да, илнең территориясен ныклап контрольдә тоту да мөмкин булмаячак. Ә Казахстан кебек зур ил өчен 19 млн халык әле бик аз. Сәяси тотрыксызлык дәвам иткәндә ырулар бүленеше казах дәүләтчелегенең җимерелүенә, сепаратизмга китерергә мөмкин йомшак урын булып кала. Нинди генә сәяси караштa булмасыннар, хәзерге казах патриотлары алдындагы төп бурыч – демократияләштерү һәм сәяси реформалар уздыру гына түгел, ә ыруларга бүленүдән дә арыну булырга тиеш. Территориянең зурлыгын исәпкә алып, илнең бер өлеше дә үзен кимсетелгән дип хис итмәсен өчен, бәлки эчке федеральләштерү турында да уйларга вакыт җиткәндер, әлбәттә, икътисади яктан. Казах милләтен берләштерүнең бердәнбер юлы – ырулар бүленешен бетерү. Һәм сәер яңгырарга мөмкин булса да – бу безнең халыкларны туганлаштыра. Казахлар алдында ырулар бүленешен бетерү бурычы торса, безгә бердәм татар милләтен төрле сәбәпләр табып, ясалма рәвештә читтән бүлгәләү тырышлыкларына нык каршы торырга кирәк. Казахстан мисалында моның мөһим нәрсә булуын ачык күрәбез. Андый бүлгәләнеш китсә, хәтта бәйсез дәүләтең дә тулы гарантия була алмый.

Илнар ГАРИФУЛЛИН,
тарихчы, сәясәт белгече.

Мәк. Тамаша заллары чакыра

Г.КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

28 гыйнвар – 17.00 Шәрык клубында экскурсия һәм артист Алмаз Борһанов белән иҗади очрашу. 19.00 зур залда – Татарстанның халык артисты Ирек Баһмановның 90 еллыгы уңаеннан «Бабайлар чуагы» спектакле (И.Зәйниев). 20.00 кече залда – Премьера. «Киек каз юлы» (И.Мөхәммәтгалиев).
29 гыйнвар – 12.00, 12.30 – «Дәрсе гыйбрәттер театр» (Р.Мөхәммәтшин). 18.00 – «Миркәй белән Айсылу» (Н.Исәнбәт).
30 гыйнвар – 14.00 Шәрык клубында – «Бичара кыз» (Г.Ильяси). 18.00 – «Дон Жуан» (Ж.-Б.Мольер).
1 февраль – «Хуш, авылым» (А.Җаббаров).
2 февраль – «Хуш, авылым. Хыял» (А.Җаббаров).
3 февраль – «Бию пәрие» (И.Зәйниев).
4 февраль – «Тормышмы бу?» (Г.Исхакый).

М.ҖӘЛИЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ҺӘМ БАЛЕТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

30 гыйнвар – 26 февраль – Ф.Шаляпин исемендәге 40-нчы халыкара опера фестивале:
30, 31 гыйнвар – «Тоска» (Дж.Пуччини).
4 февраль – «Пиковая дама» (П.Чайковский).

К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ

28 гыйнвар – «Ядәч! Исемдә! Бер гаилә трагикомедиясе» (Й.Миңнуллина, М.Гафурова, А.Бикбулатов, Э.Дусаева).
29 гыйнвар – «Кияү урлау» (С.Юзеев, Х.Ибраһим тәрҗемәсе).
30 гыйнвар – «Төш» (Т.Миңнуллин).
1 февраль – «Ак тәүбә, кара тәүбә» (Т.Миңнуллин).
2 февраль – «Син бит минем бергенәм» (И.Мәхмүтова).
3 февраль – «Эх, алмагачлары!» (Ш.Фәрхетдинов).

Г.КАРИЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ЯШЬ ТАМАШАЧЫ ТЕАТРЫ

2 февраль – «Сөннәтче бабай» (Г.Исхакый).
3 февраль – «Ак чәчәкләр кебек» (Р.Мухина).
4 февраль – 13.00 – «Кәҗүл читек» (Г.Исхакый). 18.00 – «Арыну» (А.Әхмәдиев, Т.Кулов).

«ӘКИЯТ» ТАТАР ДӘҮЛӘТ КУРЧАК ТЕАТРЫ

28 гыйнвар – Зур залда – Премьера. «Приключения Барона Мюнхгаузена (Р.Распе). Кече залда – «Адәмнәр» (Г.Ибраһимов).
29 гыйнвар – Зур залда – Премьера. «Приключения Барона Мюнхгаузена (Р.Распе). Кече залда – «Кәтүкнең сихри төшләре» (Х.Ибраһим, И.Нәфиев).
30 гыйнвар – 10.00 – «Хәерле иртә!» (Н.Егорова). 12.00, 14.30 – «Страна чудес Алисы» (Л.Кэрролл әсәренә нигезләнеп куелган). 13.00 – «Камыр батыр» (С.Хөсни).
2 февраль – «Страна чудес Алисы» (Л.Кэрролл әсәренә нигезләнеп куелган).
3, 4 февраль – «Приключения Барона Мюнхгаузена» (Р.Распе).

Г.ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ФИЛАРМОНИЯСЕНЕҢ КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

28 гыйнвар – Татарстан дәүләт филармония джаз оркестрына Этери Бериашвили кушылып җырлый.
29 гыйнвар – Филармония әдәби-музыкаль лекториенең композитор Джоаккино Россининең 230 еллыгына багышланган кичәсе.
30 гыйнвар – Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты Айдар Фәйзрахмановның иҗат кичәсе. Катнашалар – җырчылар Ф.Каһиров, А.Хәйри, С.Зәйнетдинова, Алинә һәм Азат Кәримовлар, И.Мөхетдинов, Р.Насыйбуллин, Татарстан Республикасы фольклор музыкасы дәүләт ансамбле һәм Р.Рәхмәтуллин җитәкчелегендәге «Мирас» инструменталь ансамбле, музыкантлар А.Барышникова, И.Камал.
31 гыйнвар – 14.00 – «Илһамлы яшьлек» концерты. 18.30 – Светлана Черныхның музыкаль кунакханәсендә дирижер һөнәре турында фикер алышу.
1, 2 февраль – Татарстанның халык артисты Нәфкать Нигъмәтуллин концерты.
4 февраль – Танеев исемендәге квартет концерты.

С.СӘЙДӘШЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ЗУР КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

30 гыйнвар – Балалар өчен «Lego-music» дип исемләнгән концерт программасы.

Борынгылар әйткән сүзләр

(Мәкальләр һәм әйтемнәр тарихыннан)

Хуҗи МӘХМҮТОВ

(Дәвамы. Башы 2021 елның 40-42 нче, 2022 елның 1 нче саннарында).

КЫЯМӘТТӘ КУЛЫМ ЯКАҢДА БУЛСЫН!

Тулырак варианты: «Кыямәт көнне (ахирәттә) ике кулым якаңда булсын!» Берәүдән үз хакын, әйтик, әҗәткә биреп торган әйберсен, акчасын яки куйган хезмәте өчен тиешле әҗерен ала алмаучы кешенең бурыч түләмәүчегә рәнҗеп һәм янап-куркытып әйтә торган каргыш сүзләре.

Шәригать кануннары, ислам әхлагы буенча кеше хакына керү, мөмкинлегең булып та, алган бурычларыңны кайтармый калу иң зур гөнаһларның берсе итеп санала. Зыян күрүченең ризалыгы, бәхиллеге булмый торып, күпме тәүбә итсәң дә, Аллаһы Тәгалә мондый гөнаһны гафу кылмый. Бу мәсьәләнең Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйиссәлам хәдисләрендә бик еш кузгатылуы һич тә очраклы хәл түгел. Мәсәлән:

«Аллаһы юлында шәһид булу барлык гөнаһларны йола, әмма бурычны ярлыкамый».

«Сезнең иң яхшыларыгыз – бурычларын җиңел түләүчеләр».

«Бурыч бирү сәдака бирүдән яхшырактыр».

«Бурычлы булып вафат иткән адәм кабере эчендә богауланып торыр, бу богаудан аны бурычын үтәү генә азат кылыр» (Ягъни мәетнең якыннары йә варислары бурыч хуҗаларын ризалатырга тиеш).

«Кемдә кеше хакы бар, вафат булганга кадәр кешеләр белән бәхилләшсен. Чөнки кыямәт көнендә кеше хакы аңа файда бирмәс».

Кыямәт көнне хөкем вакытында дөньялыкта үз бурычын кайтара алмаучылар, бурычлы булып калган кешенең якасына ябышып, үз хакларын аннан Ходай каршында даулап алачаклар, ди.

Күзәтелә торган гыйбарә әнә шул җирлектә барлыкка килгән. Матур әдәбиятта да, фольклор әсәрләрендә дә шактый еш очрый. Мәсәлән, Фатих Хөснинең «Утызынчы ел» романында мондый эпизод бар: Галләм хаҗи, Җаббар Гайниясенә барып, аңа биргән әҗәтләре хакында сүз кузгата. Әмма Гайниянең дә кыямәтлек дәгъвасы бар икән хаҗи абзыенда:

«...Гайния, тавышын бераз тыя төшеп... картка беравык текәлеп карап торды: «Дөресен әйтә башласак, хаҗи абзый, теге дөньяда кем кемнең якасыннан алыр бит әле? Капчык төбенә салып җибәргән бер пот борчак оның өчен синме минем якадан алырсың, әллә җәйнең җәй буе тир түгеп эшләтеп тә, рәтле-башлы түләмичә... кайтарып җибәргәнең өчен минме сине боргычлап алырмын?»

Әлеге гыйбарә кергән бер мәзәк белән дә танышып китик:

«Берәү бөтен кешеләрдән бурычка жыя икән. Күршедәге Тукмаклы дигән урыс авылында яшәүчеләрдән дә бик күп әҗәткә алган, ди.

Беркөнне бер кеше моңа бурычын сорап килгән.

– Фәлән абзый, мин бурычымны алырга килдем, биреп кенә җибәрче, – дигән.

Монысы бер дә бирергә теләми икән. Шуннан әлеге кеше ачулана башлаган:

– Бурычымны кайтармасаң, ахирәттә кулым якаңда булсын! – дигән.

Бурыч түләмәүче кеше тирән генә көрсенгән дә әйткән:

– Ярар, нишлисең инде. Әгәр Тукмаклы урысларыннан якамда буш урын калса, син дә ябышырсың, – дигән».

Язучы Гомәр Бәширов шушы мәзәкне үзенең «Туган ягым – яшел бишек» повестенда файдалана. Анда кием тектергән бер хуҗа тегүчеләрнең хезмәт хакын басып калмакчы була.

«Сафа абзый кызарынып-бүртенеп бишмәтенә барып ябышты:

– Алла боерса, моннан соң йортыңа ике аягымның берсен атламам... Кыямәт көнне эш хакымны сорап якаңа ябышырмын!

Картлач, һич исе китмичә, ястыгына кырын ята төшеп:

– Һем! – дип көлемсерәп куйды. - Ябышырсың, якамда Чыпчык урысларыннан буш урын калса. Аларга бирәчәгем ун кәррә артык»

ЛӘМ-МИМ ДӘШМӘҮ

«Ләм-мим» сүзләре Коръәндәге «Бәкара» («Сыер») һ. б. кайбер сүрәләрнең беренче аятьләрендә очрый: «Әлиф ләм мим (мәгънәсен Аллаһ үзе генә беләдер)».

Татар телендә гарәп алфавитыннан кергән байтак хәреф исемнәре әле тагын күчерелмә мәгънәләргә дә ия. (Бигрәк тә элифнең андый мәгънәләре күп.) «Ләм-мим»гә килсәк, ул сөйләшмәүне, сорауга җавап бирә алмый торуны яисә кемдер (нәрсәдер) турында бөтенләй сүз кузгатмауны, берни дә хәбәр итмәүне белдерә...

«Кар ерып йөри торгач, безнең юлчылар яхшы ук арыганнар иде, кайтканда ләммим сөйләшмичә, упкәләшкән кешеләр кебек, берсе алдан, икенчесе арткарак калып кайттылар» *(Фатих Хөсни. Җәяүле кеше сукмагы).*

«Ни генә булмасын, Бакый бик егет кеше ул. Нинди вопрос белән каптырган үзләрен, исеңдәме? Гаҗәп вопрос ул. Озын Талип аңа каршы нәрсәдер мыгырдап маташса да, берәү дә рәтләп тыңламаган. Ә үзләре, сөяккә кадалган төсле, төелеп калганнар, ләм-мим бер сүз әйтә алмаганнар» *(Шәриф Камал. Сайланма әсәрләр: өч томда).*

«Барып җиткәнче тагын бик күпләрнең язмышын сөйләп өлгерде ул, Мостафа белән Нәсимәне генә телгә алмады. Алар турында ләм-мим дәшмәве йөрәкне әллә нинди вәсвәсәләр белән көйдерсә дә, Мәликә әби сабыр гына тыңлап барды» *(Кави Нәҗми. Әсәрләр: дүрт томда).*

«Ләм-мим» мондый күчерелмә мәгънәне ничек хасил иткән соң?

Нәкый Исәнбәт моны «ләм» һәм «мим» сүзләрен әйткән вакытта авызның, иреннәрнең йомылып калуы белән бәйләп аңлата.

МАҢГАЙГА ЯЗУ (МӨҺЕР, ТАМГА БАСУ)

Кешенең һөнәрен, холкын-фигылен тышкы кыяфәтеннән чамалап булса, бу кеше турында: «Аның кемлеге маңгаена язылган инде», – диләр, һәм, киресенчә, кемнедер кыяфәтенә карап кына тану-бәяләү кыен булуны аңлатырга теләгәндә: «Мин аны каян белим, аның кем икәнлеге маңгаена язылып куелмаган бит», – дип әйтәләр.

«Син, энекәш, кешеләрдән курка торган бул, – дип сөйләп китте бакенчы абзый. – ...Кешенең нинди икәне маңгаена язып куелмаган. Әнә, шәһәрдәге кибетләрне күргәнсең, маңгай турыларына язулы калай элгәннәр: бусы – тимер-томыр кибете, бусы – кашык-аяк... Кешеләрнең дә маңгайларында язулары булса, бер төрлесенең янына да килмәс идең, йөз чакрымнан әйләнеп үтәр идең» *(Ибраһим Гази. Онытылмас еллар).*

«Без әле күптән түгел генә ат казылыгын яраткан кешенең маңгаена «милләтче» дигән мөһер суккан заманда яшәдек» *(Миргазиян Юныс. Юлда уйланулар).*

Аңлашыла ки, бу гыйбарәләрдә сүз маңгайга чыннан да нидер язылган яки язылмаган булу турында бармый. Әмма мондый күчерелмә мәгънәнең, әүвәл башлап, туры мәгънәдә кулланылган сүзләрдән килеп чыккан булуы бик ихтимал, һәрхәлдә, татарларга борын-борыннан яхшы таныш булган ислам әдәбиятында «Маңгайга язу» тәгъбире үзенең реаль мәгънәсендә дә очрый. Әйтик, оҗмахтагы кешеләрнең биргә керү бәхетенә баштан укмы, йә булмаса, гөнаһлары өчен бераз тәмуг газабын татыганнан соң гынамы ирешкәнлекләрен аларның маңгайларында шул хакта язу булу-булмауга карап аерырга мөмкин икән:

«Мөхәммәд пәйгамбәр аннан соң мөселманнарны, шәфәгать кылып, җәһәннәмнән чыгарыр вә тереклек елгасына алып барып коендырып, аларга җәннәткә керергә ярдәм итәр. Һәрбарчасы яшьләр сыйфатында сакалсыз, мыексыз булырлар, йөзләре ай шикелле булыр, ләкин маңгайларында «җәһәннәмлеләр, уттан Аллаһының азат булганнары» дип язылган булыр» *(Имам-хатыйб Идрис Галәветдин. Җәннәт вә җәһәннәм).*

Әлбәттә, реаль тормышта да маңгайга язу, тамга-билге салу күренеше киң таралган була. Рус телендәге «У него на лбу написано» әйтелмәсе борынгы рус дәүләтендә җинаятьчеләрнең маңгайларына кыздырылган тимер белән келәймә сугудан килеп чыккан, дип аңлаталар. Алексей Михайлович патшалык иткән чорда (XVII йөз) келәймә урынына, яндырып, «б» дип («бунтовщик» сүзенең беренче хәрефе) яза башлаганнар. Күрәсең, әйтелмәнең «Маңгайга хурлык тамгасы басу» дигән вариантында әнә шундый күренешләрнең тәэсире чагыладыр:

«Тукайның тапкыр сүзне һичкемнән тартынмый әйтү кыюлыгын, милләтчеләрне, карагруһчыларны бөтен ил каршында адәм көлкесе ясавын, маңгайларына мәңге бетмәс хурлык тамгасы басу сәләтен электән үк белә иде ул» *(Кави Нәҗми. Әсәрләр: дүрт томда)*

«Маңгайга язу (язылу)» гыйбарәсе үзенең килеп чыгышы ягыннан элеккеге сынчылык күренешенә бәйләнгән булырга да мөмкин. Нәкый Исәнбәт язганча, борынгы сынчылар, кешенең йөзенә, кыланышына бераз карап торгач, читләтеп бер-ике сорау белән, аның нәселен, чыгышын, үзенең кемлеген һәм киләчәк язмышын әйтеп бирергә тиеш булганнар. Халык иҗатында кешенең төс-бит, буйсын үзенчәлекләренә карап, аның нинди холыклы, нәрсәгә сәләтле булуын (яки булачагын) чамалап әйтә торган махсус юрау сүзләре дә күп. Алар арасында кешене маңгай төзелешенә карап сынауга нигезләнгәннәре дә бар: «Маңгае киң кешенең зиһене яхшы була», «Маңгае тарның – акылы тар», «Маңгае ак – йөзе пакь» һ. б.

Бер уңайдан, «Маңгайга язылу» гыйбарәсенең башка мәгънәләренә һәм мәгънә төсмерләренә дә күз салып үтик. Элеккерәк вакытларда ул «кешенең язмышы алдан ук билгеләнеп куела» дигән ышануны да аңлатып йөргән. Моны «Маңгайга язган җуелмый», «Маңгайга язылган язмышны тир белән сыпырып төшереп булмый» кебек мәкальләрдән яисә «Безнең лә болай буласыбыз туган көнне маңгайга язылган», «Маңгайга ла язылган язмышларны сыпырып ташлап булмый җиң белән» дигән җыр юлларыннан күрергә мөмкин. Яки менә матур әдәбияттан бер-ике мисал:

«– Көфер сүз сөйлисең, Бибиҗиһан, тәкъдирдә язылганга ышанмыйсыңмы әллә син? Маңгаеңа язылмаган, шуңа баемыйсың син...» *(Әхмәт Фәйзи. Әсәрләр: биш томда).*

Ниһаять, «бик нык кисәтеп, хәтердә сакланырлык итеп әйтү» дигәнне белдерү өчен дә «Маңгайга язу» гыйбарәсен кулланалар. Бу очракта ул «Колакка киртләү» әйтелмәсе белән мәгънәдәш була.

«Менә бу максатны маңгаегызга язып куегыз да, мөфтиләр, муллалар, партиясез зыялылар мәсьәләсе белән демагогия, провокация ясарга уйлаганда, саграк маташыгыз!» *(Галимҗан Ибраһимов. Әсәрләр: сигез томда).*

Чир җиңеләчәкме?

Германия һәм Британия галимнәре Альцгеймер авыруыннан эксперименталь вакцина уйлап тапкан. Чир баш мие күзәнәкләрендә амилоид бета-аксымы тупланудан башлана, шунлыктан традицион дәва әлеге аксымны юкка чыгаруга юнәлтелә. Хәзер исә галимнәр яңа дәва системасы тәкъдим итә – ул бета-амилоидка күп санлы молекулалардан “йомгак” булып тупланырга мөмкинлек бирмәячәк. Лестер университеты һәм Геттинген университеты медицина үзәге белгечләре тычканнарда уңышлы сынау үткәргән инде: иртә стадиядә вакцина кадалган кимерүчеләрдә деменция билгеләре пәйда булмаган. Яңа препарат нигезендә TAP01 антитәнчеге ята, зыянлы аксымга кушыла да, ул аның молекулаларына “йомгак” булып төенләнергә комачаулый, шул рәвешле Альцгеймердан саклый. Әлеге мәкерле чир исә деменция башлануның төп сәбәбе булып тора. Ул баш мие күзәнәкләрен җимерә һәм андагы хәбәр тапшыра торган нерв очлары эшен боза. Кагыйдә буларак, Альцгеймер авыруы өлкән яшьтәгеләрне интектерә. Беренчел билгеләре – хәтер һәм когнитив функцияләр начараю, кәеф төшү. Галимнәр инде озак вакыттан бирле әлеге чирне нәтиҗәле диагностикалау һәм дәвалау ысулларын эзли, әмма ул хәзергә кадәр ел саен миллионлаган кешене бимазалый. Иң мөһим проблемалардан берсе – аның авыруларда соң ачыклануы. Alzheimer’s Disease International оешмасы бәяләвенчә, Альцгеймер чире китереп чыгарган деменция очракларының 90 проценты диагноз куелмаган килеш кала. Якын арада яңа вакцина кешедә сынала башлаячак, һәм аның нәтиҗәлелеге расланса, бу медицина өчен бик зур казаныш булачак. Лестер университетының Структуралы һәм химик биология институты профессоры Марк Карр әйтүенчә, клиник сынаулар уңышлы узса, бу кешегә Альцгеймер симптомнары табылганнан соң дәвалануны гына түгел, бәлки алдан ук вакцина кадатып чирдән саклану мөмкинлеген дә бирәчәк.

(“РБК”).

Иң кыска һәм иң озын

Хәзер башкалабызда туристлар бик күп. Еш кына алар беренче карашка бик гади тоелган сораулар да биреп куйгалый. Аптырап калмас өчен, шуларның берничәсенә җавап әзерләп куйыйк әле. Мәсәлән, Казанның иң озын урамы – Җиңү проспекты яки Көньяк магистраль. Әлеге алты юллы урам 9,8 чакрымга сузыла. (Әмма кайберәүләр ТЭЦ урамы аннан озынрак – 9,9 чакрым, дип саный.) Декабристлар урамының озынлыгы 4,5 чакрым тәшкил итә. Иң кыскасы – 70 метрлы Кечкенә урам. Анда нибары бер йорт тора. Кайчандыр биредә сугышка кадәр Болакны яңартып корган кеше, “Татпроект” җитәкчесе Үзбәк Алпаров; Казанның баш архитекторы Георгий Солдатов; элекке хәрби разведчик Алекс, шулай ук архитектор Шәүкәт Зөбәйдуллин; стадион, “Татарстан” кунакханәсе, консерваториянең һәм филармониянең концерт заллары, ветеринария институты, Сөембикә манарасын ныгыту проектының, Казан циркының инженерлык чишелеше авторы, атаклы Осия Берим; композитор Әнвәр Бакиров яшәгән. Иң тар урам – Иске Татар бистәсендәге Күнче, аның киңлеге – 3,5 метр, озынлыгы – 100 метр. Шәһәрдәге иң зур мәйдан – Кремль янындагы элеккеге Ташаяк, хәзерге Меңьеллык мәйданы, ул 90 мең квадрат метр урын били. Башкаладагы иң борынгы мөселман һәйкәле - Мәрҗани мәчете 1770 елда салынган. Шәһәрдә иң озын автобус маршруты – 46 нчы. Киров районыннан Идел буе районына кадәр ара 39 километр тәшкил итә, 57 тукталышы бар. Иң кыска маршрут – Авиатөзелеш районындагы 42 нче автобусныкы (озынлыгы 8 чакрым, 16 тукталышы бар). Россиядә иң озын трамвай маршруты да Казанда - 5 нче линиянең озынлыгы 34 километрга тәңгәл.

(“Sntat.ru”).

Дару түгел, агу

Аризона университеты галиме Шоун Юнгштедт йоклата торган даруларны көн саен бер кап тәмәке тарткан кебек үк зыянлы, дип саный. Алар йөрәк өянәге ихтималын арттыра һәм баш миен зарарлый, акылны зәгыйфьләндерә, вестибуляр аппарат эшен боза. Йокысызлыктан бөтен дөнья халкы интегә. Мәсәлән, АКШта гына да бүген андыйлар саны 100 миллионнан артып китә, аларның күпчелеге дарусыз йоклап китә алмый. Хәзер бу даруларның “Z-препаратлар” дигән яңа буыны пәйда булган, алар бәйлелек тудырмый, дип исәпләнә. Тик аларны кулланучыларның да реакциясе акрыная, чөнки даруларның тәэсире көндез дә саклана. Шунлыктан йокы даруы бик күп автомобиль һәлакәтләренең сәбәбе булып тора. Вашингтон университетында үткәрелгән тикшеренү йокы даруының акылны зәгыйфьләндерүен дәлилләгән. Инглиз галимнәре исә киң таралган йокы даруларының үпкә ялкынсынуы куркынычын арттыруын ачыклаган. Шунлыктан, доктор Юнгштедт әйтүенчә, тиз йокыга китү өчен җиңелчә физик күнегүләр ясау, җәяү яки велосипедта йөреп керү күпкә файдалырак.

(“Die Presse”).

Сабый чактан әзерлиләр

Кытайда урта сыйныф гаиләләре балаларын ничек тә үзләреннән яхшырак яшәтү турында хыяллана. Кече яшьтән үк зур компания белән идарә итү серләренә төшендерү өчен, сабыйларын бизнес дәресләренә йөртәләр. Генераль директорлар курсына өч яшьтән язылалар. Бәләкәчләр җөмләдәге җитмәгән сүзләрне табу, уенчык кирпеч өю белән шөгыльләнә. Курс авторлары әйтүенчә, бу балаларда лидерлык сыйфатын үстерә. Кайбер әти-әниләргә мондый дәресләрнең күбрәк уен формасында алып барылуы ошап бетмәсә дә, алар яшь җитәкче мәктәбенә түккән акчаларын кызганмый, чөнки бу гаиләнең җәмгыятьтә тоткан урыны югары булуын күрсәтә икән. Дәресләр уртача 50 мең юань тора. Белгечләр мондый дәресләрнең бала психикасына зыян гына китерүен аңлатса да, генераль директор үстерәсе килгән ата-ана җәйге гольф лагерьлары, атта йөрергә өйрәтү һ.б. курслар өчен акча түгүен дәвам итә.

(“Синьхуа”).





Челтәр картиналар

Венгриядә яшәүче рәссам Агнес Герцег җептән инсталляцияләрен тиңе булмаган техникада иҗат итә – үзе ул аларны “челтәр фотосурәтләр” дип атый. Төрле төстәге җепләрдән тыш, Агнес миниатюраларында агач кайрысы һәм ботакларын, кокос чикләвеге кабыгын файдалана. Рәссам текстиль белән эшләргә Венгрия сынлы сәнгать университетында өйрәнгән, аннары чигү һәм челтәр бәйләү осталыгын исскиткеч камилләштергән.

(“Livemaster.ru”).

Газета өчен
Алсу ЗӘЙДУЛЛИНА әзерләде.

Дүшәмбе

31 гыйнвар

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «КАЙДА СИН?» 12+
10.00, 23.00 «КОРОЛЕВА ИГРЫ». 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
13.00 «Семь дней».». 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество». 12+
14.45 «Аулак өй». 6+
15.15 «Акыл баттл» һәм «Сәйлән».
16.00 «Әдәби хәзинә». 6+
18.00 «Мин». 12+
19.00, 20.00 «Таяну ноктасы». 16+
21.00 «Tatarstan today. Открытый миру». 12+
22.00 «Вызов 112». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

6.00, 13.00 «Манзара». 6+
7.15, 19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
8.40, 23.05 «Башваткыч». 12+
9.50 «Семь дней». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 22.20 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
14.00 «Ком сәгате». 12+
15.20 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «НАУЧИ МЕНЯ ЖИТЬ». 16+
10.30 «ВОЛЬНАЯ ГРАМОТА». 16+
11.30, 17.10 «ФАМИЛЬНЫЕ ЦЕННОСТИ». 16+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «БАРАНЫ». 12+
15.00 «Это лечится». 12+
15.30 «Страшно. Интересно». 12+
16.20 «Кошечки-собачки».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
21.00 «СЛУЧАЙНАЯ НЕВЕСТА». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00, 9.25 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.50 «Жить здорово!» 16+
10.55 «Модный приговор». 6+
12.15, 17.00 «Время покажет». 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
18.40 «На самом деле». 16+
19.45 «Пусть говорят». 16+
21.00 «Время».
21.30 «ЦЫПЛЕНОК ЖАРЕНЫЙ». 16+
23.25 «Вечерний Ургант». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30 «Судьба человека с Борисом Корчевниковым». 12+
12.40, 18.40 «60 Минут». 12+
14.55 «ТАЙНЫ ГОСПОЖИ КИРСАНОВОЙ». 12+
17.15 «Андрей Малахов. Прямой эфир». 16+
21.20 «СКЛИФОСОВСКИЙ». 16+
23.35 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.20, 10.00, 15.00, 19.30, 23.50 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Невский ковчег. Теория невозможного. Огнеслав Костович.
7.35 «Русские в океане. Адмирал Лазарев».
8.30 Легенды мирового кино.
8.55, 16.35 «ПАРИ», «ЛИМОННЫЙ ТОРТ», «ПОКОРИТЕЛИ ГОР».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 «Народный артист СССР Алексей Грибов».
12.20 «Дом на гульваре».
13.15 Линия жизни. Эдгард и Аскольд Запашные.
14.20 «Загадка ЛК-1. Леонид Куприянович».
15.05 Новости. Подробно. АРТ.
15.20 «Агора».
16.25 Цвет времени. Надя Рушева.
17.40 Музыка эпохи барокко. Ансамбль I Gemelli. К.Коццолани. «Вечерня Пресвятой Богородицы».
18.40 «Настоящая война престолов».
19.45 Главная роль.
20.05 «Правила жизни».
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.45 85 лет Регимантасу Адомайтису. Острова.
21.25 «Сати. Нескучная классика...»
22.05 «ВЗРОСЛЫЕ ДЕТИ».
23.20 «Запечатленное время».

«НТВ»

4.55 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.15 Сегодня.
8.25, 10.25 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ». 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие.
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «НЕВСКИЙ. ОХОТА НА АРХИТЕКТОРА». 16+
23.35 «ПЁС». 16+

Сишәмбе

1 февраль

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «КАЙДА СИН?» 12+
10.00, 23.00 «КОРОЛЕВА ИГРЫ». 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте». 12+
11.15 «Память сердца». 12+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
13.00 «Оныта алмыйм...»
13.30 «Юлчы». 6+
14.00 «Путь». 12+
14.15 «Не от мира сего...» 12+
14.45 «Аулак өй». 6+
15.15 «Уймак» һәм «Сәйлән».
16.00 «Ватандашлар». 12+
18.00 «Казаннан - казанга». 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Күчтәнәч».
21.00 «Чёрное озеро». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
7.15, 19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
8.40, 23.05 «Җырлыйк әле!» 6+
9.40, 16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
10.30, 20.30 «Халкым минем». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 22.20 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
14.00 «Ком сәгате». 12+
15.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
16.30 «Тамчы-шоу». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «НАУЧИ МЕНЯ ЖИТЬ». 16+
10.30, 21.00 «СЛУЧАЙНАЯ НЕВЕСТА». 16+
11.30, 17.10 «ФАМИЛЬНЫЕ ЦЕННОСТИ». 16+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «ТИХАЯ СЕМЕЙНАЯ ЖИЗНЬ». 16+
14.35 «Люди РФ». 12+
15.00 «Клинический случай». 12+
15.30 «Погоня за вкусом». 16+
16.30 «Три кота».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00, 9.25 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.50 «Жить здорово!» 16+
10.55 «Модный приговор». 6+
12.15, 17.00 «Время покажет». 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
18.40 «На самом деле». 16+
19.45 «Пусть говорят». 16+
21.00 «Время».
21.30 «ЦЫПЛЕНОК ЖАРЕНЫЙ». 16+
23.25 «Вечерний Ургант». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30 «Судьба человека с Борисом Корчевниковым». 12+
12.40, 18.40 «60 Минут». 12+
14.55 «ТАЙНЫ ГОСПОЖИ КИРСАНОВОЙ». 12+
17.15 «Андрей Малахов. Прямой эфир». 16+
21.20 «СКЛИФОСОВСКИЙ». 16+
23.35 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.20, 10.00, 15.00, 19.30, 23.50 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05, 20.05 «Правила жизни».
7.35, 18.40 «Настоящая война престолов».
8.30 Легенды мирового кино.
9.00, 16.35 «СУББОТНИЙ ВЕЧЕР», «ТРИ РУБЛЯ», «БАБОЧКА».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 80 лет Льву Лещенко. XX век. «Споемте, друзья». Ведущий Лев Лещенко.
12.15 «ВЗРОСЛЫЕ ДЕТИ».
13.25, 23.20 «Запечатленное время».
13.50 «Игра в бисер» «Михаил Булгаков. «Записки юного врача».
14.30 «Рэгтайм, или Разорванное время». «Истории с фотографиями. Таланты и поклонник-я».
15.05 Новости. Подробно. Книги.
15.20 «Эрмитаж».
15.50 «Сати. Нескучная классика...»
17.35 Музыка эпохи барокко. Сэр Джон Элиот Гардинер, Хор Монтеверди и Английские барочные солисты. И.С.Бах. Ж.-Ф.Рамо.
18.30 Цвет времени. Марк Шагал.
19.45 Главная роль.
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.45 Искусственный отбор.
21.25 «Белая студия».
22.10 «РАФФЕРТИ».

«НТВ»

4.55 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.15 Сегодня.
8.25, 10.25 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ». 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие.
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «НЕВСКИЙ. ОХОТА НА АРХИТЕКТОРА». 16+
23.35 «ПЁС». 16+

Чәршәмбе

2 февраль

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00 «КАЙДА СИН?» 12+
10.00, 23.00 «КОРОЛЕВА ИГРЫ». 16+
11.00 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
13.00, 0.50 «Җырлыйк әле!» 6+
14.00 «Азбука долголетия». 6+
14.15 «Если хочешь быть здоровым...» 12+
14.45 «Аулак өй». 6+
15.15 «Шома бас» һәм «Калеб».
16.00 «Переведи!» 6+
17.00 «КАЙДА СИН?» 12+
18.00 «Халкым минем...» 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Күчтәнәч».
21.00, 0.00 «Соотечественники». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05, 8.40, 23.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
7.15, 19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
9.40 «Ачыктан-ачык». 12+
10.30, 20.30 «Юлчы». 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 22.20 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
14.00 «Ком сәгате». 12+
15.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Яшьләр тукталышы». 12+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «НАУЧИ МЕНЯ ЖИТЬ». 16+
10.30, 21.00 «СЛУЧАЙНАЯ НЕВЕСТА». 16+
11.30, 17.10 «ФАМИЛЬНЫЕ ЦЕННОСТИ». 16+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «4 ЛИЦА МОНЫ ЛИЗЫ». 12+
14.35 «Люди РФ». 12+
15.00 «Эпидемия». 12+
15.30 «Зов крови». 16+
16.20 «Три кота».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00, 9.25 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.50 «Жить здорово!» 16+
10.55 «Модный приговор». 6+
12.15, 17.00 «Время покажет». 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
18.40 «На самом деле». 16+
19.45 «Пусть говорят». 16+
21.00 «Время».
21.30 «ЦЫПЛЕНОК ЖАРЕНЫЙ». 16+
22.30 «Док-ток». 16+
23.25 «Вечерний Ургант». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30 «Судьба человека с Борисом Корчевниковым». 12+
12.40, 18.40 «60 Минут». 12+
14.55 «ТАЙНЫ ГОСПОЖИ КИРСАНОВОЙ». 12+
17.15 «Андрей Малахов. Прямой эфир». 16+
21.20 «СКЛИФОСОВСКИЙ». 16+
23.35 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.20, 10.00, 15.00, 19.30, 23.50 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05, 20.05 «Правила жизни».
7.35, 18.40 «Настоящая война престолов».
8.30 Легенды мирового кино. Фаина Раневская.
9.00, 16.35 «ТЕРМОМЕТР», «ТРИ ЖЕНИХА», «УДАЧА».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 «Хоккей, хоккей...»
12.10, 22.10 «РАФФЕРТИ».
13.15, 23.20 «Запечатленное время».
13.45 День разгрома советскими войсками немецко-фашистских войск в Сталинградской битве. «Чистая победа. Сталинград».
14.30 «Рэгтайм, или Разорванное время». «Красота - ошибка Бога или удача?»
15.05 Новости. Подробно. Кино.
15.20 «Библейский сюжет».
15.50 «Белая студия».
17.35 Музыка эпохи барокко. Уильям Кристи и ансамбль Les Arts Florissants. «В итальянском саду».
19.45 Главная роль.
20.30 «Часовой детства».
21.25 Абсолютный слух.

«НТВ»

4.55 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.15 Сегодня.
8.25, 10.25 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ». 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие.
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «НЕВСКИЙ. ОХОТА НА АРХИТЕКТОРА». 16+
23.35 «ПЁС». 16+

Пәнҗешәмбе

3 февраль

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «КАЙДА СИН?» 12+
10.00, 23.00 «КОРОЛЕВА ИГРЫ». 16+
11.00 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
13.00 «Кәмит Җәвит». 16+
14.00 «Здоровая семья: мама, папа и я». 6+
14.15 «Фолиант в столетнем переплёте». 12+
14.45 «Аулак өй». 6+
15.15 «Бергәләп өйрәник» һәм «Сәйлән».
16.00 «Казаннан - казанга». 12+
18.00 «Юлчы». 6+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Күчтәнәч».
21.00 «Ватандашлар». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
7.15, 19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
8.40, 23.05 «Кәмит Җәвит». 16+
9.40 «Йөрәктән - йөрәккә». Әмирхан Еники турында телеочерк. 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 22.20 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
14.00 «Ком сәгате». 12+
15.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Халкым минем». 12+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.30 «Йөрәктән-йөрәккә». Фатыйх Хөсни турында телеочерк. 6+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «НАУЧИ МЕНЯ ЖИТЬ». 16+
10.30, 21.00 «СЛУЧАЙНАЯ НЕВЕСТА». 16+
11.30, 17.10 «ФАМИЛЬНЫЕ ЦЕННОСТИ». 16+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «ИТАЛЬЯНЕЦ». 16+
14.30 «Люди РФ». 12+
15.00 «Это лечится». 12+
15.30 «Вокруг света. Места силы». 16+
16.30 «Три кота».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00, 9.25 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.

9.50 «Жить здорово!» 16+
10.55 «Модный приговор». 6+
12.15, 17.00 «Время покажет». 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
18.40 «На самом деле». 16+
19.45 «Пусть говорят». 16+
21.00 «Время».
21.30 «ЦЫПЛЕНОК ЖАРЕНЫЙ». 16+
22.30 «Большая игра». 16+
23.25 «Вечерний Ургант». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30 «Судьба человека с Борисом Корчевниковым». 12+
12.40, 18.40 «60 Минут». 12+
14.55 «ТАЙНЫ ГОСПОЖИ КИРСАНОВОЙ». 12+
17.15 «Андрей Малахов. Прямой эфир». 16+
21.20 «СКЛИФОСОВСКИЙ». 16+
23.35 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.20, 10.00, 15.00, 19.30, 23.50 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 «Правила жизни».
7.35, 18.40 «Настоящая война престолов».
8.30 Легенды мирового кино.
8.55, 16.35 «В.ДАВЫДОВ И ГОЛИАФ», «ИСТОРИЯ ОДНОГО ПОДЗАТЫЛЬНИКА».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 XX век. Концерт народного артиста СССР Сергея Яковлевича Лемешева в Колонном зале Дома Союзов.
12.20, 22.10 «РАФФЕРТИ».
13.25 «Запечатленное время».
13.50 Абсолютный слух.
14.30 «Рэгтайм, или Разорванное время». «Истории с фотографиями. Немного о друзьях».
15.05 Новости. Подробно. Театр.
15.20 Моя любовь - Россия! «Вкус абазинской халвы».
15.50 «2 Верник 2».
17.40 Музыка эпохи барокко. Филипп Жарусски, Жюльен Шовен и камерный оркестр Le Concert de la Loge.
19.45 Главная роль.
20.05 Открытая книга. Александр Пелевин. «Покров-17».
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.45 «Старший сын» молодого драматурга».
21.25 «Энигма. Пётр Бечала».
23.20 «Лионский зал. Золото на голубом».

«НТВ»

4.55 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.15 Сегодня.
8.25, 10.25 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ». 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие.
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «НЕВСКИЙ. ОХОТА НА АРХИТЕКТОРА». 16+
23.35 «ЧП. Расследование». 16+

Җомга

4 февраль

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «КАЙДА СИН?» 12+
10.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 6+
11.00 «Нәсыйхәт». 6+
11.30, 16.30, 21.00 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
13.00 «Башваткыч». 12+
14.00 «Актуальный ислам». 6+
14.15 «Рыцари вечности». 12+
14.45 «Аулак өй». 6+
15.15 «Төмә» һәм «Сәйлән».
16.00 «Мин». 12+
18.00 «Туган җир». 12+
19.00, 20.00 «Точка опоры». 16+
22.00 «Вызов 112». 16+
23.50 «ИСЧЕЗНОВЕНИЕ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
7.15, 19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
8.40, 14.00, 23.05 «Ком сәгате». 12+
9.40, 16.30 «Нәсыйхәт». 6+
10.30 «Казаннан казанга». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 22.20 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
15.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
20.00 «Йөрәктән-йөрәккә». Ләбиб Лерон турында телеочерк. 6+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «НАУЧИ МЕНЯ ЖИТЬ». 16+
10.30 «СЛУЧАЙНАЯ НЕВЕСТА». 16+
11.30, 17.10 «ФАМИЛЬНЫЕ ЦЕННОСТИ». 16+
12.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00, 23.50 «БОЛЬШИЕ НАДЕЖДЫ». 12+
15.10 «Клинический случай». 12+
15.40 «Это реальная история». 16+
16.40 «Три кота».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.30 «Fam TV». 16+
21.00 «КРИК СОВЫ». 12+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

4.45 Зимние Олимпийские игры. Фигурное катание. Танцы.
10.00 «Жить здорово!» 16+
11.00 «Модный приговор». 6+
12.00, 15.00, 18.00 Новости.
12.15, 17.00 «Время покажет». 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
18.40 «Человек и закон». 16+
19.45 «Поле чудес».
21.00 «Время».
21.30 Зимние Олимпийские игры.
23.30 «Вечерний Ургант». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 20.45 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.10, 20.00 Вести.
11.30 «Судьба человека с Борисом Корчевниковым». 12+
12.40, 18.40 «60 Минут». 12+
15.00 Церемония открытия XXIV Зимних Олимпийских игр.
17.30 «Андрей Малахов. Прямой эфир». 16+
21.00 «Возможно всё!» 16+
23.00 «МИЛЛИАРД». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.20, 10.00, 15.00, 19.30, 23.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 «Правила жизни».
7.35 «Настоящая война престолов».
8.30 «Первые в мире».
8.45, 16.20 «ЖИЛ-БЫЛ НАСТРОЙЩИК...»
10.15 «БАБЫ».
11.40 Открытая книга. Александр Пелевин. «Покров-17».
12.10 «РАФФЕРТИ».
13.20 «Лионский зал. Золото на голубом».
13.50 Власть факта. «Метаморфозы прогресса».
14.30 «Рэгтайм, или Разорванное время». «Оценка».
15.05 Письма из провинции.
15.35 «Энигма. Пётр Бечала».
17.30 Музыка эпохи барокко. Люка Дебарг. Д.Скарлатти. Сонаты.
18.15 «Царская ложа».
19.00 «Смехоностальгия».
19.45 «Олимпионики».
20.10 85 лет Роберту Ляпидевскому. Линия жизни.
21.05 «ТРЕМБИТА».
22.40 «2 Верник 2».
23.50 «ДИКАРЬ».

«НТВ»

4.55 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 Сегодня.
8.25, 10.25 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ». 16+
11.00, 14.00 «МЕНТОВСКИЕ ВОЙНЫ». 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие.
16.45 «ДНК». 16+
17.55 «Жди меня». 12+
20.00 «НЕВСКИЙ. ОХОТА НА АРХИТЕКТОРА». 16+
23.20 «Своя правда». 16+

Шимбә

5 февраль

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
6.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 6+
7.00 «Sиңа Миннән Sәлам». 6+
9.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
10.00 «Кайнар хит». 12+
11.00 «Мин». 12+
11.30 «Казаннан - казанга». 12+
12.00, 0.45 «Каравай». 6+
12.30 «Видеоспорт». 12+
13.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
13.30 «Күңелем минем...» Җәвит Шакировның 60 яшьлек юбилей кичәсе. 6+
15.30 «Юлчы». 6+
16.00 «Әйдә, шаяРТ!» 12+
17.00 «Әдәби хәзинә». 6+
17.30 «Татарлар». 12+
18.00 «Кәмит Җәвит». 16+
19.00 «Халкым минем...» 12+
19.30, 21.30 Новости в субботу. 12+
20.00 «Адымнар». 12+
20.30 «Җырлыйк әле!» 6+
22.00 «КунакБиТ- шоу». 12+
23.00 «РИМСКИЕ СВИДАНИЯ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00 «Йөрәктән - йөрәккә». Илтани Илялова турында телеочерк. 6+
7.00, 15.00 «Sиңа Миннән Sәлам». 6+
9.00 «Кәмит Җәвит». 16+
10.00 «Кайнар хит». 12+
11.00, 18.15 «Башваткыч». 12+
12.05, 19.05 «Җырлыйк әле!» 6+
13.00 Спектакль «Әрем исе». 12+
17.10 «Казаннан казанга». 12+
17.45 «Халкым минем». 12+
20.00 «Адымнар». 12+
20.30 «КазАнга КазандА». 12+
21.40 «Сагынырлык булсын...» Марат Кәбировның иҗат кичәсе. 6+

«ЭФИР»

5.00 «Люди РФ». 12+
5.30 «Опыты дилетанта». 12+
6.00 «Мировой рынок». 12+
7.00 «Сказочный патруль».
8.00 «Непростые вещи». 12+
8.35 «МИЛЛИОНЕРША». 12+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «ВЕЧНОСТЬ МЕЖДУ НАМИ». 12+
14.45 «Все, кроме обычного». 16+
16.00 «СЕМЕЙНЫЙ БИЗНЕС». 12+
18.05 «ПСИХОЛОГИНИ». 16+
19.00 «Город». 16+
21.00 «ЛЕГОК НА ПОМИНЕ». 12+
22.30 «Человек - невидимка». 16+
23.25 «Дружить по-русски!» 18+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

6.00 «Доброе утро. Суббота».
9.00 «Умницы и умники». 12+
9.45 «Слово пастыря».
10.00, 11.30 Новости.
10.20 К юбилею Льва Лещенко. «Все, что в жизни есть у меня». 12+
11.45 Зимние Олимпийские игры. Биатлон.
13.20 «Лихая музыка атаки». 12+
14.25 «Видели видео?» 6+
16.15 «Кто хочет стать миллионером?»
17.50 «Сегодня вечером». 16+
19.50 Юбилейный концерт Льва Лещенко «Созвездие Льва». 12+
21.00 «Время».
21.20 «Созвездие Льва». 12+
22.55 Дневник Олимпийских зимних игр.
23.55 «ОТЕЛЬ «ГРАНД БУДАПЕШТ». 16+

«РОССИЯ»

5.00 «Утро России. Суббота».
8.00 Вести. Местное время.
8.20 Местное время. Суббота.
8.35 «Формула еды». 12+
9.00 «Пятеро на одного».
9.50 «Сто к одному».
10.45 XXIV Зимние Олимпийские игры. Лыжные гонки.
11.45 Вести.
12.15 «Юмор! Юмор! Юмор!!!» 16+
13.20 «ДЕВЯТЬ ЖИЗНЕЙ». 16+
18.00 «Привет, Андрей!» 12+
20.00 Вести в субботу.
21.00 «НЕ ОГЛЯДЫВАЙСЯ НАЗАД». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Библейский сюжет».
7.05 Мультфильмы.
8.30 «СУРОВЫЕ КИЛОМЕТРЫ».
10.00 «Обыкновенный концерт с Эдуардом Эфировым».
10.25 «Передвижники. Иван Похитонов».
10.55 «ТРЕМБИТА».
12.30 «Эрмитаж».
12.55 «В царстве белоголового лангура».
13.50 «Эффект бабочки».
14.20 Церемония вручения премии «За верность науке».
16.20, 23.55 «ВЫЛЕТ ЗАДЕРЖИВАЕТСЯ».
17.40 «Ксения - дочь Ксении...»
18.20 «Старший сын» молодого драматурга».
19.00 «Отцы и дети».
19.30 «Энциклопедия загадок».
20.00 «ПРОФЕССИЯ: РЕПОРТЕР».
22.00 «Агора».
23.00 Клуб «Шаболовка, 37».

«НТВ»

5.00 «ЧП. Расследование». 16+
5.25 «МОЛОДОЙ». 16+
7.20 Смотр.
8.00, 10.00 Сегодня.
8.20 «Готовим с Алексеем Зиминым».
8.50 «Поедем, поедим!»
9.25 «Едим дома».
10.20 «Главная дорога». 16+
11.00 «Живая еда с Сергеем Малозёмовым». 12+
12.00 «Квартирный вопрос».
13.05 «Однажды...» 16+
14.00 «Своя игра».
15.00 «ПЯТЬ МИНУТ ТИШИНЫ. ВОЗВРАЩЕНИЕ». 12+
19.00 «Центральное телевидение».
20.20 «Ты не поверишь!» 16+
21.20 «Секрет на миллион». 16+
23.25 «Международная пилорама». 16+

Якшәмбе

6 февраль

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
6.00 «Гомер китабы». Лилия Муллагалиева концерты. 6+
8.00, 13.00 «Адымнар». 12+
8.30 «Хайкю». 12+
9.00 «Здоровая семья: мама, папа и я». 6+
9.15 «Тамчы- шоу».
9.45 «Яшьләр тукталышы». 12+
10.15 «Ачыктан - ачык». 12+
11.00 «Яратам». Гөлнара Габидуллина концерты. 6+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Закон. Парламент.Общество». 12+
13.30 «Күңелем минем...» Җәвит Шакировның 60 яшьлек юбилей кичәсе. 6+
15.30 «Бу - димәк, мәхәббәт». Габделфәт Сафин. 6+
16.00, 0.45 «Ком сәгате». 12+
17.00 «Видеоспорт». 12+
17.30 «Татарлар». 12+
18.00 «Башваткыч». 12+
19.00, 22.00 «Семь дней». 12+
20.00 «Чёрное озеро». 16+
20.30 «Болгар радиосы» концерты. 6+
21.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
23.00 «ИСКУССТВО ЖИТЬ В ОДЕССЕ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05, 12.35, 23.20 «Халкым минем». 12+
5.30, 13.35 «Нәсыйхәт». 6+
6.00, 13.00, 0.40 «Татарлар». 12+
6.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
7.00 Спектакль «Әрем исе». 12+
9.00 «Ихсан күңел». Илсеяр Иксанова турында телеочерк. 6+
10.00 «Юлчы». 6+
10.30 «Калеб». 6+
11.10 «Тамчы-шоу». 6+
11.45 «Бергәләп өйрәник». 6+
12.05 «Яшьләр тукталышы». 12+
14.05 Зөфәр Хәйретдиновның 60 яшьлек юбилей кичәсе. 6+
17.15 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
18.10 «Кәмит Җәвит». 16+
19.05, 23.45 «Ком сәгате». 12+
20.00 «Семь дней». 12+
21.10 «Йолдызлар сәламе». 6+

«ЭФИР»

5.00, 14.30 «Люди РФ». 12+
5.30 «Опыты дилетанта». 12+
6.00 «Мировой рынок». 12+
7.00 «Сказочный патруль».
8.00 «Научные сенсации». 12+
9.00 «СЕМЕЙНЫЙ БИЗНЕС». 12+
11.10 «ПСИХОЛОГИНИ». 16+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «ЛЕГОК НА ПОМИНЕ». 12+
15.00 «Непростые вещи». 12+
15.35 «МИЛЛИОНЕРША». 12+
19.00 «Город». 16+
21.00 «ВЕЧНОСТЬ МЕЖДУ НАМИ». 12+
22.45 «Шерлоки». 16+
23.35 «БЭНКСИ». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

4.45, 6.10 «ГАЛКА И ГАМАЮН». 16+
6.00, 9.35, 12.00 Новости.
6.50 «Играй, гармонь любимая!» 12+
7.35 «Часовой». 12+
8.05 «Здоровье». 16+
9.15 «Непутевые заметки». 12+
9.50 Зимние Олимпийские игры. Лыжные гонки.
12.15 «Видели видео?» 6+
14.35 «Страна Советов. Забытые вожди». 16+
17.45 Концерт Максима Галкина. 12+
19.10 «Две звезды. Отцы и дети». 12+
21.00 «Время».
22.00 «ХРУСТАЛЬНЫЙ». 16+

«РОССИЯ»

4.30 XXIV Зимние Олимпийские игры. Фигурное катание.
7.40 «По секрету всему свету».
8.00 Местное время. Воскресенье.
8.35 «Когда все дома с Тимуром Кизяковым».
9.25 «Утренняя почта с Николаем Басковым».
10.10 «Сто к одному».
11.00 Вести.
11.30 «Петросян-шоу». 16+
13.20 «ДЕВЯТЬ ЖИЗНЕЙ». 16+
17.50 «Танцы со Звёздами». 12+
20.00 Вести недели.
22.00 Москва. Кремль. Путин.
22.40 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Энциклопедия загадок».
7.05 Мультфильмы.
7.45 «ВЕСЁЛАЯ ВДОВА».
10.05 «Мы - грамотеи!»
10.50 «МЕТЕЛЬ».
12.05 Больше, чем любовь.
12.45 Письма из провинции.
13.15 Диалоги о животных.
14.00 Невский ковчег. Теория невозможного. Георгий Пионтек.
14.30 «Игра в бисер» «Поэзия Владимира Высоцкого».
15.10 «Архи-важно».
15.40 «СИЛЬНАЯ ЖАРА».
17.10 «Пешком. Другое дело». Павел Флоренский.
17.40 К 60-летию Виктора Ракова. Линия жизни.
18.35 «Романтика романса».
19.30 Новости культуры.
20.10 «ИЗ ЖИЗНИ ОТДЫХАЮЩИХ».
21.30 «Майерлинг». Балет Кеннета МакМиллана. Постановка Королевского театра «Ковент- Гарден».
23.55 «ИСЧЕЗНУВШАЯ БАННИ ЛЕЙК».

«НТВ»

4.45 «БЕГЛЕЦ». 16+
6.35 «Центральное телевидение». 16+
8.00, 10.00, 16.00 Сегодня.
8.20 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Первая передача». 16+
11.00 «Чудо техники». 12+
12.00 «Дачный ответ».
13.00 «НашПотребНадзор». 16+
14.00 «Своя игра».
15.00, 16.20 «Следствие вели...» 16+
18.00 «Новые русские сенсации». 16+
19.00 Итоги недели.
20.10 «Звезды сошлись». 16+
21.40 «Основано на реальных событиях». 16+

Сукбайның сигез җинаяте

Бер тирәдә йөрүче эчкечеләр арасында шомлы хәлләр туктаусыз чыгып тора. “Сәрхушләрнең эзе суынмый” дигән язмада (“Мәдәни җомга”, 2021 ел.) Кама Тамагы бистәсендә шундый бәндәләр җыелып эчә торган өйдә Р.Гафиуллинның 35 яшьлек шешәдәшен кыйнап үтерүе турында сүз барды һәм шул даирәдәге башка ирләрнең дә җинаять кылу ихтималы зур булу турында әйтелде.

Бу очракта кан коюлы әлеге исерекләр мәҗлесендә катнашканга күрә җинаять эшендә төп шаһит буларак чыгыш ясаган М.Смирнов һәм В.Новрузов кебекләр күз алдында тотылды. Кызганычка, ошбу фараз бик тиз аклана. Утырып кайткан кеше буларак, административ күзәтүдә торган М.Смирнов тиешле кагыйдәләрне үтәмичә йөргән өчен, берничә ай колониядә торып ирекккә чыкты инде, ләкин моның озакка сузылачагына ышаныч аз.

Икенче шешәдәш Вахид Новрузов галәмәтләре турында озын-озаклап сөйләргә туры килә, чөнки узган елның май азагыннан сентябрь башына чаклы Кама Тамагында сигез җинаять эшләп өлгерде ул. Бу хәлләр турында сөйли башлаганчы 58 яшьлек абзыйның җинаятьчел үткәненә тукталып үтик. Иң әүвәл әлеге әзәрбайҗан кешесенең гаиләсез-баласыз һәм яшәр урыны булмаган сукбай гына түгел, хәтта илсез-ватансыз зат икәнен искәртик. Ягъни яшь вакытында ук Татарстанга килгән, СССР таркалгач, Россия гражданлыгы алмаган, Әзәрбайҗан Республикасы паспортына да ирешмәгән. Кыскасы, рәсми кәгазьләрдә “лицо без гражданства” дип язылган, шәхесен раслаучы бердәнбер документы – 2020 елда төзәтү колониясеннән чыкканда бирелгән белешмәсе бар аның.

Моның, иң беренче чиратта, Вахидның туктаусыз төрмә юлын таптавы нәтиҗәсе икәне бәхәссез, 90 нчы елларда хәтта кеше үтергән өчен дә хөкем ителгән ул. Әле хәзер дә гамәлдә булган соңгы еллардагы хөкемнәре дә җитәрлек. 2017 елда полиция хезмәткәрләренә каршылык күрсәткән кызу канлы Кавказ кешесенә алты айлык төзәтү эшләре билгеләнгән, күп тә үтми үзен йортка керткән хатыны Фәрдияне кыйнаган һәм тагын полиция белән бәйләнешкән өчен, ел ярымга Менделеев каласындагы колониягә озатылган. Аннан кайтуы белән шундый ук җинаятьләр кылып, кабат бер ел утырып 2020 ел азагында ирекккә чыга һәм Кама Тамагында пәйда була сукбай, үзе кебекләр рәтендәге таныш-белешләр янында, димәк, сәрхушләр җыела торган урыннарда тора. Югарыда телгә алынган кеше үтерү Новрузов шешәдәше М.Смирнов өендә торганда була.

Ваха кушаматы йөртүче бәндә “кунак булсаң, тыйнак бул”, дигән әйтемдәгечә яшәми. Үз даирәсендәгеләр арасында минем өчен кеше үтерү берни тормый, дип еш шапырына. Үзеннән куәтлерәкләргә барып ябышмый. Гафиуллин шешәдәшен үтергәндә дә почмакта посып утыра. Ә менә хатын-кызлар, кеше үтерүче дигән яманаты булган сукбайдан шикләнүче хәлсезрәк ирләр алдында бик тә кыю кылана.

Узган елның 21 маенда 32 яшьлек Олег Малышев өендә икәүләп салып утыра алар. Олег югарыда телгә алынган Фәрдия малае булганга, ирләр күптәннән таныш. Эчә торгач, Вахидның кибетче ханымны эш урынында дөмбәсләве һәм моның өчен утырып кайтуы хакында сүз чыкмый калмый. Әйтүенчә, Новрузов Малышевның бу турыда искә алуын ошатмый һәм кызып китеп өстәлдәге пычакны алып шешәдәшенә таба селтәнә, анысы тайпылып өлгерсә дә, борын өсте һәм чигә тирәсендә яра барлыкка килеп, кан ага башлый.

Төрмәдән башы чыкмаган затлар да анда яңадан әләгергә омтылмый. В.Новрузов та шүрли калып, урамга чыга, кулына пычак тоткан килеш күршесе ишегалдына барып керә, аңа кемнедер чәнчүен әйтә, җинаять коралын бирмәкче була. Күрше исә аны куып чыгара да кирәкле оешмаларга хәбәр сала. Качып китәргә уйламый Вахид, Малышев өенә кереп пычакны югач, аның янына черем итәргә ята. Малышевны, ярасын эшкәртеп теккәч, сырхауханәдән өенә кайтарып җибәрәләр. Эксперт аның сәламәтлегенә җиңел рәвештән зыян китерелгән дип белдерә, димәк, шул хактагы маддә буенча эш кузгатыла. Новрузов шактый вакыт барысын да кире кага, ләкин соңрак дөресен сөйли. Алданрак ялган оештыруын полиция изоляторга ябып куюдан курку белән аңлата.

Куркырлык сәбәп тә була монда. Чөнки вакыйга урынына килеп җиткән полиция хезмәткәрләрен дә, кем әйткәндәй, эттән алып этке сала ул. Оперативник Н.Берляковка күбрәк эләгә, хезмәт вазифаларын башкаручы власть вәкилен кимсеткән өчен, тагын бер җинаять эше ачыла. Ләкин ябып куймыйлар аны. Бистә урамнарында арлы-бирле йөри торгач, ике көннән тагын бер хилафлык кыла хәрәсән – рөхсәтсез чит кеше торагына керә.

Әйтүенчә, 23 майда арып ял итәргә урын эзләргә керешә һәм Д.Дружинина (кайбер исемнәр үзгәртелә) өенә килә, ишек бикле булгач, веранда тәрәзәсен ватып эчкә үтә, түр яктагы караватка сузылып ята. Очраклы торак булмый бу. Чөнки элегрәк монда Анна атлы хатын белән яши, ханым 2015 елда вафат булгач та, Вахид чираттагы хөкемен үтәргә киткәнче, шунда көн күрә. 2021 ел февралендә мәрхүмәнең кызы Д.Дружинина аңа сыеныр урын бирә. 23 май иртәсендә туган тиешле өч хатын-кыз килеп өйне җыештыралар, В.Новрузовны куып чыгарып, бүтән килмәскә кушалар. Ул вакытта күндәм кыланган сукбай, чарасызлыктан әйләнеп кайта. Кич белән ватык тәрәзәне күреп, өйгә килеп кергән М.Дружинин аны уятып, урамга озата.

Тикшерү комитетының аеруча мөһим эшләр буенча тикшерүчесе Андрей Россиев чит торакка кереп хуҗабикәнең конституцион хокукын бозу очрагы буенча тагын бер, димәк, дүртенче җинаять эше кузгата. Берничә көннән Вахиднең ошбу йорттан бензин пычкысы чәлдерүе дә билгеле була. Урлау турындагы җинаять эшен полиция бүлекчәсе тикшерүчесе алып бара. Тикшерү эшләре озын-озакка сузылмый, август аенда аларның кайберләре судта карала да башлый. Әмма инде хөкем ителүче “дәрәҗә”сенә ия булган ир-ат башын түбән иеп кенә йөрми.

Дружинина өеннән чыгарылгач та, шешәдәше О.Махрин йортына ияләшә ул. Олегның язылышмаган хатыны Е.Малинина аның эшләмичә алар хисабына яшәвен, исереп кайтып еш кына гауга куптаруын һәм элек кеше үтергәне булган бу адәмнән бик куркуын әйтеп тора. Ләкин О.Махрин аны урамга озатырга базмый. 5 август кичендә салмыш кайтып кергән Вахид “йокларга вакыт” дип телевизорны сүндергән хатынга бәйләнә, бер-ике тапкыр баш тирәсенә тондырып та ала, пычак тотып тегеләр дөньяга озату белән өркетә, Махрин әйткәннәрне колагына да элмичә котырына. Көч-хәл белән урамга чыгып чапкан хатын-кыз полициягә шалтырата. Тән җәрәхәтләре сәламәтлеккә зыян салмаган булып чыга, җинаять эше 40 яшьлек Е.Малининага үтерү белән янаган өчен кузгатыла.

Хатын-кыз Новрузовтан шүрләп өч көн буе ире янына кайтмыйча танышларында кунып йөри. Шуңа күрә О.Махрин да озатып җибәрә сукбайны. Берничә көннән сый-хөрмәт тотып, Антонина атлы ялгыз ханым янына килеп керә ул. Ике-өч ел элек ошбу йортка бер сөяркәсе белән килеп йөргәнгә, күптәнге танышлар була алар. Хәмер булгач уртак тел табыла, бергәләп салып утырганнан соң, 56 яшьлек ханым аны кунарга калдыра. Әрсез кунак икенче көнне дә пәйда була, ә өченче көнне иртүк хуҗабикә ияләшә башлаган сәрхушне урамга куа, артыннан капканы бикләп кала.

Төштән соң килеп чыккан исерек Вахид ишегалдына коймa аша төшә, чыр-чу килгән Антонинага ашыйсы һәм йокысы килүен әйтә, хәленә керүче булмагач, өйалды ишеген каерып түрдән уза һәм йокларга түнә. Участок инспекторы Р.Нәҗмиев уятып, аны һәм хуҗабикәне полициягә алып бара, хатын-кыз чакырылмаган кунакны җинаять җаваплылыгына тартуны сорап гариза яза.

3 сентябрьдә Новрузов кәмитләре буенча беренче хөкем игълан ителә, ниһаять. Суд полиция хезмәткәрен кимсеткән өчен аңа 10 айлык төзәтү эшләре билгели. Әлбәттә, Вахид урам себерергә яисә фермада терлекләр карарга кереште дигәнне белдерми бу. Гел ирекгә йөрүче Вахид 8 сентябрьдә, үзе әйтмешли, акча табып һәм аракы алып, тагын О.Махрин йортына барып керә. Хуҗа иртүк эшкә киткәнгә, Е.Малинина үзе генә чак туры килә. Алданрак бар да дуслык шартларында бара, хатын-кыз эчеп кенә утырмый, шул арада керләр, шул исәптән, юмарт кунак киемнәрен дә юып ала. Ләкин бер мәлне вәзгыять кискенләшә, исерүе җиткән Новрузов хатын-кызның бер ай элек аның өстеннән язган гаризасын исенә төшерә һәм аның муенына ябыша, буыла башлагач ычкындыра, кулына чәнечке тотып болгана һәм дөмектерәм, дип акыра. Коты алынган хатын урамга чыгып качу җаен таба һәм эштән кайтып килүче иренең телефоныннан полициягә шалтырата.

А.М.Россиевка үтерү белән янаган өчен тагын бер эш кузгатырга туры килә. Ләкин бусы да соңгысы булмый әле. Полициядән чыгарып җибәргәч бер танышында куна да, гадәттәгечә, эчәргә җай чыгара һәм ял итәргә урын эзли башлый. Шул нияттән тагын О.Махрин йорты янына килә, хуҗаны капка төбендә очрата. Әлбәттә, аның явызлыкларыннан туйган ир-ат өенә кертми, ишекне бикләп эшенә китә. Берәр сәгатьтән аңа хатыны Елена ишек тыштан бикле, ә өйдә кемдер бар бугай, дигән шиген белдерә. Күп тә үтми алар участковый Р.Нәҗмиевны очратып, аның белән бергәләп өйләренә керәләр һәм диванда яткан таныш бәндәне күрәләр. Новрузов веранданың тәрәзәсеннән керүен әйтә. Чит кеше фатирына керү буенча тагын бер эш кузгатыла.

Менә шуннан соң көньяк кешесенең хикмәтле кыланмышларына чик куела. Чөнки Кама Тамагы район суды май аенда Дружинина йортыннан бензопила урлау очрагы буенча 1963 елгы абзыйны ирегеннән мәхрүм итәргә дигән карар чыгара, ул утырышлар залында богаулана. Әлбәттә, әлеге кырыс җәза алдагы хөкемнәрне исәпкә алып бирелә. Шуннан соң бер-бер артлы без санап үткән җинаятьләр буенча карарлар игълан ителә, димәк ки, колониядә утырту срогы да арта бара. 2021 елның 21 декабрендә соңгы җинаять эшен тыңлау тәмамланды. Ахыр чиктә, В.Новрузовны 3 ел ярымга колониягә озатырга карар бирелде. Яңа ел бәйрәмнәре алдыннан хөкем үз көченә керде.

Шулай итеп 2021 ел гыйнварында эчеп утырган дүрт ир-атның икесе колониядә, берсе гүрдә инде. В.Новрузов җинаятьләренең барысы да таныш-белешләр, шешәдәшләргә карата һәм, әлбәттә, исерек баштан кылынган. Ул үзе дә аек булсам алай эшләмәс идем дип, эчкән чакта йөгәнсез икәнен таный. Сәрхушләрне шул йөгәнсезлек алып барып чыгара да инде.

Наил ВАХИТОВ.

Мәдәни җомга

Г.Кариев исемендәге Татар дәүләт яшь тамашачы театрында Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты Нуриәхмәт Сафинны 75 яшьлеге белән котладылар.

Юбилей уңае илә, *яки* Нәрсәдән арынабыз?

Нуриәхмәт ага яшьләр театрында иң өлкән артист булса да, күңеле һаман яшь. Театрның беренче көннәреннән эшләп 55 еллык иҗат гомерендә ул тормыш авырлыкларына бирешмичә, нык торырга, күңел күтәренкелеген җуймаска өйрәнде. Ә яшьләр театры кыенлыкларны күп күрде. Бинасыз интегү үзе генә дә ни тора. Аның үз куышына кереп сыенганына әле бик аз вакыт үтте. Аның каравы сөенечләр дә шактый. Ф.Бәйрәмова әсәре буенча куелган «Атылган йолдыз» спектаклендә шагыйрь Һади Такташны уйнау бәхет түгелмени? «Башмагым» спектаклендә - Кәрим бай, «Йосыф-Зөләйха»да Йагкуб рольләре репертуарының таҗы булып тора. Король Лирны уйнаган бәхетле артист ул Н.Сафин. Нинди генә хәрабә биналарда иҗат итсә, уч төбе кадәр кечкенә сәхнәләрдә уйнаса да, Яшьләр театры Шекспирны, Мольерны, Тукайны, Гаяз Исхакыйны, бөтән классикларны куйды. Кайбер йөзьяшәр театрларыбыз да бу бөек әсәрләргә алынмый, чөнки төп рольләрне башкарырдай актерлар юк, режиссерлар да үз көчләренә үзләре ышанмый, күрсәң. Ә Нури Сафин режиссер Ренат Әюпов куйган спектакльдә Лирны театр тарихына кереп калырлык итеп башкарды. Ни генә күрсә дә, Яшьләр театрында бер генә артист та әрәм булып калмады, һәрберсенә рольләр табылды һәм моның өчен без, әлбәттә, режиссер Ренат Әюповка рәхмәтле. Җыеп әйткәндә, Яшьләр – Сафиннан, Нури абый Яшьләр театрыннан унды.

Шуңа өстәп, Н.Сафин ике тапкыр Мәскәүдә А.П.Чехов исемендәге МХАТ мәктәп-студиясендә Олег Табаков һәм Олег Ефремов җитәкчелегендә стажировка уза. Ул вакытта театрның үз бинасы да юк. Бер почмактан икенче почмакка барып сыеналар. Театрны оештырган һәм җитәкләгән Фәрит Хәбибуллинның тәвәккәллегенә сокланып туймаслык.

Юбилей кичендә Н.Сафинга Татарстан Президенты Указы нигезендә театр сәнгатен үстерүдәге казанышларын һәм күпьеллык нәтиҗәле иҗади эшчәнлеген бәяләп «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале һәм «Казан хакына мактауга лаеклы хезмәте өчен» аерым хөрмәтләү билгесе тапшырылды. Яшьрәк коллегалары артистны җылы котлауларга күмде.

Ә менә юбилей уңаеннан күрсәтелгән спектакль әллә нинди шомлы, киртәләрне җиңеп, артист булу теләгенә тугры калган Н.Сафинның табигатенә ят, капма-каршы рухта иде. Пьеса авторлары А.Әхмәдиев һәм Т.Куловның бер кеше язмышы аша илебезнең тарихын чагылдыруы һәм режиссер Тимур Куловның вакыйгаларны тыгыз рәвештә мавыктыргыч сәхнә теле белән бәян итүе әйбәт эшләнсә дә, «Арыну» Н.Сафинның гына түгел, милләтебезнең рухына ят спектакль булып чыккан.

Вакыйгалар 75 яшьлек Хәй Әхмәтовичның үткәннәрне искә алуы рәвешендә бәян ителә. Аның тормышында ирешми калган үрләр, үкенечләр байтак – актер карьерасына кызыгып та, гомер буе сәхнә монтеры булып эшләү, Казанны зурайтырга теләп күпкатлы йортлар төзү нәтиҗәсендә, шәһәр яны бистәләренең берсендә кендек каны тамган йортыннан колак кагуы, бердәнбер улын чечен сугышында югалтуы, шул кайгыдан янып үлгән карчыгы Саниясен җир куенына илтеп тыгуы һ.б. Ул сөйләгәндә бетеп барган авыллар, мәгънәсез сугышларда башларын салган милләттәшләребез өчен әрнү билән ала. Адәм баласының ирексез, ә кайчак алданып яшәвеннән, дөреслек таба алмавыннан йөрәк яна. Үткәннәрне искә төшергән спектакльдә «Умырзая», «Күңелемдә яз», «Очрашырбыз, ышанам» һ.б. матур җырларның байтак яңгыравы урынлы һәм күңелгә сары май булып ята. Спектакльдә геройлар шактый булса да, аларны Халидә Сөнгатуллина, Фирүзә Зиннәтуллина, Альбина Гайзуллина, Фернат Насыйбуллин, Эльдар Гатауллин, Булат Гатауллин гына гәүдәләндерә. Берничә роль башкарган актерларның берсеннән икенчесенә оста күчүе сокландырса да, профессиональ театр сәхнәсендә «Мунча ташы» өслүбендә ясалма чәч, мыек тагып чыгып пародиягә охшаш рәвештә роль башкару урынсыз диярг кирәк.

Спектакльнең вак-төяк кимчелекләренә күз йомарга да мөмкин булыр иде, ахыры шул дәрәҗәдә аяныч тәмамланмаса. Хәй Әхмәтовичның муенына элмәк салып мордар китүе исә - «Арыну» спектакленең герое һәм аны караган тамашачы өчен генә түгел, бөтен татар театры өчен шомлы күренеш. Тәкъдиргә риза булмыйча, Аллаһка каршы барып, мордар китү бабаларыбыз диненә каршы килә. Үз-үзен үтерүчеләргә бакый дөньяда мәңгелек газап язган. Моңа кадәр татар сәхнәсендә якты маяк булып янган үлемсез Әлмәндәребез бар иде. Тормышта да җор телле, моңаюны белмәс, мәңге яшь Әлмәндәр бабайга охшарга тырыштык. «Арыну» спектакле белән исә без гүя үлемсез Әлмәндәребездән үтерәбез. Арыну сүзе бу очракта күп еллар буена татар тормышына мәгънә, ямь биргән кадерле нәрсәләрдән котылу булып ишетелә...

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ – «ТАТМЕДИА» АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры – баш мөхәррир

Вахит Шәих улы ИМАМОВ

Җаваплы сәркатип
Илгизәр ЗӘКИЕВ

Шылтыратыгыз:

222-09-83 (1562) – кабул итү бүлмәсе;

222-05-47 (1560) – җаваплы сәркатип, компьютер үзәге;

222-05-47 (1561) – иҗтимагый-сәяси тормыш, мәгариф һәм фән, сәнгать бүлекләре; хатлар һәм социаль конкуреш, тәрҗемә бүлекләре;

222-09-84 (1266) – бухгалтерия.

Реклама хезмәте телефоны: (843)222-05-47 (1560)

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләр өлкәсенә күзәтчелек итү федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2019 елның 9 октябрендә ПИ №ФС 77–76961 нче санлы теркәү таныклыгы алды

Индекс П2355

Авторлар фикере редакция фикере белән авазадаш булмаска да мөмкин

Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк

Хатлар, кулъязмалар, фотографияләр, рәсемнәргә бәяләмә бирелми һәм алар кире кайтарылмый

© Газетада чыккан материалларны күчереп бастырганда редакциядән язмача рөхсәт алу мәҗбүри

Реклама һәм белдерүләрнең төгәллеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы

Безгә иганәлек ярдәме күрсәтергә теләүчеләр өчен редакциянең исәп-хисап счеты:

**ИНН 1655144950 КПП 165802012
ПАО «АК БАРС» банк,
г. Казань
р/с 40702810600020010312
к/с 30101810000000000805
БИК 049205805 ОГРН 1021600000124**

НӘШЕР ИТҮЧЕ – «ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан, Академия урамы, 2

Редакция, гамәлгә куючы һәм басмаханәнең адресы:

420066, Казан,
Декабристлар урамы, 2

E-mail: m-jomga@mail.ru

“Мәдәни җомга” газетасы Интернетта:
www.madanizhomga.ru

Басмаханә гаебе белән җибәрелгән сыйфат җитешсезлекләре хакында 562-10-61 номерлы телефон буенча шылтыратырга

Газета һәр атнаның җомга көнендә чыга. Бу санның чыгу көне 28.01.2022

График буенча бу санга 15 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 14 сәгать 30 минутта.

“Татмедиа” АҖ филиалы – “Идел-Пресс” полиграфия-нәшрият комплексында басылды

Газетаның сатудагы бәясе ирекле

Тираж – 2750 данә

Заказ 2737

16+